© Изге Китапны тәрҗемә итү институты, 2007

# Саннар*

*Исраиллеләрнең санын исәпкә алу*

1 [1] Исраиллеләрнең Мисыр җиреннән чыгуларының икенче
елында, икенче айның беренче көнендә, Синай чүлендә, Из-
ге чатырда Раббы Мусага түбәндәгеләрне әйтте:
[2] – Исраил җәмәгатьчелегенең кабиләләре, гаиләләре, исемнәр
исемлеге буенча барлык ир-ат затын берәмләп исәпкә алыгыз. [3] Син
һәм Һарун, егерме яшьтән алып аннан өлкәнрәкләрне, Исраилдә
сугышка яраклы барлык ир-ат затын, хәрби төркемнәре буенча
исәпкә алыгыз.
[4] – Һәр ыруггтан нәсел башлыгы булган кеше сезгә ярдәм итәргә ти-
еш. [5] Менә сезгә ярдәм итәргә тиешле кешеләрнең исемнәре: Рубин-
нан Шедур угылы Элисур; [6] Шимуннан Суришаддай угылы Шелуми-
ел; [7] Йәһүдәдән Амминадаб угылы Нахшон; [8] Исәсхәрдән Суар угылы
Нетанел; [9] Зәбулуннан Хелон угылы Элиаб; [10] Йосыф угылларыннан:
Эфраимнан Аммиһуд угылы Элишама, Менашшедан Педаһсур угы-
лы Гәмәлиел; [11] Беньяминнән Гидеони угылы Абидан; [12] Даннан Ам-
мишаддай угылы Ахигызыр; [13] Аширдән Өхрән угылы Пагиел; [14] Гәд-
тән Дегуил* угылы Эльясаф; [15] Нәфталидән Энан угылы Ахира.
[16] Болар – халык арасыннан сайланган кешеләр, ата-бабалары-
ның ыруг җитәкчеләре, Исраил кабиләләренең башлыклары.
[17] Муса белән Һарун атап үткән бу кешеләрне үзләре белән алды-
лар. [18] Икенче айның беренче көнендә алар барлык җәмәгатьчелекне
бергә җыйдылар. Үзләренең егерме яшьтән алып аннан өлкәнрәк бул-
ган кешеләрен кабиләләре, гаиләләре һәм исемнәр саны буенча бе-
рәмләп исәпкә алдылар. [19] Раббы Мусага шулай эшләргә боерык бир-
де. Һәм ул, шул рәвешчә, Синай чүлендә халык санын исәпкә алды:
[20-21] Исраилнең беренче угылы Рубин ыругында, кабиләләре, гаи-
ләләре, исемнәр саны буенча егерме яшьтән алып аннан өлкәнрәк

---

* *Саннар* – халык санын исәпкә алу мәгънәсендә.

* 1:14 Яһүдчә нөсхәдә шул аятьтә Дегуил «Регуил» дип аталды.

булган сугышка яраклы барча ир-ат затларын берәмләп исәпләгәннән соң, кырык алты мең биш йөз кеше булды.
22-23 Шимун ыругында, кабиләләре, гаиләләре, исемнәр саны буенча егерме яшьтән алып аннан өлкәнрәк булган сугышка яраклы барча ир-ат затларын берәмләп исәпләгәннән соң, илле тугыз мең өч йөз кеше булды.
24-25 Гәд ыругында, кабиләләре, гаиләләре, исемнәр саны буенча егерме яшьтән алып аннан өлкәнрәк булган сугышка яраклы барча ирләрне исәпләгәннән соң, кырык биш мең алты йөз илле кеше булды.
26-27 Йәһүдә ыругында, кабиләләре, гаиләләре, исемнәр саны буенча егерме яшьтән алып аннан өлкәнрәк булган сугышка яраклы барча ирләрне исәпләгәннән соң, җитмеш дүрт мең алты йөз кеше булды.
28-29 Исәсхәр ыругында, кабиләләре, гаиләләре, исемнәр саны буенча егерме яшьтән алып аннан өлкәнрәк булган сугышка яраклы барча ирләрне исәпләгәннән соң, илле дүрт мең дүрт йөз кеше булды.
30-31 Зәбулун ыругында, кабиләләре, гаиләләре, исемнәр саны буенча егерме яшьтән алып аннан өлкәнрәк булган сугышка яраклы барча ирләрне исәпләгәннән соң, илле җиде мең дүрт йөз кеше булды.
32-33 Йосыф угылы Эфраим ыругында, кабиләләре, гаиләләре, исемнәр саны буенча егерме яшьтән алып аннан өлкәнрәк булган сугышка яраклы барча ирләрне исәпләгәннән соң, кырык мең биш йөз кеше булды.
34-35 Менашше ыругында, кабиләләре, гаиләләре, исемнәр саны буенча егерме яшьтән алып аннан өлкәнрәк булган сугышка яраклы барча ирләрне исәпләгәннән соң, утыз ике мең ике йөз кеше булды.
36-37 Беньямин ыругында, кабиләләре, гаиләләре, исемнәр саны буенча егерме яшьтән алып аннан өлкәнрәк булган сугышка яраклы барча ирләрне исәпләгәннән соң, утыз биш мең дүрт йөз кеше булды.
38-39 Дан ыругында, кабиләләре, гаиләләре, исемнәр саны буенча егерме яшьтән алып аннан өлкәнрәк булган сугышка яраклы барча ирләрне исәпләгәннән соң, алтмыш ике мең җиде йөз кеше булды.
40-41 Ашир ыругында, кабиләләре, гаиләләре, исемнәр саны буенча егерме яшьтән алып аннан өлкәнрәк булган сугышка яраклы барча ирләрне исәпләгәннән соң, кырык бер мең биш йөз кеше булды.
42-43 Нәфтали ыругында, кабиләләре, гаиләләре, исемнәр саны буенча егерме яшьтән алып аннан өлкәнрәк булган сугышка яраклы барча ирләрне исәпләгәннән соң, илле өч мең дүрт йөз кеше булды.

[44] Менә болар Муса белән Һарун һәм Исраилнең унике башлы-
гы – һәр ыругтан бер кеше – исәпкә алганнарның саны. [45] Исра-
иллеләрдән гаиләләре буенча егерме яшьтән алып аннан өлкәнрәк
булган һәм сугышка яраклы дип табылган ирләр саны исәпкә алын-
ды. [46] Һәм исәпкә алынганнарның саны барлыгы алты йөз өч мең
биш йөз илле кеше булды.

*Леви ыругының исәпкә алынмавы*

[47] Әмма алар арасында ата-бабаларының ыругы буенча левиләр,
аларның гаиләләре исәпкә алынмады. [48] Раббы Мусага әйтте:
[49] – Бары тик Леви ыругын гына исәпкә алма, аларны исраилле-
ләр белән бергә санама. [50] Ә боерыклар куелган чатырны, аның бар-
лык әсбапларын һәм анда булган һәр нәрсәне левиләргә тапшыр.
Алар чатырны һәм аның әсбапларын күчереп йөртсеннәр һәм шун-
да хезмәт итсеннәр; үз чатырларын да чатыр әйләнәсендә корсын-
нар. [51] Чатырны бер урыннан икенче урынга күчергәндә, аны леви-
ләр генә сүтсен; һәм һәр яңа урынга баргач, аны левиләр генә
корсын. Ә инде кем дә булса башка кеше аңа якын килсә, ул үлемгә
дучар ителергә тиеш. [52] Исраиллеләрнең һәркайсы үз чатырын үз
байрагы астында, үз хәрби төркеме белән корырга тиеш. [53] Ә ле-
виләр исә, Исраил җәмәгатьчелегенә Аллаһының ачуы чыкмасын
өчен, үз чатырларын боерыклар куелган чатыр әйләнәсендә ко-
рырга тиешләр. Левиләр боерыклар куелган чатырны сакларга тиеш.
[54] Раббы Мусага ничек әмер биргән булса, исраиллеләр нәкъ
шулай эшләделәр дә.

*Кабиләләрне чатырларга урнаштыру*

**2** [1] Раббы Муса белән Һарунга әйтте:
[2] – Исраиллеләрнең һәрберсе үз чатырын үз байрагы астында
һәм үз гаиләләренең билгесе астында Изге чатыр тирәли ко-
рырга тиеш.
[3] – Изге чатырдан көнчыгышка таба Йәһүдә гаскәренең байрагы
астында Йәһүдә ыругы үз чатырларын корып урнаштырырга тиеш.
Йәһүдә угылларының башлыгы – Амминадаб угылы Нахшон. [4] Аның
гаскәрендә исәпкә алынганнар саны җитмеш дүрт мең алты йөз
кеше. [5] Йәһүдә ыругы янында Исәсхәр ыругы үз чатырларын корып
урнаштырырга тиеш. Исәсхәр угылларының башлыгы – Суар угы-
лы Нетанел. [6] Аның гаскәрендә исәпкә алынганнар саны илле дүрт
мең дүрт йөз кеше. [7] Зәбулун ыругы да чатырларын шунда корып
урнаштырырга тиеш. Зәбулун угылларының башлыгы – Хелон угы-
лы Элиаб. [8] Аның гаскәрендә исәпкә алынганнар саны илле җиде
мең дүрт йөз кеше. [9] Йәһүдә гаскәрендә исәпкә алынган барлык
кешеләр саны йөз сиксән алты мең дүрт йөз кеше. Башка урынга
күчкәндә, алар беренче булып кузгалырга тиеш.

[10] – Изге чатырдан көньякка таба Рубин гаскәренең байрагы астында Рубин ыругы үз чатырларын корып урнаштырырга тиеш. Рубин угылларының башлыгы – Шедур угылы Элисур. [11] Аның гаскәрендә исәпкә алынганнар саны кырык алты мең биш йөз кеше. [12] Рубин ыругы янында Шимун ыругы үз чатырларын корып урнаштырырга тиеш. Шимун угылларының башлыгы – Суришаддай угылы Шелумиел. [13] Аның гаскәрендә исәпкә алынганнар саны илле тугыз мең өч йөз кеше. [14] Гәд ыругы анда да чатырларын корып урнаштырырга тиеш. Гәд угылларының башлыгы – Дегуил угылы Эльясаф. [15] Аның гаскәрендә исәпкә алынганнар саны кырык биш мең алты йөз илле кеше. [16] Рубин гаскәрендә исәпкә алынган барлык кешеләр саны бер йөз илле бер мең дүрт йөз илле кеше. Башка урынга күчкәндә, алар икенче булып кузгалырга тиеш.

[17] – Изге чатыр һәм Леви ыругы башка ыруглар уртасында булып, урнашкан урыннарында ничек торсалар, күченгәндә нәкъ шулай барырга тиеш. Һәркайсы үз урынында, үз байрагы астында барсын.

[18] – Изге чатырдан көнбатышка таба Эфраим гаскәренең байрагы астында Эфраим ыругы үз чатырларын корып урнаштырырга тиеш. Эфраим угылларының башлыгы – Аммиһуд угылы Элишама. [19] Аның гаскәрендә исәпкә алынганнар саны кырык мең биш йөз кеше. [20] Эфраим ыругы янында Менашше ыругы үз чатырларын корып урнаштырырга тиеш. Менашше угылларының башлыгы – Педаһсур угылы Гәмәлиел. [21] Аның гаскәрендә исәпкә алынганнар саны утыз ике мең ике йөз кеше. [22] Беньямин ыругы анда да чатырларын корып урнаштырырга тиеш. Беньямин угылларының башлыгы – Гидеони угылы Абидан. [23] Аның гаскәрендә исәпкә алынганнар саны утыз биш мең дүрт йөз кеше. [24] Эфраим гаскәрендә исәпкә алынган барлык кешеләр саны бер йөз сигез мең бер йөз кеше. Башка урынга күчкәндә, алар өченче булып кузгалырга тиеш.

[25] – Изге чатырдан төньякка таба Дан гаскәренең байрагы астында Дан ыругы үз чатырларын корып урнаштырырга тиеш. Дан угылларының башлыгы – Аммишаддай угылы Ахигызыр. [26] Аның гаскәрендә исәпкә алынганнар саны алтмыш ике мең җиде йөз кеше. [27] Дан ыругы янында Ашир ыругы үз чатырларын корып урнаштырырга тиеш. Ашир угылларының башлыгы – Өхрән угылы Пагиел. [28] Аның гаскәрендә исәпкә алынганнар саны кырык бер мең биш йөз кеше. [29] Нәфтали ыругы анда да чатырларын корып урнаштырырга тиеш. Нәфтали угылларының башлыгы – Энан угылы Ахира. [30] Аның гаскәрендә исәпкә алынганнар саны илле өч мең дүрт йөз кеше. [31] Дан гаскәрендә исәпкә алынган барлык кешеләр саны бер йөз илле җиде мең алты йөз кеше. Башка урынга күчкәндә, алар үз байраклары астында иң соңгы булып кузгалырга тиеш.

[32] Исраиллеләрдән, гаиләләренә карап, исәпкә алынганнар саны
алты йөз өч мең биш йөз илле кеше булды. [33] Ә левиләр, Мусага
Раббы әмер иткәнчә, исраиллеләр белән бергә исәпкә алынмады-
лар. [34] Исраиллеләр, Мусага Раббы ничек әмер иткән булса, шулай
эшләделәр: үз байраклары астында, үз чатырлары белән тиешле тәр-
типтә тезелеп урнаштылар, һәм һәркайсы үз кабиләсе, үз гаиләсе
белән хәрәкәт итте.

*Руханилар һәм Леви ыругы хакында*

**3** [1] Синай тавында Раббы Мусага сөйләгән вакытта, Һарун бе-
лән Мусаның нәселләре менә нинди иде. [2] Һарун угыллары-
ның исемнәре: иң беренче булып туган Надаб, Абиһу, Элгазар,
Итамар. [3] Болар Һарун угылларының исемнәре. Алар руханилыкка
багышлану өчен май сөртелгән руханилар. [4] Әмма Надаб белән Аби-
һу Синай чүлендә Раббы алдында рөхсәт ителмәгән ут тәкъдим ит-
кән вакытта үлделәр; аларның балалары булмады. Ә Элгазар белән
Итамар үзләренең аталары – Һарун янында рухани булып калдылар.
[5] Раббы Мусага әйтте:
[6] – Леви ыругын алып кил һәм Һарун алдына бастыр, алар рухани
Һарунга хезмәт итәргә булышсыннар. [7] Алар Изге чатыр алдында
Һарун һәм бөтен җәмәгатьчелек өчен чатыр хезмәтен башкарсын-
нар. [8] Изге чатырның барлык әсбапларын сакласыннар һәм, Изге
чатырда хезмәт итеп, исраиллеләрнең вазифаларын үтәсеннәр.
[9] Левиләрне Һарун һәм аның угыллары карамагына тапшыр. Бөтен
исраиллеләр арасыннан Һарун карамагына алар бирелсен. [10] Һарун
һәм аның угылларын руханилар итеп билгелә. Алар руханилык ва-
зифаларын төгәл үтәсеннәр. Әгәр башка кеше хезмәт итәргә теләп
якынлаша икән, ул кеше үлемгә тапшырылырга тиеш.
[11] Раббы Мусага әйтте:
[12] – Менә, Мин барлык исраиллеләр арасыннан, һәрбер хатын-
нан беренче булып туганнар урынына, левиләрне алдым. Левиләр
Минеке булырга тиеш. [13] Чөнки беренче булып туганнарның бары-
сы да Минеке. Мин Мисыр җирендә мисырлыларның беренче бу-
лып туганнарының һәммәсен юк иткән көндә, Исраилдә беренче
булып туганнарны – кешеме ул, хайванмы – барчасын Үзем өчен
изгеләндердем. Алар Минеке булырга тиеш. Мин – Раббы.

*Левиләрнең вазифалары*

[14] Раббы Синай чүлендә Мусага әйтте:
[15] – Леви угылларын, гаиләләре һәм кабиләләре буенча, бер ай-
лыктан алып аннан өлкәнрәк булган барлык ир-ат затларын исәп-
кә ал.
[16] Һәм Муса, Раббы ничек әмер иткән булса, шулай исәпләде.
[17] Исемнәре буенча Леви угыллары менә шушылар: Гершон, Коһат

һәм Мерари. [18] Кабиләләре буенча Гершон угылларының исемнәре менә болай: Либни һәм Шимгый. [19] Кабиләләре буенча Коһат угылларының исемнәре: Амрам, Исһар, Хебрун һәм Уззиел. [20] Кабиләләре буенча Мерари угылларының исемнәре: Махли һәм Муши. Гаиләләре буенча левиләрнең кабиләләре менә шулар.

[21] Либни һәм Шимгый кабиләләре Гершонныкы; алар Гершон кабиләләредер. [22] Аларның бер айлыктан алып аннан өлкәнрәк булган барлык ир-ат затларының исәпкә алынган саны җиде мең биш йөз кеше булды. [23] Гершон кабиләләре үз чатырларын Изге чатыр артында көнбатышка таба корып урнаштырырга тиеш иде. [24] Гершон гаиләләренең башлыгы – Ләил угылы Эльясаф. [25-26] Изге чатырны, аның өске каплавычын, керү урынындагы пәрдәне һәм чатыр белән мәзбәхне әйләндереп алган ишегалды пәрдәләрен, ишегалдының керү урынындагы пәрдәне һәм бауларны, шулай ук барлык кирәк-яракларны саклау бурычы Гершон угылларына тапшырылды.

[27] Амрам белән Исһар, Хебрун һәм Уззиел кабиләләре Коһатныкы; алар Коһат кабиләләредер. [28] Аларның бер айлыктан алып аннан өлкәнрәк булган барлык ир-ат затларының исәпкә алынган саны сигез мең алты йөз кеше. Болар – Изге бүлмәне саклаучылар. [29] Коһат угылларының кабиләләре үз чатырларын Изге чатырдан көньякка таба корып урнаштырырга тиеш иде. [30] Коһат кабиләсенең гаиләләре башлыгы – Уззиел угылы Элисафан. [31] Аллаһы сандыгы, өстәл, шәмдәл, мәзбәхләр, хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган Изге бүлмә әсбаплары, пәрдә һәм барлык кирәк-яраклар алар сагы астында булды. [32] Рухани Һарун угылы Элгазар левиләрнең җитәкчеләре өстеннән баш җитәкче булды. Ул Изге бүлмәне саклау вазифасы йөкләнгәннәр өстеннән күзәтчелек итте.

[33] Махли һәм Муши кабиләләре Мераринеке; алар Мерари кабиләләредер. [34] Аларның бер айлыктан алып аннан өлкәнрәк булган барлык ир-ат затларының исәпкә алынганы алты мең ике йөз кеше. [35] Мерари кабиләсенең гаиләләре башлыгы – Абихаил угылы Суриел. Алар үзләренең чатырларын Изге чатырның төньягында корып урнаштырырга тиеш булды. [36-37] Чатырның такталарын, борысларын, баганаларын, нигезләрен һәм барлык әсбаплары белән кирәк-яракларын, шулай ук ишегалдының һәр ягындагы баганаларын, аларның нигезләрен һәм казыкларын, бауларын саклау бурычы Мерари угылларына тапшырылды.

[38] Муса белән Һарун һәм Һарун угыллары үз чатырларын Изге чатыр алдына, аның көнчыгышка караган ягына корып урнаштырырга тиеш булдылар. Исраиллеләр өчен Изге бүлмәне саклау вазифасы аларга йөкләнде. Әгәр нинди дә булса башка кеше аңа якын килсә, ул үлемгә дучар ителергә тиеш иде. [39] Раббының күрсәтмәсе буенча, Муса белән Һарун, кабиләләренә карап,

левиләрнең санын исәпкә алдылар. Бер айлыктан алып аннан өлкәнрәк яшьтәге барлык ир-атларның саны егерме ике мең кеше булды.

*Исраиллеләрнең беренче булып туганнары урынына левиләрне алу*

40 Раббы Мусага әйтте:
– Бер айлыктан алып аннан өлкәнрәк яшьтәге исраиллеләрнең беренче булып туган ир-ат затларын исәпкә ал һәм аларның санын исемнәре буенча яз.
41 Мин – Раббы, Минем өчен исраиллеләрдә беренче булып туганнарның һәммәсе урынына левиләрне ал. Исраиллеләрнең хайваннары арасыннан да, барча беренче булып туганнары урынына, левиләрнекен ал.
42 Муса, Раббы ничек әмер биргән булса, шулай эшләде: исраиллеләрдә беренче булып туганнарның һәммәсен исәпкә алды.
43 Исемнәре буенча бер айлыктан алып аннан өлкәнрәк яшьтәге беренче булып туган барлык ир-атларның саны егерме ике мең ике йөз җитмеш өч кеше булды.
44 Раббы Мусага әйтте:
45 – Исраиллеләрдә беренче булып туганнарның һәммәсе урынына левиләрне ал; һәм исраиллеләрнең хайваннары урынына да левиләрнекен ал. Мин – Раббы, һәм левиләр Минеке булсыннар.
46 Исраиллеләрнең беренче булып туган ир-атларның саны левиләр санынннан ике йөз җитмеш өч кешегә артык булды. Шушы артык ике йөз җитмеш өч кеше өчен йолым түләнергә тиеш.
47 Рәсми бәя буенча, кеше башына бишәр шәкыл* көмеш ал. Бер шәкылда егерме гера исәпләнә.
48 Левиләрдән артык булган исраиллеләрнең беренче туганнары өчен йолым итеп алынган көмешне Һарунга һәм аның угылларына бир.
49 Муса, левиләр санынннан артык булганнардан китерелгән йолым көмешен алып,
50 исраиллеләрнең беренче булып туганнарыннан, рәсми бәя буенча, бер мең өч йөз алтмыш биш шәкыл көмеш җыйды.
51 Шуннан соң Муса, Раббы ничек әмер иткән булса, көмешне Һарунга һәм аның угылларына бирде.

*Коһат угылларының вазифалары*

4
1 Раббы Мусага һәм Һарунга әйтте:
2 – Леви угыллары арасыннан Коһат угылларын кабиләләре, гаиләләре буенча исәпкә ал.
3 Изге чатырда хезмәт итү өчен яраклы, утыз яшьтән алып илле яшькә кадәр булганнарның һәммәсен дә исәпкә ал.
4 Коһат угылларының Изге чатырда башкарачак хезмәте: чатырдагы иң изге әйберләрне күтәреп йөртү.
5 Тукталу урынынннан

* 3:47 *Шәкыл* – 10 грамм чамасы.

юлга кузгалган вакытта, Һарун һәм аның угыллары, чатырга керәп, боерыклар сандыгы алдындагы пәрдәне алсыннар һәм аның белән сандыкны капласыннар. 6 Аның өстенә диңгез филе тиресеннән эшләнгән япма япсыннар, аны йоннан тукылган зәңгәр җәймә белән каплап, күтәреп йөртү өчен колгаларын тыгып куйсыннар.

7 Икмәк бүләге өстәле өстенә йоннан тукылган зәңгәр җәймә япсыннар, аның өстенә савыт-саба һәм табакларны, тәлинкә һәм шәраб бүләген тәкъдим итү өчен касәләрне куйсыннар. Өстәл өстендә һәрвакыттагыча икмәк торырга тиеш. 8 Һәм аларның өстенә кызыл төстәге җәймә япсыннар; аны диңгез филе тиресеннән эшләнгән япма белән каплап, күтәреп йөртү өчен колгаларын тыгып куйсыннар.

9 Йоннан тукылган зәңгәр җәймә алып, яктылык бирә торган шәмдәлне һәм аның яктырткычларын, филтә кыскычын һәм көл җыю өчен улакларны, эшләгәндә файдаланыла торган зәйтүн мае савытларын япсыннар. 10 Шәмдәл һәм аның барлык әсбапларын диңгез филе тиресеннән эшләнгән япма белән каплап, аны авыр әйберләр йөртү өчен агачтан эшләнгән җайланма өстенә куйсыннар.

11 Алтын мәзбәх* өстенә йоннан тукылган зәңгәр җәймә ябып, аны диңгез филе тиресеннән эшләнгән япма белән капласыннар, күтәреп йөртү өчен колгаларын тыгып куйсыннар.

12 Изге бүлмәдә хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган барлык нәрсәләрне йоннан тукылган зәңгәр җәймәгә төрсеннәр һәм аларны диңгез филе тиресеннән эшләнгән япма белән каплап, авыр әйберләр йөртү өчен агачтан эшләнгән җайланма өстенә куйсыннар.

13 Һарун һәм аның угыллары мәзбәхне, көленнән тазартып, җете кызыл җәймә белән капласыннар. 14 Һәм мәзбәхтә хезмәт күрсәтү өчен кулланыла торган барлык әсбапларны: майлы көлне җыю өчен улакларны, чәнечкеләрне, көрәкләрне, кан бөркү касәләрен мәзбәх өстенә куйсыннар һәм аны диңгез филе тиресеннән эшләнгән япма белән каплап, күтәреп йөртү өчен колгаларын тыгып куйсыннар.

15 Тукталу урыныннан юлга кузгалган вакытта, Һарун һәм аның угыллары Изге бүлмә әйберләрен, аның барлык әсбапларын каплап бетергәч, аларны күтәреп бару өчен Коһат угыллары килсен. Әмма алар изге әйберләргә кагылырга тиеш түгел, кагылган очракта, алар үләчәк. Изге чатырның бу әйберләрен Коһат угыллары күтәреп барырга тиеш.

16 Яктырткычлар өчен зәйтүн мае һәм хуш исле сумала, даими икмәк бүләге, сөртү мае, бөтен Изге чатыр һәм аның эчендә булган бар нәрсә, Изге бүлмә һәм аның барлык әсбаплары рухани Һарун угылы Элгазар карамагына тапшырылсын.

---

* 4:11 *Алтын мәзбәх* – хуш исле сумала яндыру урыны.

17 Раббы Муса белән Һарунга әйтте:
18 – Коһат нәселе кабиләләрен левиләр арасыннан юкка чы-
гармагыз. 19 Иң изге әйберләр янына килгәндә үлмәсеннәр, исән
калсыннар өчен, алар белән болай эшләгез: Һарун һәм аның угыл-
лары, Изге бүлмә эченә кереп, аларның һәрберсен үз хезмәтенә
һәм күтәреп барачак йөге янына билгеләргә тиеш. 20 Әмма ко-
һатлылар үзләре, изге әйберләрне каплаган вакытта, бу әйберләр-
гә якын килергә һәм аларны күрергә тиеш түгелләр. Югыйсә, алар
үләчәк.

*Гершон угылларының вазифалары*

21 Раббы Мусага әйтте:
22 – Гаиләләре һәм кабиләләре буенча Гершон угылларын да
исәпкә ал. 23 Утыз яшьтән алып илле яшькә кадәр булган һәм Изге
чатырда хезмәт итү өчен килгәннәрнең һәммәсен исәпкә ал.
24 Гершон кабиләләренең хезмәт иткәндә һәм йөк ташыганда баш-
карачак эшләре түбәндәгеләр: 25 алар чатыр пәрдәләрен һәм Изге
чатыр белән аның каплавычын, аның өстендәге диңгез филе тире-
сеннән эшләнгән каплавычны, Изге чатырга керү урынындагы пәр-
дәне, 26 чатыр һәм мәзбәхне әйләндереп алган ишегалды пәрдәлә-
рен, ишегалдына керү урынындагы пәрдәне, бауларны һәм шулар
янында хезмәт иткәндә кулланыла торган барлык әсбапларны та-
шырга тиеш. Анда башкарыласы барлык эшләрне гершонлылар
үтәргә тиеш. 27 Гершон угылларының бөтен хезмәте, йөк ташумы,
башка эшләрме, Һарун һәм аның угылларының күрсәтмәсе белән
башкарылырга тиеш. Алар ташый торган барлык әйберләрне сак-
лау бурычын аларның үзләренә тапшырыгыз. 28 Гершон угыллары
кабиләләренең Изге чатырда башкарачак хезмәтләре менә шулар.
Алар рухани Һарун угылы Итамарның күзәтүе астында үз вазифа-
ларын башкарачак.

*Мерари угылларының вазифалары*

29 Кабиләләре һәм гаиләләре буенча Мерари угылларын исәпкә
ал. 30 Утыз яшьтән алып илле яшькә кадәр булган һәм Изге ча-
тырда хезмәт итү өчен килгәннәрнең һәммәсен исәпкә ал. 31 Изге
чатырда хезмәт иткәндә йөк ташу буенча аларның вазифалары
түбәндәгедән гыйбарәт: чатырның такталарын, борысларын, бага-
наларын һәм нигезләрен, 32 ишегалдының һәр ягындагы багана-
ларын, нигезләрен, казыкларын, бауларын һәм аларның барлык
кирәк-яракларын алар күтәреп барырга тиеш. Һәр кеше күтәреп
барасы әйберне исемнәре белән билгелә. 33 Мерари угыллары ка-
биләләренең Изге чатырда башкарачак хезмәте менә шул. Алар
рухани Һарун угылы Итамар күзәтүе астында үз вазифаларын баш-
карачак.

*Левиләрнең санын исәпкә алу*

34-35 Муса, Һарун һәм җәмәгатьчелек башлыклары кабиләләре һәм гаиләләре буенча утыз яшьтән алып илле яшькә кадәр булган һәм Изге чатырда хезмәт итү өчен килгән Коһат угылларының һәммәсен исәпкә алдылар.
36 Кабиләләре буенча исәпкә алынганнарның
саны ике мең җиде йөз илле кеше булды.
37 Бу – Коһат кабиләләреннән Изге чатырда хезмәт итәргә тиешлеләрнең саны. Аларны, Раббының Муса аркылы биргән күрсәтмәсе буенча, Муса белән Һарун исәпкә алды.

38-39 Кабиләләре һәм гаиләләре буенча утыз яшьтән алып илле яшькә кадәр булган һәм Изге чатырда хезмәт итү өчен килгән
Гершон угылларының һәммәсе исәпкә алынды.
40 Алар арасыннан кабиләләре һәм гаиләләре буенча исәпкә алынганнарның саны ике
мең алты йөз утыз кеше булды.
41 Бу – Гершон кабиләләреннән Изге чатырда хезмәт итәргә тиешлеләрнең саны. Раббының күрсәтмәсе буенча аларны Муса белән Һарун исәпкә алды.

42-43 Кабиләләре һәм гаиләләре буенча утыз яшьтән алып илле яшькә кадәр булган һәм Изге чатырда хезмәт итү өчен килгән Мерари угылларының һәммәсе исәпкә алынды.
44 Һәм кабиләләре буенча исәпкә алынганнарның саны өч мең ике йөз кеше булды.
45 Болар – Мерари угылларының кабиләләреннән исәпкә алынган кешеләр саны. Аларны, Раббының Муса аркылы биргән күрсәтмәсе буенча, Муса белән Һарун исәпкә алды.

46 Муса белән Һарун һәм Исраил башлыклары барлык левиләрне
кабиләләре һәм гаиләләре буенча исәпкә алдылар.
47-48 Утыз яшьтән алып илле яшькә кадәр булган, хезмәт итү өчен килгән һәм Изге чатырны ташырга тиешле кешеләрнең исәпкә алынган саны
сигез мең биш йөз сиксән кеше булды.
49 Раббының Муса аша биргән күрсәтмәсе буенча, левиләрнең һәркайсы үзенең хезмәтенә һәм ташый торган йөгенә билгеләнде. Алар, Раббының Мусага әмер итүенчә, исәпкә алындылар.

*Шакшы булганнарны тукталу урыныннан читләштерү хакында*

**5**
1 Раббы Мусага әйтте:
2 – Исраиллеләргә шуны боер: барлык йогышлы тире авыруларны, бүлендегә агып* торганнарны һәм мәеткә кагылып шакшыланганнарны тукталу урыныннан сөрсеннәр.
3 Ир кешеме ул, хатын-кызмы, андыйларны тукталу урыныннан сөрегез, алар үзләренең шакшылыклары белән араларында Мин яши торган үзләренең торак урыннарын нәҗесләмәсеннәр.

---

* 5:2 *Бүлендек агу* – тулырак аңлау өчен Левиләр китабының унбишенче бүлеген карагыз.

[4] Исраиллеләр шулай эшләделәр: андый кешеләрне тукталу урыннан сөрделәр. Раббы Мусага ничек әйткән булса, исраиллеләр шулай эшләделәр дә.

*Гаеп өчен йолым түләү турында*

[5] Раббы Мусага әйтте:
[6] – Исраиллеләргә әйт: «Нинди дә булса берәр ир яки берәр ха-
тын икенче бер кешегә каршы гөнаһ кылса, димәк, ул Раббыга
каршы да гөнаһ эш эшли, андый кеше гаепле була. [7] Әлеге кеше
кылган гөнаһын танырга тиеш һәм, кемгә каршы гөнаһ эшләгән
булса, шул кешегә, гаебенә карап, тулысы белән һәм янә шуның
биштән бер өлеше кадәр өстәп, йолым түләргә тиеш. [8] Әгәр ул ке-
ше үлсә, гаебе өчен түләгәнне алучы варисы булмаса, ул чакта йо-
лым Раббыныкы була. Бу йолым, гөнаһ эшләгән кешене гөнаһтан
арындыру өчен бирелгән сарык тәкәсеннән тыш, өстәмә итеп, ру-
ханига бирелергә тиеш. [9] Һәм исраиллеләрнең Раббыга тәкъдим
итә торган барлык изге бүләкләре руханиныкы булачак. [10] Теләсә
кем тарафыннан бирелгән изге бүләкләр аныкы булачак; кем дә кем
руханига нәрсә дә булса бүләк итә икән, барысы да руханиныкы
булачак».

*Хатынның үз иренә тугрылыгын сынау турында*

[11] Раббы Мусага әйтте:
[12] – Исраиллеләргә белдер һәм сөйлә: «Әгәр бер ирнең хатыны,
хыянәт итеп, аңа тугрылыгын бозса, [13] һәм икенче бер ир аның
белән якынлык кылса, һәм бу эш аның иреннән яшереп тотылса,
хатын яшерен рәвештә нәҗесләнсә, әмма хатынга каршы шаһит
булмаса һәм бу хатынның ялган эше фаш ителмәсә, [14] ләкин бу ха-
тынның ирендә аңа карата көнчелек туса һәм хатыны нәҗесләнгән
яки хәтта хатыны нәҗесләнмәгән вакытта да аңардан көнләш-
сә, [15] бу ир үзенең хатынын рухани янына алып барырга тиеш. Ха-
тыны өчен бүләк итеп ул епаның* уннан бер өлеше кадәр арпа
оны алып барсын. Әмма аңа май да салмаска һәм өстенә хуш исле
сумала да куелмаска тиеш, чөнки бу – көнчелек өчен икмәк бүлә-
ге, гөнаһны хәтергә алган бүләк була.
[16] Рухани ул хатынны Раббы алдына китереп бастырырга тиеш.
[17] Рухани, балчык савытка изге су алып, Изге чатыр астыннан ал-
ган туфракны шул суга салсын. [18] Шуннан соң рухани, хатынны
Раббы алдына бастырып, аның чәчен туздырсын һәм кулына хати-
рә бүләген, ягъни көнчелек өчен икмәк бүләген бирсен. Рухани
кулында исә ләгънәт китерә торган ачы су булачак. [19] Рухани, ха-
тынны ант иттертеп, аңа әйтсен: „Әгәр синең белән беркем дә

* 5:15 *Епа* – 10-20 литр чамасы.

якынлык кылмаган булса, син үзең нәҗесләнмәгән һәм иреңә хыянәт итмәгән булсаң, ләгънәтле бу ачы судан газап чикмәссең. [20-21] Әгәр син иреңә хыянәт иткән һәм үзең нәҗесләнгән булсаң, һәм синең белән икенче бер ир якынлык кылган булса (ул чагында рухани хатынны ләгънәт анты белән ант иттерсен), Раббы синең ботыңны шиңдергәндә һәм корсагыңны күбендергәндә, Ул сине үз халкың арасында ләгънәткә дучар итсен. [22] Һәм ләгънәт китерә торган бу су синең корсагыңны күбендерү, ботыңны шиңдерү өчен синең эчеңә керсен".

Шуннан соң хатын: „Амин, амин", – дияргә тиеш.

[23] Шуннан соң рухани бу ләгънәтләрне тире төргәккә язсын һәм аны ачы суда юсын. [24] Ләгънәт китерә торган әлеге ачы суны рухани хатынга эчәргә бирәчәк, бу су аның эченә керәчәк һәм аңа ачы газаплар китерәчәк. [25] Рухани көнчелек өчен икмәк бүләген хатынның кулыннан алып, Раббы алдында селкесен һәм аны мәзбәхкә китерсен. [26] Рухани әлеге хатирә өчен икмәк бүләгеннән бер уч тотырып алсын да аны мәзбәхтә яндырсын, шуннан соң хатынга су эчерсен. [27] Хатынга су эчергәннән соң, әгәр хатын нәҗесле һәм иренә хыянәт иткән булса, әлеге ачы су аңа газап китерәчәк, аның корсагы күперәчәк, боты шиңәчәк, һәм ул хатын үз халкы арасында ләгънәткә дучар ителәчәк. [28] Әгәр хатын нәҗесләнмәгән һәм чиста булса, ул сау-сәламәт калачак һәм балалар тудырачак.

[29] Көнчелек турындагы канун менә шул. Хатын үзенең иренә хыянәт итсә һәм нәҗесләнсә, [30] яки ирендә хатынына карата шик туып, аңарда көнчелек хисе уянса, ул үзенең хатынын Раббы алдына китереп бастырсын һәм шул чагында рухани бу хатынга карата алда әйтелгән бөтен канун нигезендә эш итсен. [31] Һәм ир гөнаһтан азат булачак, ә хатын гаепле булса, ул гөнаһ нәтиҗәсен үзендә йөртәчәк».

*Нәзир* булу хакында*

**6** [1] Раббы Мусага әйтте:
[2] – Исраиллеләргә игълан ит һәм әйт: «Әгәр бер ир яки бер хатын нәзир булу өчен, ягъни үзен Раббыга багышлау өчен, нәзер кылса, [3] бу кеше шәраб һәм каты эчемлек эчүдән тыелырга тиеш. Ул шәраб серкәсе дә, эчемлек серкәсе дә эчмәскә тиеш. Бернинди дә йөзем суы эчәргә тиеш түгел, яңа өлгергән һәм киптерелгән йөзем җимешен дә ашамаска тиеш. [4] Нәзир булган көннәрендә ул йөзем орлыгыннан һәм кабыгыннан әзерләнгән бернинди ризыкны да ашарга тиеш түгел.

[5] Нәзир булган көннәрендә ул чәчен дә кыркырга тиеш түгел. Нәзер кылып, үзен Раббыга багышлаган көннәр тәмамланганга

* *Нәзир* – үзен Аллаһыга багышлаган кеше.

кадәр, ул изге була һәм чәчен үстерергә тиеш. [6] Нәзир буларак,
үзен Раббыга багышлаган көннәрендә, ул мәет янына килергә тиеш
түгел. [7] Үзенең атасы, анасы, ир яки кыз туганы үлсә, ул аларның
мәетләренә якын килеп, үзен нәҗесләмәсен, чөнки аның үзен Ал-
лаһыга багышлау билгесе — аның башында. [8] Нәзир булган барча
көннәрендә ул, изге буларак, Раббыга багышлана.

[9] Әгәр аның янында кинәт кенә берәү үлсә һәм шуның белән
нәзир үзенең башын нәҗесләсә, ул үзенең чистарыну көнендә —
җиденче көндә, чәчен алдырырга тиеш. [10] Ә сигезенче көнне Изге
чатырга керү урыны алдына руханига ике урман күгәрчене яки ике
бала күгәрчен китерергә тиеш. [11] Рухани кошларның берсен гө-
наһ йолу корбаны, икенчесен тулаем яндыру корбаны итеп, аны
мәеткә кагылып пакьсезләнү гөнаһыннан арындыру өчен корбан
итәргә тиеш. Һәм шул көнне ул үзенең башын кабат изгеләнде-
рергә [12] һәм нәзир булган көннәре өчен үзен кабат Раббыга ба-
гышларга тиеш; гаеп йолу корбаны итеп ул бер яшьлек тәкә бәрән
китерергә тиеш. Аның элекке көннәре бушка китә, чөнки Раббыга
багышланган ул көннәре нәҗесләнгән була.

[13] Нәзир булган көннәре тәмамланган вакыттагы канун менә бу:
нәзир булган кеше Изге чатырга керү урынына китерелергә тиеш.
[14-15] Ул, тулаем яндыру корбаны өчен кимчелексез бер яшьтәге тә-
кә бәрән, гөнаһ йолу корбаны өчен кимчелексез бер яштәге сау-
лык бәрән, татулык корбаны өчен кимчелексез бер сарык тәкәсе
һәм иң яхшы бодай онынннан зәйтүн мае кушып пешерелгән бер
кәрзин төче икмәк, май белән майланган төче көлчәләр һәм алар
белән бергә икмәк вә шәраб бүләкләрен Раббыга китерергә тиеш.

[16] Рухани боларны Раббы хозурына китереп, нәзирнең гөнаһ йолу
корбаны белән тулаем яндыру корбанын тәкъдим итәргә тиеш. [17] Ул
сарык тәкәсен, кәрзингә салынган төче икмәкләр белән бергә, та-
тулык корбаны итеп, Раббыга тәкъдим итәргә тиеш. Рухани аның
икмәк бүләге белән шәраб бүләген дә Раббыга тәкъдим итәчәк.

[18] Шуннан соң нәзир Изге чатырга керү урыны алдында үзенең
чәчен кырып алырга һәм кыркылган шул чәчен татулык корбаны
астындагы утка атарга тиеш.

[19] Нәзир чәчен кырып алганнан соң, рухани сарык тәкәсенең
пешерелгән җилкәсен һәм кәрзиннән бер төче икмәк белән бер
төче көлчә алып, аларны нәзир кулына куярга тиеш. [20] Аннары ру-
хани аларны, селки-селки, махсус бүләк итеп Раббы алдына ките-
рергә тиеш. Алар һәм Раббыга селкетелгән күкрәк белән тәкъдим
ителгән бот изге була, һәм бөтенесе руханиныкы. Шуннан соң нә-
зиргә шәраб эчәргә рөхсәт ителә.

[21] Үзен Раббыга багышлап, нәзер кылган нәзиргә бирелгән канун
менә шул. Нәзир булу өчен канун төгәл үтәлергә тиеш. Әгәр нә-
зир нәзер иткәннән артык бүләк бирә алса, алай эшләргә ярый».

*Исраиллеләргә фатиха*

22 Раббы Мусага әйтте:
23 – Һарунга һәм аның угылларына әйт: «Исраиллеләргә менә мондый сүзләр белән изге теләк теләгез:

24 „Раббы сиңа фатихасын бирсен
һәм сине сакласын!
25 Раббы Үзенең йөзе белән сине балкытсын
һәм сиңа шәфкать итсен!
26 Раббы сиңа Үзенең йөзен юнәлтсен
һәм сиңа иминлек бирсен!“»

27 – Минем исемемне исраиллеләргә менә шулай җиткерсеннәр, һәм Мин аларга фатихамны бирәчәкмен.

*Изге чатырны багышлау һәм ыруг башлыкларының бүләкләре*

7 1 Муса, Изге чатырны корып бетергәннән соң, чатырга һәм
аның барлык кирәк-яракларына, мәзбәхкә һәм аның барлык
әсбапларына май сөртте һәм аларны изгеләндерде. 2 Шуннан
соң халык санын исәпкә алганда җитәкчелек иткән Исраил җитәкчеләре, ягъни гаилә башлыклары, ыруг башлыклары бүләкләр алып
килделәр. 3 Алып килгән үз бүләкләрен алар Раббы алдына куйдылар. Бу бүләкләр түбәндәгеләр: өсте каплаулы алты олау һәм унике үгез – бу ике башлыктан бер олау һәм һәр башлыктан бер үгез дигән сүз. Боларны Изге чатыр алдында бүләк иттеләр.

4 Раббы Мусага әйтте:
5 – Син бу бүләкләрне ал, алар Изге чатырда хезмәт башкару өчен кирәк булачак. Аларны, һәрберсенең башкарган хезмәтенә карап, левиләргә бир.

6 Шуннан соң Муса, олауларны һәм үгезләрне алып, аларны левиләргә бирде. 7-8 Ике олау һәм дүрт үгезне, башкарган хезмәтләренә карап, Гершон угылларына һәм дүрт олау белән сигез үгезне, башкарган хезмәтләренә карап, Мерари угылларына тапшырды. Алар рухани Һарун угылы Итамар күзәтүе астында эшләделәр.
9 Әмма Коһат угылларына бернәрсә дә бирмәде, чөнки алар изге әйберләрне җилкәләренә куеп, күтәреп барырга тиеш булдылар.

10 Башлыклар мәзбәхкә май сөрткән көндә дә, мәзбәхне багышлау өчен, бүләкләр алып килделәр һәм үз бүләкләрен мәзбәх алдына куйдылар. 11 Раббы Мусага әйтте:
– Мәзбәхне багышлау өчен һәр көн башлыклардан берсе үзенең бүләкләрен китерсен.

12 Беренче көнне үз бүләкләрен Йәһүдә ыругыннан Амминадаб угылы Нахшон алып килде. 13 Аның бүләкләре түбәндәгеләр: рәсми бәя буенча, йөз утыз шәкыл авырлыгындагы бер көмеш тәлинкә,

җитмеш шәкыл авырлыгындагы бер көмеш касә – бу савытларның икесенә дә икмәк бүләге өчен зәйтүн мае белән аралаштырылган иң яхшы бодай оны тутырылган; [14] хуш исле сумала салын-
ган ун шәкыл авырлыгындагы бер алтын савыт; [15] тулаем яндыру
корбаны өчен бер үгез бозау, бер сарык тәкәсе һәм бер яшьлек бер
тәкә бәрән; [16] гөнаһ йолу корбаны өчен бер кәҗә тәкәсе; [17] һәм та-
тулык корбаны өчен ике үгез, биш сарык тәкәсе, биш кәҗә тәкәсе, бер яшьлек биш тәкә бәрән. Амминадаб угылы Нахшон алып килгән бүләкләр менә шулар.
[18] Икенче көнне Исәсхәр угылларының башлыгы Суар угылы
Нетанел үз бүләкләрен алып килде. [19] Аның китергән бүләкләре
түбәндәгеләр: рәсми бәя буенча, йөз утыз шәкыл авырлыгындагы бер көмеш тәлинкә, җитмеш шәкыл авырлыгындагы бер көмеш касә – бу савытларның икесенә дә икмәк бүләге өчен зәйтүн мае белән аралаштырылган иң яхшы бодай оны тутырылган; [20] хуш исле
сумала салынган ун шәкыл авырлыгындагы бер алтын савыт; [21] ту-
лаем яндыру корбаны өчен бер үгез бозау, бер сарык тәкәсе һәм бер
яшьлек бер тәкә бәрән; [22] гөнаһ йолу корбаны өчен бер кәҗә тәкә-
се; [23] татулык корбаны өчен ике үгез, биш сарык тәкәсе, биш кәҗә тәкәсе, бер яшьлек биш тәкә бәрән. Суар угылы Нетанел алып килгән бүләкләр менә шулар.
[24] Өченче көнне Зәбулун угылларының башлыгы Хелон угылы Элиаб үз бүләкләрен алып килде. [25] Аның бүләкләре түбәндәгеләр: рәсми
бәя буенча, йөз утыз шәкыл авырлыгындагы бер көмеш тәлинкә, җитмеш шәкыл авырлыгындагы бер көмеш касә – бу савытларның икесенә дә икмәк бүләге өчен зәйтүн мае белән аралаштырылган иң
яхшы бодай оны тутырылган; [26] хуш исле сумала салынган ун шәкыл
авырлыгындагы бер алтын савыт; [27] тулаем яндыру корбаны өчен бер
үгез бозау, бер сарык тәкәсе һәм бер яшьлек бер тәкә бәрән; [28] гө-
наһ йолу корбаны өчен бер кәҗә тәкәсе; [29] татулык корбаны өчен
ике үгез, биш сарык тәкәсе, биш кәҗә тәкәсе һәм бер яшьлек биш тәкә бәрән. Хелон угылы Элиаб алып килгән бүләкләр менә шулар.
[30] Дүртенче көнне Рубин угылларының башлыгы Шедур угылы
Элисур үз бүләкләрен алып килде. [31] Аның бүләкләре түбәндәгеләр:
рәсми бәя буенча, йөз утыз шәкыл авырлыгындагы бер көмеш тәлинкә, җитмеш шәкыл авырлыгындагы бер көмеш касә – бу савытларның икесенә дә икмәк бүләге өчен зәйтүн мае белән аралаштырылган иң яхшы бодай оны тутырылган; [32] хуш исле сумала
салынган ун шәкыл авырлыгындагы бер алтын савыт; [33] тулаем ян-
дыру корбаны өчен бер үгез бозау, бер сарык тәкәсе һәм бер яшь-
лек бер тәкә бәрән; [34] гөнаһ йолу корбаны өчен бер кәҗә тәкәсе;
[35] татулык корбаны өчен ике үгез, биш сарык тәкәсе, биш кәҗә тәкәсе һәм бер яшьлек биш тәкә бәрән. Шедур угылы Элисур алып килгән бүләкләр менә шулар.

36 Бишенче көнне Шимун угылларының башлыгы Суришаддай
угылы Шелумиел үз бүләкләрен алып килде. 37 Аның бүләкләре тү-
бәндәгеләр: рәсми бәя буенча, йөз утыз шәкыл авырлыгындагы
бер көмеш тәлинкә, җитмеш шәкыл авырлыгындагы бер көмеш
касә – бу савытларның икесенә дә икмәк бүләге өчен зәйтүн мае
белән аралаштырылган иң яхшы бодай оны тутырылган; 38 хуш исле
сумала салынган ун шәкыл авырлыгындагы бер алтын савыт; 39 ту-
лаем яндыру корбаны өчен бер үгез бозау, бер сарык тәкәсе һәм бер
яшьлек бер тәкә бәрән; 40 гөнаһ йолу корбаны өчен бер кәҗә тәкә-
се; 41 татулык корбаны өчен ике үгез, биш сарык тәкәсе, биш кә-
җә тәкәсе, бер яшьлек биш тәкә бәрән. Суришаддай угылы Шелу-
миел алып килгән бүләкләр менә шулар.
42 Алтынчы көнне Гәд угылларының башлыгы Дегуил угылы
Эльясаф үз бүләкләрен алып килде. 43 Аның бүләкләре түбәндәге-
ләр: рәсми бәя буенча, йөз утыз шәкыл авырлыгындагы бер кө-
меш тәлинкә, җитмеш шәкыл авырлыгындагы бер көмеш касә –
бу савытларның икесенә дә икмәк бүләге өчен зәйтүн мае белән
аралаштырылган иң яхшы бодай оны тутырылган; 44 хуш исле су-
мала салынган ун шәкыл авырлыгындагы бер алтын савыт; 45 тула-
ем яндыру корбаны өчен бер үгез бозау, бер сарык тәкәсе һәм бер
яшьлек бер тәкә бәрән; 46 гөнаһ йолу корбаны өчен бер кәҗә тәкә-
се; 47 татулык корбаны өчен ике үгез, биш сарык тәкәсе, биш кәҗә
тәкәсе, бер яшьлек биш тәкә бәрән. Дегуил угылы Эльясаф алып
килгән бүләкләр менә шулар.
48 Җиденче көнне Эфраим угылларының башлыгы Аммиһуд угы-
лы Элишама үз бүләкләрен алып килде. 49 Аның бүләкләре түбән-
дәгеләр: рәсми бәя буенча, йөз утыз шәкыл авырлыгындагы бер кө-
меш тәлинкә, җитмеш шәкыл авырлыгындагы бер көмеш касә – бу
савытларның икесенә дә икмәк бүләге өчен зәйтүн мае белән ара-
лаштырылган иң яхшы бодай оны тутырылган; 50 хуш исле сумала
салынган ун шәкыл авырлыгындагы бер алтын савыт; 51 тулаем ян-
дыру корбаны өчен бер үгез бозау, бер сарык тәкәсе һәм бер яшь-
лек бер тәкә бәрән; 52 гөнаһ йолу корбаны өчен бер кәҗә тәкәсе;
53 татулык корбаны өчен ике үгез, биш сарык тәкәсе, биш кәҗә тә-
кәсе, бер яшьлек биш тәкә бәрән. Аммиһуд угылы Элишама алып
килгән бүләкләр менә шулар.
54 Сигезенче көнне Менашше угылларының башлыгы Педаһсур
угылы Гәмәлиел үз бүләкләрен алып килде. 55 Аның бүләкләре тү-
бәндәгеләр: рәсми бәя буенча, йөз утыз шәкыл авырлыгындагы
бер көмеш тәлинкә, җитмеш шәкыл авырлыгындагы бер көмеш
касә – бу савытларның икесенә дә икмәк бүләге өчен зәйтүн мае
белән аралаштырылган иң яхшы бодай оны тутырылган; 56 хуш ис-
ле сумала салынган ун шәкыл авырлыгындагы бер алтын савыт;
57 тулаем яндыру корбаны өчен бер үгез бозау, бер сарык тәкәсе һәм

бер яшьлек бер тәкә бәрән; 58 гөнаһ йолу корбаны өчен бер кәҗә тәкәсе; 59 татулык корбаны өчен ике үгез, биш сарык тәкәсе, биш кәҗә тәкәсе, бер яшьлек биш тәкә бәрән. Педаһсур угылы Гамалиел алып килгән бүләкләр менә шулар.

60 Тугызынчы көнне Беньямин угылларының башлыгы Гидеони угылы Абидан үз бүләкләрен алып килде. 61 Аның бүләкләре түбәндәгеләр: рәсми бәя буенча, йөз утыз шәкыл авырлыгындагы бер көмеш тәлинкә, җитмеш шәкыл авырлыгындагы бер көмеш касә – бу савытларның икесенә дә икмәк бүләге өчен зәйтүн мае белән аралаштырылган иң яхшы бодай оны тутырылган; 62 хуш исле сумала салынган ун шәкыл авырлыгындагы бер алтын савыт;
63 тулаем яндыру корбаны өчен бер үгез бозау, бер сарык тәкәсе һәм бер яшьлек бер тәкә бәрән; 64 гөнаһ йолу корбаны өчен бер кәҗә тәкәсе; 65 татулык корбаны өчен ике үгез, биш сарык тәкәсе, биш кәҗә тәкәсе, бер яшьлек биш тәкә бәрән. Гидеони угылы Абидан алып килгән бүләкләр менә шулар.

66 Унынчы көнне Дан угылларының башлыгы Аммишаддай угылы Ахигызыр үз бүләкләрен алып килде. 67 Аның бүләкләре түбәндәгеләр: рәсми бәя буенча, йөз утыз шәкыл авырлыгындагы бер көмеш тәлинкә, җитмеш шәкыл авырлыгындагы бер көмеш касә – бу савытларның икесенә дә икмәк бүләге өчен зәйтүн мае белән аралаштырылган иң яхшы бодай оны тутырылган; 68 хуш исле сумала салынган ун шәкыл авырлыгындагы бер алтын савыт; 69 тулаем яндыру корбаны өчен бер үгез бозау, бер сарык тәкәсе һәм бер яшьлек бер тәкә бәрән; 70 гөнаһ йолу корбаны өчен бер кәҗә тәкәсе; 71 татулык корбаны өчен ике үгез, биш сарык тәкәсе, биш кәҗә тәкәсе, бер яшьлек биш тәкә бәрән. Аммишаддай угылы Ахигызыр алып килгән бүләкләр менә шулар.

72 Унберенче көнне Ашир угылларының башлыгы Өхрән угылы Пагиел үз бүләкләрен алып килде. 73 Аның бүләкләре түбәндәгеләр: рәсми бәя буенча, йөз утыз шәкыл авырлыгындагы бер көмеш тәлинкә, җитмеш шәкыл авырлыгындагы бер көмеш касә – бу савытларның икесенә дә икмәк бүләге өчен зәйтүн мае белән аралаштырылган иң яхшы бодай оны тутырылган; 74 хуш исле сумала салынган ун шәкыл авырлыгындагы бер алтын савыт; 75 тулаем яндыру корбаны өчен бер үгез бозау, бер сарык тәкәсе һәм бер яшьлек бер тәкә бәрән; 76 гөнаһ йолу корбаны өчен бер кәҗә тәкәсе;
77 татулык корбаны өчен ике үгез, биш сарык тәкәсе, биш кәҗә тәкәсе, бер яшьлек биш тәкә бәрән. Өхрән угылы Пагиел алып килгән бүләкләр менә шулар.

78 Уникенче көнне Нәфтали угылларының башлыгы Энан угылы Ахира үз бүләкләрен алып килде. 79 Аның бүләкләре түбәндәгеләр: рәсми бәя буенча, йөз утыз шәкыл авырлыгындагы бер көмеш тәлинкә, җитмеш шәкыл авырлыгындагы бер көмеш касә – бу

савытларның икесенә дә икмәк бүләге өчен зәйтүн мае белән ара-
лаштырылган иң яхшы бодай оны тутырылган; [80] хуш исле сумала
салынган ун шәкыл авырлыгындагы бер алтын савыт; [81] тулаем ян-
дыру корбаны өчен бер үгез бозау, бер сарык тәкәсе һәм бер яшь-
лек бер тәкә бәрән; [82] гөнаһ йолу корбаны өчен бер кәҗә тәкәсе;
[83] татулык корбаны өчен ике үгез, биш сарык тәкәсе, биш кәҗә тә-
кәсе, бер яшьлек биш тәкә бәрән. Энан угылы Ахира алып килгән
бүләкләр менә шулар.

[84] Мәзбәхне багышлау өчен аңа май сөрткән көндә, исраилле-
ләрнең башлыклары китергән бүләкләр түбәндәгеләр: унике көмеш
тәлинкә, унике көмеш касә, унике алтын савыт. [85] Һәр тәлинкәдә
йөз утыз шәкыл көмеш һәм һәр касәдә җитмеш шәкыл көмеш;
димәк, рәсми бәя буенча хисаплаганда, ул савытлардагы барлык кө-
меш ике мең дүрт йөз шәкыл булды. [86] Хуш исле сумала салынган
алтын савытлар унике, рәсми бәя буенча, һәр савытның авырлыгы
ун шәкыл; шулай итеп, бөтен савытларның алтыны йөз егерме
шәкыл булды. [87] Тулаем яндыру корбаны өчен унике үгез бозау,
унике сарык тәкәсе, бер яшьлек унике тәкә бәрән һәм алар белән
бергә икмәк бүләге, гөнаһ йолу корбаны өчен унике кәҗә тәкәсе;
[88] татулык корбаны өчен барлыгы егерме дүрт үгез, алтмыш сарык
тәкәсе, алтмыш кәҗә тәкәсе һәм бер яшьлек алтмыш тәкә бәрән.
Мәзбәхкә май сөрткәннән соң, аны багышлау өчен китерелгән бү-
ләкләр менә шулар.

[89] Муса Раббы белән сөйләшү өчен Изге чатырга кергәндә, бое-
рыклар сандыгындагы гөнаһ йолу урыны өстендә ике керубим* су-
рәте арасыннан үзенә эндәшкән тавыш ишетә, һәм бу тавыш аның
белән сөйләшә иде.

*Яктырткычлар хакында*

**8** [1] Раббы Мусага әйтте:
[2] – Һарунга белдер һәм әйт: «Җиде яктырткычны яндырган
вакытта, алар шәмдәл алдындагы урынны яктыртырга тиеш».
[3] Һарун шулай эшләде дә: Раббының Мусага әмер итүенчә, як-
тырткычларны яктысы шәмдәл алдындагы урынга төшәрлек итеп
урнаштырды. [4] Шәмдәлнең төзелеше мондый: ул, төбеннән алып
өстендәге чәчәкләренә кадәр, алтыннан чүкеп эшләнде. Шәмдәл
Раббы Мусага күрсәткән үрнәк буенча ясалды.

*Левиләрне исраиллеләрдән аеру турында*

[5] Раббы Мусага әйтте:
[6] – Исраиллеләр арасыннан левиләрне ал да аларны чистарт.
[7] Аларны чистарту өчен болай эшлә: аларга шакшылыкны пакьләү

---

* [7:89] *Керубим* – Раббы хезмәтендәге рухи зат.

суы сип, һәм алар үз тәннәрен пәке белән кырсыннар, киемнәрен
юсыннар һәм үзләрен чистартсыннар. [8] Шуннан соң бер үгез бозау
һәм аның белән бергә, икмәк бүләге буларак, зәйтүн мае белән
аралаштырылган иң яхшы бодай оны китерсеннәр; син икенче
үгез бозауны гөнаһ йолу корбаны итеп ал. [9] Һәм левиләрне Изге
чатыр алдына алып кил дә Исраилнең барлык җәмәгатьчелеген
җый. [10] Левиләрне Раббы алдына алып кил, исраиллеләр алар өс-
тенә үз кулларын куйсыннар. [11] Һарун левиләрне, исраиллеләрнең
махсус бүләге буларак, Раббыга багышлаячак. Шуннан соң леви-
ләр Раббыга хезмәт күрсәтү өчен әзер булырлар. [12] Левиләр кулла-
рын үгез бозаулар башына куйгач, левиләрне гөнаһларыннан арын-
дыру өчен, гөнаһ йолу корбаны булган үгез бозауны һәм икенче-
сен, тулаем яндыру корбаны буларак, Раббыга китер. [13] Левиләрне
Һарун һәм аның угыллары алдына китереп бастыр да, махсус бү-
ләк буларак, Раббыга багышла. [14] Менә шулай итеп левиләрне,
Минеке булсыннар өчен, исраиллеләрдән аерып ал.
[15] – Левиләрне чистартканнан һәм махсус бүләк буларак Раббыга
багышлаганнан соң, алар, хезмәт итү өчен, Изге чатырга киләчәк-
ләр. Чөнки алар – исраиллеләр арасыннан тулаем Миңа бирел-
гәннәре. [16] Исраиллеләр арасыннан барлык хатыннардан беренче
булып туганнар урынына Мин аларны Үземә алам. [17] Исраиллеләр
арасында, кешеме ул, хайванмы, беренче булып туганнар барысы
да Минеке. Чөнки Мисыр җирендә барлык беренче булып туган-
нарны юкка чыгарган көндә, Мин аларны Үзем өчен изге иттем.
[18] Һәм Мин исраиллеләр арасыннан барлык беренче булып туганнар
урынына левиләрне алдым. [19] Исраиллеләр Изге бүлмәгә якын кил-
гән вакытта, аларга үләт булмасын дип, Изге чатырда хезмәт итү
һәм исраиллеләр өчен гөнаһ йолу корбаны итү өчен, бөтен исра-
иллеләр арасыннан левиләрне, бүләк буларак, Һарунга һәм аның
угылларына тапшырдым.
[20] Левиләр хакында Раббы Мусага ничек әмер иткән булса,
Муса белән Һарун һәм Исраилнең бөтен җәмәгатьчелеге нәкъ
шулай эшләделәр. [21] Левиләр үзләрен чистартып, кием-салым-
нарын юдылар; Һарун аларны, махсус бүләк буларак, Раббыга
багышлады; һәм аларны пакьләү өчен, гөнаһтан арындыру йо-
ласын башкарды. [22] Шуннан соң левиләр, Һарун һәм аның угыл-
ларына хезмәт итү өчен, Изге чатырга керделәр. Левиләр хакында
Раббы Мусага ничек әмер иткән булса, алар нәкъ шулай эшлә-
деләр.
[23] Раббы Мусага әйтте:
[24] – Левиләр хакындагы кагыйдә менә шушы: егерме биш яшь-
тән алып аннан өлкәнрәк булган левиләр Изге чатырда үзләренә
тапшырылган хезмәтне башкарырга тиешләр. [25] Илле яшь тулгач,
алар хезмәт итүдән туктарга һәм эшләмәскә тиеш. [26] Шуннан соң

алар Изге чатырда хезмәт башкаручы туганнарына ярдәм итсен-
нәр, әмма эшләмәсеннәр. Левиләрнең хезмәт вазифаларын билге-
ләгәндә нәкъ менә шулай эшлә.

*Коткарылу бәйрәме хакында өстәмә кагыйдәләр*

9 [1] Исраиллеләр Мисыр жиреннән чыгарылганның икенче елы-
ның беренче аенда Синай чүлендә Раббы Мусага әйтте:
[2] – Исраиллеләр Коткарылу бәйрәмен билгеләнгән вакытта бәй-
рәм итсеннәр. [3] Шушы айның ундүртенче көнендә кич белән, билгелән-
гән вакытта, барлык кагыйдәләр һәм кануннар буенча бәйрәм итегез.
[4] Муса исраиллеләргә Коткарылу бәйрәмен үтәргә кушты. [5] Кот-
карылу бәйрәмен Синай чүлендә беренче айның ундүртенче кө-
нендә кичен бәйрәм иттеләр. Раббы Мусага ничек әмер иткән
булса, исраиллеләр нәкъ шулай эшләделәр.
[6] Берничә кеше үлгән кеше мәетенә кагылып нәҗесләнделәр
һәм ул көнне Коткарылу бәйрәмен үткәрә алмадылар. Алар Муса
белән Һарун янына килеп сорадылар:
[7] – Үлгән кеше мәетенә кагылып без үзебезне нәҗесләдек, бил-
геләнгән вакытта исраиллеләр белән бергә Раббыга бүләк тәкъдим
итүдән безне ни өчен мәхрүм иттегез?
[8] Муса аларга әйтте:
– Туктагыз, башта мин сезнең хакта Раббының нәрсә әмер итә-
чәген тыңлап карыйм.
[9] Раббы Мусага әйтте:
[10] – Исраиллеләргә әйт: «Әгәр арагыздан яки нәселегездән берәү
мәеткә кагылып нәҗесләнә яисә озак вакыт юлда була икән, андый
кешеләр дә Коткарылу бәйрәмен бәйрәм итәргә тиеш. [11] Андый ке-
шеләр Коткарылу бәйрәмен икенче айның ундүртенче көнендә кич
белән бәйрәм итсеннәр. Алар тәкә бәрән белән төче икмәкләр һәм
ачы үләннәр ашасыннар. [12] Икенче көннең иртәсенә кадәр ул азык-
лардан бернәрсә дә калдырмасыннар, тәкә бәрәннең сөякләрен ват-
масыннар. Алар Коткарылу бәйрәмен, аның барлык кагыйдәләре
буенча, бәйрәм итәргә тиеш. [13] Ә инде нәҗесләнмәгән һәм юлда
булмаган кеше Коткарылу бәйрәмен бәйрәм итмәсә, андый кеше-
нең җаны үз халкы арасыннан юкка чыгарылачак; чөнки ул билге-
ләнгән вакытта Раббыга бүләк китермәгән була. Андый кеше үзенең
гөнаһын үзендә йөртәчәк. [14] Сезнең арагызда читтән килгән берәр
кеше Коткарылу бәйрәмен үткәрергә теләсә, ул да кагыйдәләр һәм
кануннар буенча бәйрәм итәргә тиеш. Читтән килгән кеше өчен дә,
җирле кеше өчен дә кагыйдә бертөрле».

*Изге чатыр өстендә болыт*

[15] Боерыклар куелган чатыр корылган көнне, аны болыт капла-
ды. Кичтән алып иртәнгә кадәр болыт, ут күренеше кебек, чатыр

өстендә торды. 16 Һәм һәрвакыт шулай булды: чатырны болыт кап-
лый торды, ә төнлә ул ут күренеше кебек булды. 17 Болыт Изге ча-
тыр өстеннән күтәрелә башлаганда, исраиллеләр юлга чыктылар,
ә болыт туктаган урында алар да, чатырларын корып, ял иттеләр.
18 Исраиллеләр Раббының күрсәтмәсе буенча юлга чыктылар һәм,
Аның күрсәтмәсе белән, чатырларын корып, ял иттеләр. Болыт ча-
тыр өстендә торган вакытта, алар да туктап торды. 19 Болыт чатыр
өстендә озак торган вакытта, исраиллеләр дә, Раббы әмерен үтәп,
юлга чыкмадылар. 20 Кайвакыт болыт чатыр өстендә берничә көн
торды. Мондый очракта, Раббы күрсәтмәсе буенча, исраиллеләр
дә туктап тордылар һәм, Раббы күрсәтмәсе буенча, кузгалып юлга
чыктылар. 21 Кайвакыт болыт чатыр өстендә кичтән алып иртәнгә
кадәр генә торды, болыт иртә белән күтәрелеп кузгалуга, алар да
кузгалып юлга чыктылар. Болыт көндез дә, төнлә дә күтәрелеп куз-
галганда, алар да кузгалып юлга чыктылар. 22 Ике көн яисә бер ай,
яки бер ел буе болыт чатыр өстендә туктап торган вакытта исраил-
леләр дә шунда туктап тордылар һәм юлга чыкмадылар, ә инде бо-
лыт күтәрелеп кузгалуга, алар да кузгалып юлга чыктылар. 23 Алар
Раббының күрсәтмәсе буенча туктап тордылар һәм Аның күрсәт-
мәсе буенча юлга чыктылар. Раббының Муса аша биргән күрсәтмә-
се буенча, алар Аның әмеренә буйсындылар.

*Көмеш быргылар хакында*

**10** 1 Раббы Мусага әйтте:
2 – Көмештән ике быргы ясат. Алар җәмәгатьчелекне җыю
һәм гаскәрләрне юлга озату өчен хезмәт итәр. 3 Быргы-
лар кычкырткан вакытта, бөтен җәмәгатьчелек синең янга – Изге
чатырга керү урыны алдына җыелачак. 4 Бер генә быргы кычкырт-
са, синең янга җитәкчеләр, ягъни Исраил гаскәрләренең башлык-
лары җыелыр. 5 Кузгалу турында быргы кычкыртканда, көнчыгыш
тарафта урнашкан ыруглар кузгалып китәр. 6 Быргы кузгалу турында
икенче мәртәбә кычкыртканда, көньяк тарафта урнашкан ыруглар
кузгалып китәр. Аларны юлга чыгара башлаганда, кузгалу турында
тавыш бирелер. 7 Җыелышны чакырырга кирәк булганда, быргылар-
ны кычкыртыгыз, ә кузгалу турында тавыш бирмәгез.
8 – Быргыларны Һарун угыллары – руханилар – кычкыртырга тиеш.
Бу сезнең өчен нәселдән нәселгә күчеп килә торган мәңгелек кагыйдә.
9 Үз җирегездә сезгә һөҗүм итүче дошманга каршы сугышка чыкканда,
кузгалу турында быргылар кычкыртыгыз. Шул чакта сез Раббы Алла-
гыз тарафыннан искә алынырсыз һәм дошманнарыгыздан котылып
калырсыз. 10 Шатлыклы көннәрегездә һәм билгеләнгән бәйрәмнәре-
гездә, яңа ай туган көннәрдә, тулаем яндыру һәм татулык корбанна-
рыгызны тәкъдим иткәндә, быргылар кычкыртыгыз. Алар Аллагыз
алдында сезне искә төшерү булыр. Мин – Раббы, сезнең Аллагыз.

### *Исраиллеләрнең Синай чүленнән юлга чыгуы*

[11] Икенче елның икенче аенда, икенче айның егерменче көнен-
дә боерыклар куелган чатыр өстеннән болыт күтәрелде. [12] Шуннан
соң исраиллеләр Синай чүленнән юлга чыктылар, һәм болыт Паран
чүлендә туктады. [13] Алар, Раббының Муса аша биргән күрсәтмәсе
буенча, беренче мәртәбә юлга чыгып киттеләр.
[14] Беренче булып, хәрби төркемнәре буенча, Йәһүдә угыллары
гаскәре үзләренең байрагы астында кузгалып китте. Йәһүдә ыругы
хәрби төркеменең яубашы Амминадаб угылы Нахшон иде. [15] Исәс-
хәр ыругы хәрби төркеменең яубашы Суар угылы Нетанел иде.
[16] Зәбулун ыругы хәрби төркеменең яубашы Хелон угылы Элиаб
иде. [17] Изге чатыр сүтеп алынды, Гершон һәм Мерари угыллары,
чатырны күтәреп, юлга чыктылар.
[18] Аннары, хәрби төркемнәре буенча, Рубин гаскәре үзләренең
байрагы астында кузгалып китте. Рубин ыругы хәрби төркеменең
яубашы Шедур угылы Элисур иде. [19] Шимун ыругы хәрби төркеме-
нең яубашы Суришаддай угылы Шелумиел иде. [20] Гәд ыругы хәрби
төркеменең яубашы Дегуил угылы Эльясаф иде. [21] Алардан соң
изге әйберләрне күтәреп баручы коһатлылар кузгалып китте. Изге
чатыр алар килгәнгә кадәр үк корып куелган иде инде.
[22] Аннан соң, хәрби төркемнәре буенча, Эфраим угыллары гаскә-
ре үзләренең байрагы астында кузгалып китте. Эфраим ыругы хәрби
төркеменең яубашы Аммиһуд угылы Элишама иде. [23] Менашше ыру-
гы хәрби төркеменең яубашы Педаһсур угылы Гәмәлиел иде. [24] Бень-
ямин ыругы хәрби төркеменең яубашы Гидеони угылы Абидан иде.
[25] Барлык гаскәрләрнең иң соңгысы булып, хәрби төркемнәре бу-
енча, Дан угыллары гаскәре үзләренең байрагы астында кузгалып
китте. Дан ыругы хәрби төркеменең яубашы Аммишаддай угылы
Ахигызыр иде. [26] Ашир ыругы хәрби төркеменең яубашы Өхрән угы-
лы Пагиел иде. [27] Нәфтали ыругы хәрби төркеменең яубашы Энан
угылы Ахира иде. [28] Гаскәрләре буенча исраиллеләрнең юлга чыгу
тәртибе менә шундый иде.
[29] Муса үзенең каенатасы мидьянлы Регуил угылы Хобабка әйтте:
– Без Раббының «Ул җирне сезгә бирермен» дигән урынына бару
өчен юлга чыгабыз. Безнең белән бар, һәм без сиңа яхшылык итәр-
без, чөнки Раббы Исраилгә яхшылыклар вәгъдә итте.
[30] Әмма Хобаб аңа әйтте:
– Бармыйм мин, үз җиремә, туган халкым янына кайтам.
[31] Муса исә аңа:
– Безне калдырып китмә, чөнки син чүлдә чатырларны кая ко-
рырга кирәклеген беләсең, безгә күз-колак булырсың. [32] Безнең бе-
лән бергә барсаң, Раббының безгә күрсәтәчәк барлык яхшылык-
ларын синең белән бүлешербез, – диде.

33 Исраиллеләр Раббы тавыннан өч көнлек юлга чыктылар. Аларга туктау урыны карау өчен, Раббы килешүе сандыгы* өч көнлек юлда алар алдыннан барды. 34 Алар тукталу урыныннан кузгалып киткән вакытта, Раббының болыты көндез алар өстендә булды.

35 Аллаһы сандыгы юлга чыккан саен Муса әйтте:

– Әй, Раббы, күтәрел!
Дошманнарыгыз таралсыннар;
Сине нәфрәт итүчеләр Синең алдыңнан йөгереп барсыннар!

36 Аллаһы сандыгы туктаган саен ул әйтте:

– Әй, Раббы, Исраилнең күп меңләгән халкы янына кире кайт!

*Исраиллеләрнең сукранулары*

**11** 1 Халык үзенең авыр тормышыннан зарланды. Раббы моны ишетте, Аның ачуы кабарды. Алар арасында Раббының уты янды һәм тукталу урынының читләрен ялмап алды. 2 Шуннан соң халык Мусага елап ялварды; Муса Раббыдан дога кылып сорагач, ут сүнде. 3 Һәм бу урынга Табыгыра* дигән исем бирелде, чөнки анда Раббы уты аларның торагын яндырды.

4 Халык арасындагы тәртипсез кешеләр аш талымлый башлады һәм алар белән бергә исраиллеләр дә елап болай диделәр:

– Безне кем ит белән туендырыр?! 5 Без Мисырда вакытта бушлай ашаган балыкларны, кыяр, кавыннарны, ялпак суган, башлы суган һәм сарымсакларны искә төшерәбез. 6 Ә хәзер безнең көчебез бетә*, ашарга бернәрсә дә юк, күз алдыбызда манна* гына.

7 Манна кориандр орлыгы кебек вак, чәергә охшаган иде. 8 Халык, тирә-юньдә йөргәндә, маннаны җыеп, аны тегермән ташында тартты яки киледә төйде дә казанда пешерде, көлчәләр ясады; аның тәме зәйтүн маенда пешерелгән көлчә тәмен хәтерләтә иде. 9 Төнлә, тукталу урыны өстенә чык төшкән вакытта, манна да ява иде.

10 Муса халыкның барлык гаиләләре һәм һәркемнең үз чатырына керү урыны алдында елауларын ишетте. Раббының моңа бик нык ачуы кабарды, Муса да борчуга төште. 11 Муса Раббыга әйтте:

– Ни өчен Син үз хезмәтчеңне газаплыйсың? Ни өчен мин Синең күз алдында мәрхәмәт казанмадым һәм нигә Син бөтен халыкның авырлыгын минем өстемә йөкләдең? 12 Бу халыкны үземнең карынымда мин йөрттемме әллә яисә аны мин тудырдыммы? Ни өчен Син миңа: «Бала караучы баланы күтәреп йөргән кебек, аларның аталарына вәгъдә иткән җиргә алып бару өчен, аларны

---

* 10:33 *Раббы килешүе сандыгы* – ягъни «Аллаһы сандыгы».
* 11:3 *Табыгыра* – «яндыру» мәгънәсендә.
* 11:6 *Көчебез бетә* – яһүдчә нөсхәдә сүзгә-сүз: «безнең җаннарыбыз хәлсезләнә».
* 11:6 *Манна* – «Чыгыш» китабындагы 16:31нче аятьне карагыз.

үзеңнең кочагында йөрт», – дип әйттең? [13] Бу кадәр халыкны ашату өчен мин аларга кайдан ит алыйм? Алар бит: «Безгә ашарга ит бир!» – дип миннән елап сорыйлар. [14] Мин барлык бу халыкны ялгызым гына күтәреп бара алмыйм бит инде, чөнки ул минем өчен бик авыр. [15] Әгәр Син миңа шулай эшлисең икән, мин Синең күз алдында мәрхәмәт казанган булсам, ул чагында Синең мине үтерүең яхшырак булыр, һәм мин үземнең бәхетсезлегемне күрмәм.

*Мусаның җитмеш аксакалны сайлавы*

[16] Раббы Мусага әйтте:

– Миңа халыкның җитәкчеләре һәм түрәләре дип исәпләнгән Исраил аксакалларыннан җитмеш кешене җый һәм аларны Изге чатыр янына алып кил. Алар анда синең белән басып торсыннар.
[17] Шулчак Мин анда төшеп, синең белән сөйләшермен һәм синдә булган Рухның бер өлешен алып, алар өстенә салырмын. Шуннан соң халыкның йөген син ялгызың гына күтәрмәячәксең, аны синең белән бергә алар да күтәрәчәкләр.

[18] – Халыкка әйт: «Иртәгәсе көнгә үзегезне пакьләгез, һәм сез ит ашаячаксыз. Чөнки сез: „Кем безгә ит ашатыр? Мисырда безнең хәлебез яхшы иде!“ – дип елап әйттегез, һәм Раббы шуны ишетте. Менә хәзер Раббы сезгә ашарга ит бирәчәк, һәм сез ашаячаксыз.
[19-20] Сез аны бер көн генә, ике көн генә, биш көн генә, ун көн генә һәм егерме көн генә дә түгел, ә бөтен ай буена, борын тишегегездән кире чыкканчы һәм күңелегез болганганчы ашаячаксыз. Чөнки сез үз арагызда булган Раббыны кире кактыгыз һәм: „Ни өчен безгә Мисырдан китәргә кирәк булды?“ – дип, Раббы алдында елап әйттегез».

[21] Муса әйтте:

– Минем яндагы бу халыкның алты йөз мең җәяүле кешесе бар, ә Син: «Мин аларга ит бирәчәкмен һәм алар ай буе ашаячаклар!» – дисең.
[22] Аларны җитәрлек туйдыру өчен, барлык сарык һәм үгезләрне чалыргамы? Аларны туйдыру өчен, диңгездә булган балыкларны тотып бетерикме? Алай да җитмәс.

[23] Раббы Мусага әйтте:

– Әллә Раббының кулы кыска дип уйлыйсыңмы? Сиңа әйткән сүзем тормышка ашармы, юкмы, хәзер күрерсең.

[24] Муса чыгып, Раббы сүзләрен халыкка җиткерде һәм халыкның аксакалларыннан җитмеш кешене җыеп, аларны Изге чатырның әйләнә-тирәсенә бастырды.
[25] Раббы болытта төшеп, аның белән сөйләште һәм, Мусада булган Рухның бер өлешен алып, җитмеш аксакалга бирде. Үзләренә Рух иңгәч, алар пәйгамбәрлек иттеләр, әмма шуннан соң алар тагын пәйгамбәрлек итмәделәр.

26 Җитмеш аксакалның икесе тукталу урынында калды. Берсе-
нең исеме – Элдад, икенчесенеке Медад иде. Алар Изге чатырга
чыкмадылар. Икесенә дә Рух иңеп, пәйгамбәрлек иттеләр. 27 Шул-
вакыт бер яшүсмер килеп, Мусага:
– Элдад белән Медад тукталу урынында пәйгамбәрлек итәләр, –
дип хәбәр салды.
28 Яшүсмер чагыннан ук Мусаның хезмәтчесе булган Нун угылы
Йешуа:
– Әфәндем Муса, аларны туктат! – диде.
29 Ә Муса аңа җавап бирде:
– Әллә син миннән көнләшәсеңме? Раббы Үзенең Рухын Аның
бөтен халкына бирсен, аларның барчасы пәйгамбәрләр булсын!
30 Муса үзе һәм аның белән бергә Исраил аксакаллары тукталу
урынына кире кайттылар.

*Раббыдан бүдәнәләр*

31 Менә Раббы тарафыннан җил күтәрелеп, диңгездән бүдәнәләр
китерелде. Җил бүдәнәләрне тукталу урынының әйләнә-тирәсенә –
аның һәр ягыннан бер көнлек юл кадәр, җирдән ике терсәк* биек-
легендә итеп төшерде. 32 Халык исә шул көнне көн буе һәм тагын
төн буе, шулай ук икенче көнне көн буе бүдәнәләр җыйды. Иң аз
дигәне дә ун хомер* җыйды һәм аларны тукталу урыны әйләнәсе-
нә җәеп таратты. 33 Ит аларның теш арасында булып, әле ашап бе-
терергә дә өлгермәстән, халыкка Раббының ачуы чыкты, һәм Ул
аларга бик көчле үләт җибәрде. 34 Ул урынга Кыйбрут-Һаттава,
ягъни ач күзле кешеләр каберлеге дигән исем бирелде, чөнки анда
ач күзле кешеләрне күмделәр.
35 Халык Кыйбрут-Һаттавадан Хасеротка таба юлга чыкты һәм
шунда житкәч туктады.

*Мириам белән Һарунның шелтәсе*

**12** 1 Мириам белән Һарун Мусаны хәбәш хатынына өйлән-
гәне өчен әрләделәр. 2 Алар әйттеләр:
– Әллә Раббы Муса аша гына сөйләдеме? Ул безнең аша
да сөйләмәдеме?
Раббы моны ишетте.
3 Муса исә дөньядагы барлык кешеләрнең иң тыйнагы иде.
4 Раббы кинәт Мусага, Һарунга һәм Мириамга әйтте:
– Өчегез дә Изге чатырга чыгыгыз.
Өчесе дә Изге чатырга чыктылар. 5 Аннан Раббы болыт багана-
сында төште дә Изге чатырга керү урынында торды һәм Һарун

* 11:31 *Терсәк* – 45 сантиметр чамасы.
* 11:32 *Хомер* – 100-200 литр чамасы.

белән Мириамны чакырды; алар икесе дә килделәр. [6] Раббы аларга
әйтте:

– Минем сүзләремне тыңлагыз:
Сезнең арагызда Раббының пәйгамбәре бар икән,
Мин, Раббы, бары тик күз алдына китереп кенә
Үземне аңа белдерәм,
аның белән төштә сөйләшәм.
7 Әмма хезмәтчем Муса белән Мин алай эшләмим,
чөнки ул Минем бөтен йортымда ышанычлы кеше.
8 Мин аның белән йөзгә-йөз карап,
табышмаклар белән түгел, ә ачык итеп сөйләшәм,
һәм ул Раббы сурәтен күрә.
Алай икән, Минем хезмәтчем Мусаны гаепләргә
Сез ничек курыкмадыгыз?

[9] Аларга Раббының ачуы кабарды, Ул кузгалып китте. [10] Шул-
вакыт болыт чатыр өстеннән күтәрелде, һәм Мириамның гәүдәсе,
кар белән капланган кебек, йогышлы тире авыруы белән капланды.
Һарун Мириамга карады һәм аңарда йогышлы тире авыруын күр-
де. [11] Шулчак Һарун Мусага әйтте:

– Хуҗам минем! Акылсызлык эшләгәнебез һәм гөнаһ кылганы-
быз өчен безне газаплама. [12] Бу хатынны туганда ук гәүдәсенең яр-
тысы черек булып, үле туган бала кебек итмә.

[13] Һәм Муса:

– Әй Аллам, аны савыктырчы! – дип Раббыга ялварды.

[14] Раббы Мусага әйтте:

– Әгәр атасы Мириамның йөзенә төкергән булса, ул җиде көн
буена оялырга тиеш түгел идеме? Шуның өчен ул тукталу уры-
ныннан читтә җиде көн ябып тотылсын, шуннан соң кире кайта-
рылыр.

[15] Мириам тукталу урынынан читтә җиде көн ябып тотылды,
һәм халык, Мириам кайтмый торып, юлга чыкмады.

### *Мусаның Кәнган җиренә тикшерүчеләр җибәрүе*

**13** [1] Шушы хәлдән соң халык Хасероттан юлга кузгалды һәм
Паран чүлендә чатырларын корып туктады. [2] Раббы Му-
сага әйтте:

[3] – Исраиллеләргә Мин бирәчәк Кәнган җирен карау өчен ке-
шеләр җибәр. Һәр ата-баба ыругының башлыклары арасыннан бер
кеше булсын.

[4] Раббының күрсәтмәсе буенча, Муса аларны Паран чүленнән
җибәрде, алар барысы да исраиллеләрнең җитәкчеләре иде. [5] Менә
аларның исемнәре:

Рубин ыругыннан – Зәкүр угылы Шаммуа;

[6] Шимун ыругыннан – Хори угылы Шафат;
[7] Йәһүдә ыругыннан – Ифунни угылы Кәлеб;
[8] Исәсхәр ыругыннан – Йосыф угылы Игәл;
[9] Эфраим ыругыннан – Нун угылы Һошея;
[10] Беньямин ыругыннан – Рафу угылы Палти;
[11] Зәбулун ыругыннан – Соди угылы Гәддиел;
[12] Йосыф угылы Менашше ыругыннан – Суси угылы Гәдди;
[13] Дан ыругыннан – Гемалли угылы Аммиел;
[14] Ашир ыругыннан – Михәил угылы Сетур;
[15] Нәфтали ыругыннан – Вуфси угылы Нахби;
[16] Гәд ыругыннан – Махи угылы Гәвел.
[17] Ул җирне карарга Муса җибәргән кешеләрнең исемнәре менә шулар иде. Муса Нун угылы Һошеяны Йешуа дип атады.
[18] Муса, аларны Кәнган җирен карарга җибәргәндә, әйтте:
– Көньяктагы Нәгеб чүленнән бу илгә барыгыз да андагы тауга
менегез. [19] Ул җирне тикшерегез, ул нинди җир һәм анда нинди
халык яши, халкы көчлеме яки көчсезме, аз санлымы яисә күп
санлымы? [20] Ул халык яши торган җир нинди – яхшымы яисә на-
чармы? Ул халык яши торган шәһәрләр нинди? Алар чатырларда
яшиләрме яисә ныгытмалардамы? [21] Ул җирнең туфрагы нинди?
Уңдырышлымы яки уңдырышсызмы? Анда агачлар үсәме яки үс-миме? Кыю булыгыз һәм ул җирнең җимешләрен алып кайтыгыз.
Бу йөзем өлгергән вакыт иде.
[22] Шуннан соң алар киттеләр һәм, Сыйн чүленнән башлап, Хаматка керү урыны янындагы Рәхубка кадәр, ул җирне тикшерделәр.
[23] Алар әлеге җирнең көньяк өлешенә – Нәгебкә юнәлделәр һәм
Анак угыллары Ахиман, Шешай һәм Талмай яшәгән урынга –
Хебрунга барып җиттеләр. (Хебрун исә Мисыр шәһәре Соганнан
җиде ел элек төзелгән булган.) [24] Аннары Эшкүл* үзәнлегенә төш-
теләр һәм анда йөзем куагыннан бер тәлгәш йөзем өзеп алдылар,
аны ике кеше, колгага беркетеп, күтәреп барды. Шулай ук анар
һәм инҗир агачларының җимешләрен дә өзеп алдылар. [25] Исраил-
леләр анда бер тәлгәш йөзем өзеп алганлыктан, ул урынны Эшкүл
үзәнлеге дип атадылар. [26] Ул җирне үз күзләре белән күргәннән
соң алар, кырык көн үткәч, кире әйләнеп кайттылар.

*Тикшерүчеләрнең хисабы*

[27] Ул җирдән китеп, тикшерүчеләр Паран чүлендәге Кадышка кире әйләнеп кайттылар. Алар Муса белән Һарунга, шулай ук Исраилнең бөтен җәмәгатьчелегенә җавап алып кайттылар, ул җирдән алып кайткан җимешләрне күрсәттеләр [28] һәм Мусага болай
дип сөйләделәр:

* **13:24** *Эшкүл* – яһүдчә «тәлгәш» яки «чүк» мәгънәсендә.

– Без син җибәргән ул җиргә бардык; ул җирдә чынлап та сөт
һәм бал ага икән, менә ул җирнең җимешләре. 29 Әмма ул җирдә
яшәүче халык көчле, шәһәрләре ныгытылган һәм бик зур; без анда
Анак угылларын да күрдек. 30 Амалыклылар ул җирнең көньяк өле-
шендәге Нәгебтә, хиттиләр, йәвүсиләр һәм амориләр тауда, ә кән-
ганиләр исә диңгез буйларында һәм Үрдүн елгасы буйларында яши.
31 Әмма Кәлеб, Муса алдында халыкны тынычландырып, әйтте:
– Ул җиргә барыйк һәм аны басып алыйк, чөнки аңа безнең
көчебез җитәрлек.
32 Ә аның белән бергә барганнар әйттеләр:
– Без ул җирдә яшәүче халыкка каршы бара алмыйбыз, чөнки
алар бездән көчлерәк.
33 Һәм алар үзләре карап кайткан җир турында исраиллеләр ара-
сында яман хәбәр тараттылар:
– Без карап кайткан ул җир үзендә яшәүчеләрне йота икән, һәм
анда яшәүчеләрнең барысы да зур гәүдәлеләр. 34 Без анда нефи-
лимлеләрне дә (Анак угыллары нефилимлеләр нәселенә карый)
күрдек. Алар алдында без чикерткәләр кебек кенә идек. Алар да
безне шундый итеп күрделәр.

*Исраил җәмәгатьчелегенең сукрануы*

**14** 1 Бу хәбәрне ишеткәч, бөтен җәмәгатьчелек кычкырды.
Исраиллеләр төне буе еладылар. 2 Барлык исраиллеләр
Муса белән Һаруннан зарланды, һәм бөтен җәмәгатьче-
лек аларга әйтте:
– Аһ, без Мисыр җирендә яки шушы чүлдә үлгән булсак! 3 Ни
өчен Раббы безне бу җиргә алып бара соң? Анда без кылычтан кы-
рылачакбыз, хатыннарыбыз һәм балаларыбыз дошманга әсир төшә-
чәк. Безнең өчен Мисырга кире әйләнеп кайту яхшырак булмасмы?
4 Алар бер-берсенә:
– Үзебезгә башлык сайлыйк та кире Мисырга әйләнеп кай-
тыйк, – диештеләр.
5 Шулвакыт Муса белән Һарун Исраил җәмәгатьчелегенең бөтен
җыены алдында йөзләре белән җиргә капландылар. 6 Ул җирне ка-
рап кайтучылар арасыннан Нун угылы Йешуа һәм Ифунни угылы
Кәлеб үзләренең киемнәрен ертып ташладылар 7 һәм Исраилнең
бөтен җәмәгатьчелегенә:
– Без карап кайткан җир гаҗәеп яхшы җир ул. 8 Әгәр дә Раббы
безгә мәрхәмәтле булса, Ул безне бу җиргә кертсен һәм аны безгә
бирсен. Ул шундый җир ки, анда сөт һәм бал ага. 9 Әмма Раббыга
каршы фетнә күтәрмәгез һәм ул җирнең халкыннан курыкмагыз,
чөнки без аларны икмәк ашагандай ашап бетерәчәкбез, аларның
яклаучысы юк инде, ә Раббы безнең белән, шуның өчен алардан
куркырга кирәкми, – диделәр.

[10] Әмма бөтен җәмәгатьчелек:
– Аларны ташлар белән тукмарга кирәк, – диде.
Шулвакыт Изге чатырда барча исраиллеләр алдында Раббының
шөһрәте күренде; [11] һәм Раббы Мусага әйтте:
– Кайчанга кадәр бу халык Мине кире кагачак? Алар арасында
кылган барлык могҗизаларга карамастан, кайчанга кадәр алар Миңа
ышанмас икән? [12] Аларны Мин үләт җибәреп кырачакмын, ә инде
синнән – алардан да бөегрәк һәм көчлерәк халык тудыртачакмын.
[13] Муса исә Раббыга әйтте:
– Мисырлылар бу хакта ишетәчәкләр, чөнки бу халыкны, көч
кулланып, алар арасыннан Син чыгардың. [14] Һәм мисырлылар шул
җирдә яшәүчеләргә бу хакта сөйләячәкләр. Алар Син – Раббының
бу халык арасында торуын ишетте инде; чөнки Син, Раббы, бу ха-
лык белән йөзгә-йөз очрашасың. Синең болытың алар өстендә
тора, һәм Син көндез болыт баганасында, төнлә ут баганасында
алар алдыннан барасың. [15] Әгәр Син бу халыкны, бер кешене үтер-
гәндәй, кырасың икән, ул чакта Синең ни эшләвеңне ишеткән ха-
лыклар: [16] «Раббы бу халыкны аңа вәгъдә иткән җиргә китереп җит-
керә алмады һәм шунлыктан аны чүлдә һәлак итте», – диячәкләр.
[17] Хәзер Хуҗаның кодрәте Үзең әйткән кебек булсын: [18] «Раббы
бик сабыр вә рәхим-шәфкатьле, ул гөнаһны һәм фетнәне кичерә,
әмма гаеплеләргә җәза бирергә дә онытмый, аталарының гөнаһы
өчен аларның балаларына да, оныкларына да, хәтта оныкларының
балаларына да җәза бирә». [19] Мисырдан чыккан вакыттан алып хә-
зергә кадәр бу халыкны ничек кичергән булсаң, хәзер дә Үзеңнең
бөек мәхәббәтең белән бу халыкның гөнаһын кичер.
[20-21] Раббы әйтте:
– Синең үтенечең хакына кичерәм. Мин Үземнең мәңге яшә-
вем белән ант итәм: Минем даным бөтен җиргә таралачак; [22] Ми-
сырда һәм чүлдә Минем данымны һәм Минем могҗизалы галәмәт-
ләремне күрүгә карамастан, Мине инде уннарча мәртәбә сынап
караган һәм Минем сүзләремә колак салмаган кешеләр, [23] Мине
кире какканга күрә, аталарына Мин вәгъдә иткән ул җирне күр-
мәячәкләр. [24] Әмма Минем хезмәтчем Кәлебне, аңарда Миңа ка-
рата башка мөнәсәбәт булганы һәм Миңа хыянәтсез булганы өчен,
үзе барып кайткан ул җиргә алып барачакмын, һәм аның нәселлә-
ре ул җирне мирас итеп алачаклар. [25] Амалыклылар һәм кәнганиләр
үзәнлектә яшиләр; иртәгә кире борылыгыз һәм Камышлы диңгез*
буендагы чүлгә китегез.
[26] Раббы Муса белән Һарунга әйтте:
[27] – Бу явыз җәмәгатьчелек кайчанга кадәр Миңа сукраначак?
Исраиллеләрнең Миңа каршы сукрануларын Мин ишетәм. [28] Аларга

* 14:25 *Камышлы диңгез* – элек-электән Кызыл диңгез дип йөртәләр.

Раббы болай дип әйтә диген: «Мин Үземнең мәңге яшәвем белән
ант итәм: Миңа каршы ничек сукранган булсагыз, сезгә каршы
да шулай эшләячәкмен.
29 Сезнең гәүдәләрегез бу чүлдә ятып ка-
лачак. Сез, исәпкә алынган егерме яшьтән өлкәнрәк һәм Миңа
каршы сукранган кешеләр, һәммәгез ятып калачаксыз.
30 Мин, ку-
лымны күтәреп, сезне урнаштырырга ант иткән ул җиргә, Ифун-
ни угылы Кәлеб һәм Нун угылы Йешуадан башка, берегез дә
кермәячәк.
31 Сез дошманга ганимәт булачак дип сөйләгән бала-
ларыгызны Мин әлеге сез кире каккан җиргә алып керәчәкмен
һәм алар аны үз күзләре белән күреп беләчәкләр.
32 Ә сезнең гәү-
дәләрегез ул чүлдә ятып калачак.
33 Балаларыгыз исә кырык ел
буе чүлдә күчеп йөриячәкләр һәм, сезнең гәүдәләрегез чүлдә һә-
лак булганга кадәр, сезнең хыянәтегез өчен михнәт чигәчәкләр.
34 Сез ул җирне кырык көн карап йөрдегез, һәм шул көннәр хиса-
бынча, кырык көн, һәр көн өчен бер ел исәбеннән, ягъни кырык
ел, михнәт чигәчәксез. Менә шуннан соң инде Минем тарафтан
кире кагылуның нәрсә икәнлеген яхшы беләчәксез».
35 Мин –
Раббы, һәм Миңа каршы фетнә күтәргән бу бөтен явыз җәмә-
гатьчелеккә каршы ничек һәм нәрсә сөйләгән булсам, шуны эш-
ләячәкмен; бу чүлдә аларның һәммәсе һәлак булачак һәм үлеп бе-
тәчәк.

36-37 Муса тарафыннан ул җирне карарга җибәрелеп, кайткач ул
җир турында яман хәбәр таратып, бөтен җәмәгатьчелекне аңа кар-
шы котыртучылар – бу җир турында яман хәбәр таратучылар –
Раббы тарафыннан җибәрелгән үләттән кырылып беттеләр.
38 Ул
җирне карарга барганнардан бары тик Нун угылы Йешуа белән
Ифунни угылы Кәлеб кенә исән калдылар.

39 Муса бу сүзләрне бөтен исраиллеләргә сөйләде. Бу хәбәрне
ишеткәч, халык бик нык хәсрәтләнде.
40 Һәм иртә белән иртүк то-
рып, алар тауга менделәр һәм әйттеләр:

– Менә без хәзер Раббы вәгъдә иткән җиргә барачакбыз, чөнки
без гөнаһ эшләдек.

41 Әмма Муса әйтте:

– Ни өчен сез Раббының күрсәтмәсенә каршы киләсез, бу эш
уңышлы чыкмаячак.
42 Анда бармагыз, чөнки Раббы сезнең янда
түгел, шунлыктан дошманнар сезне җиңәчәк.
43 Амалыклылар һәм
кәнганиләр анда сезгә каршы, һәм сез аларның кылычларыннан
кырылачаксыз, чөнки сез Раббыдан чигендегез, шуңа күрә Раббы
сезнең белән булмаячак.

44 Шулай да алар тауга менәргә батырчылык иттеләр, ә Муса исә
Раббы килешүе сандыгы белән бергә тукталу урынында калды.
45 Ул тауда яшәүче амалыклылар һәм кәнганиләр, таудан төшеп,
аларны туздырдылар һәм Хормага кадәр куып бардылар.

*Төрле корбаннар китерү кагыйдәләре*

**15** [1] Раббы Мусага әйтте:
[2-3] – Исраиллеләргә игълан ит: «Яшәү өчен сезгә Мин биргән җиргә кергәч, сез тулаем яндыру корбаны яки татулык корбаны, яисә нәзерләр үтәү өчен, яки үз теләгегез белән, яки билгеләнгән бәйрәмнәрдә, үгез яисә сарык хайваныннан утта яндырып корбан китерегез. Бу корбаннарның тәмле исе Раббының күңеленә хуш килер. [4] Раббыга бүләк корбанын китерүче, икмәк бүләге буларак, һиннең* дүрттән бер өлеше кадәр зәйтүн мае белән епаның уннан бер өлеше күләмендә иң яхшы бодай онын аралаштырып китерергә тиеш. [5] Һәм тулаем яндыру корбаны яки татулык корбаны өчен, һәрбер бәрән исәбеннән шәраб бүләге итеп, һиннең дүрттән бер өлеше күләмендә шәраб китерегез.

[6] Ә инде сарык тәкәсен корбан иткәндә, һиннең өчтән бер өлеше кадәр зәйтүн мае белән епаның уннан ике өлеше кадәр иң яхшы бодай онын аралаштырып, икмәк бүләге пешерегез. [7] Һәм шәраб бүләге итеп һиннең өчтән бер өлеше күләмендә шәраб китерегез. Бу корбаннарның тәмле исе Раббының күңеленә хуш килер.

[8-9] Тулаем яндыру корбаны итеп яки нәзерне үтәү өчен яисә татулык корбаны итеп яшь үгез китергәндә, яшь үгез белән бергә икмәк бүләге дә китерелергә тиеш. Икмәк бүләге һиннең яртысы кадәр зәйтүн мае белән аралаштырылган, епаның уннан өч өлеше кадәр иң яхшы бодай онынnan булырга тиеш. [10] Һәм шәраб бүләге итеп ярты һин шәраб китерегез. Бу корбанны утта яндырыгыз; аның тәмле исе Раббының күңеленә хуш килер. [11] Корбан ителгән һәр үгез яки сарык тәкәсе өчен яисә тәкә бәрән яки кәҗә бәрәннәренең һәрберсенә менә шул рәвешчә эшләнергә тиеш. [12] Сез китерә торган корбаннарның санына карап, һәрберсе өчен менә шулай эшләгез.

[13] Һәр җирле кеше, тәмле исе Раббының күңеленә хуш килерлек утта яндырылган корбан тәкъдим иткәндә, шул рәвешчә эш итәргә тиеш. [14] Әгәр сезнең арада читтән килгән кеше яшәсә яки буыннан-буынга кем дә булса берәү яшәп килсә һәм ул Раббының күңеленә хуш килерлек утта яндырылган корбан китерергә теләсә, сез ничек эшләсәгез, ул да шулай эшләргә тиеш. [15] Барлык җәмәгатьчелек өчен – сезнең өчен дә һәм сезнең арада яшәүче читтән килгән кеше өчен дә – кагыйдә бер. Бу кагыйдә сезнең һәм киләчәк буыннарыгыз өчен мәңгелек. Раббы алдында сез ничек булсагыз, читтән килгән кеше дә шулай булачак. [16] Сезнең өчен дә, сезнең арада яшәүче читтән килгән кеше өчен дә канун һәм карар бер үк төрле булачак».

[17] Раббы Мусага әйтте:

* 15:4 *Һин* – 6 литр чамасы.

[18-19] – Исраиллеләргә игълан ит: «Сез Мин алып барачак җиргә кергәч, ул җирнең икмәген ашаганда, шул икмәкнең бер өлешен Раббыга тәкъдим итегез. [20] Беренче камыр башыннан пешерелгән көлчәләрдән беренче көлчәне дә, ындырдагы бодайның бер өлешен Раббыга багышлап китергән кебек, Аңа багышлап китерегез. [21] Буыннан-буынга үзегезнең беренче камыр башыннан бүләкне Раббыга багышлап бирегез».

*Ниятләмичә эшләнгән ялгышлар һәм тиешлеләрне ниятләмичә үтәмәүләр өчен корбан итү кагыйдәләре*

[22-23] «Раббы әмер биргән көннән башлап киләчәк буыннарга кадәр Раббының Мусага әйткән барлык әмерләрен – ягъни Раббының Муса аша сезгә биргән барлык әмерләрен ниятләмичә үтәмисез икән, [24] һәм җәмәгатьчелекнең игътибарсызлыгыннан ялгышлык ниятләмичә эшләнә икән, ул чагында бөтен җәмәгатьчелек тулаем яндыру корбаны өчен бер үгез бозау, канун буенча, аның белән бергә икмәк бүләге һәм шәраб бүләге тәкъдим итәргә тиеш. Корбанның тәмле исе Раббының күңеленә хуш килер. Шуңа өстәп, гөнаһ йолу корбаны итеп, бер кәҗә тәкәсе китерелергә тиеш. [25] Исраилнең бөтен җәмәгатьчелеген гөнаһтан арындыру өчен, рухани йоланы үтәячәк; һәм аларның гөнаһлары кичереләчәк, чөнки ул ниятләмичә эшләнгән ялгышлык, һәм алар үз ялгышлары өчен Раббыга яндырылган корбан һәм гөнаһ йолу корбаны китерделәр. [26] Һәм бөтен Исраил җәмәгатьчелегенең һәм алар арасында яшәүче читтән килгән кешеләрнең гөнаһлары кичереләчәк, чөнки бу барча халыкның ялгышуы була.

[27] Әгәр кем дә булса берәү, ниятләмичә, ялгышлык белән гөнаһ эшли икән, ул чагында бу кеше гөнаһ йолу корбаны итеп бер яшьлек кәҗә китерергә тиеш. [28] Рухани, ниятләмичә ялгышлык белән гөнаһ эшләгән кеше өчен, Раббы алдында гөнаһтан арыну йоласын үтәячәк, шуннан соң ул кичереләчәк. [29] Кем дә булса, җирле кешеме ул яки сезнең арада яшәүче читтән килгән кешеме, ниятләмичә гөнаһ эшләсә, аңа карата канун бер төрле булсын.

[30] Әгәр җирле кеше яки читтән килгән кеше арасыннан берәү, белә торып, явыз кулы белән гөнаһ эшли икән, ул кеше Раббыны хурлаган була, һәм андый кеше үз халкы арасыннан юк ителергә тиеш. [31] Чөнки ул Раббы сүзенә җирәнеп караган һәм Аның әмерләрен бозган була; андый кеше юк ителәчәк, аның гөнаһы үз өстендә булачак».

*Шимбәне бозган өчен җәза*

[32] Исраиллеләр чүлдә чакта шимбә көнне утын җыеп йөрүче кешене очраттылар. [33-34] Моны күрүчеләр, аны тотып алып, Муса белән Һарун янына һәм бөтен җәмәгатьчелек каршына алып килделәр

дә сак астына алдылар, чөнки аның белән нишләргә икәне әлегә
билгесез иде. [35] Раббы Мусага әйтте:

– Бу кеше үтерелергә тиеш; бөтен җәмәгатьчелек аны тукталу
урынының тышында ташлар белән кыйнап үтерсен.

[36] Шуннан соң бөтен җәмәгатьчелек аны тукталу урынынnan чит-
кә алып чыкты да, Раббының Мусага әмер итүенчә, ташлар белән
тукмап үтерде.

*Кием чуклары*

[37] Раббы Мусага әйтте:

[38] – Исраиллеләргә әйт: «Сез буыннан-буынга киемнәрегезнең
итәкләренә чуклар тагыгыз һәм һәр чукка бер зәңгәр җеп бәйләгез.
[39] Сез, ул чукларга карап, Раббының барлык әмерләрен хәтерләр-
сез, аларны үтәрсез, йөрәкләрегезнең һәм күзләрегезнең азгынлы-
гын тыңламассыз. [40] Шуның белән сез Минем барлык әмерләрем-
не хәтерләп, аларны үтәрсез һәм Аллагыз алдында изге булырсыз.
[41] Мин – Раббы, сезнең Аллагыз. Сезнең Аллагыз булу өчен, Мин
сезне Мисыр җиреннән алып чыктым. Мин – Раббы, сезнең Ал-
лагыз».

*Корахның Мусага һәм Һарунга каршы фетнәсе*

**16** [1] Леви угылы Коһат, Коһат угылы Ичһар, Ичһар угылы Ко-
рах. Корах, Рубин нәселеннән Элиаб угыллары Датан бе-
лән Абирам, Пелет угылы Он, [2] һәм алар белән бергә исра-
иллеләрдән ике йөз илле кеше, җәмәгатьчелек арасыннан сайланган
халыкның җитәкчеләре, дәрәҗәле кешеләр, Мусага каршы фетнә
күтәрделәр. [3] Муса белән Һарунга каршы чыгып, алар әйттеләр:

– Җитәр сезгә, бөтен җәмәгатьчелек изге, аларның һәрберсе из-
ге, һәм алар арасында Раббы! Ни өчен сез үзегезне Раббы халкын-
нан өстен куясыз?

[4] Моны ишеткәч, Муса йөзе белән җиргә капланды. [5] Ул Корах
һәм аның тарафдарларына әйтте:

– Иртәгә иртән Раббы кемнең Аныкы һәм кемнең изге икәнле-
ген күрсәтәчәк һәм аны Үзенә якынайтачак. Ул кемне сайлап алса,
шуны Үзенә якынайтачак. [6] Ә сез, Корах һәм аның тарафдарлары,
менә нәрсә эшләгез: үзегезгә сумала төтәсләү савытларын алыгыз
[7] һәм иртәгә Раббы алдында аларга ут һәм хуш исле сумала салыгыз.
Раббы кемне сайласа, шул изге булыр. Леви угыллары, җитәр сезгә!

[8] Муса Корахка тагын әйтте:

– Әй, Леви угыллары, тыңлагыз! [9] Раббы чатырында эшләсеннәр,
исраиллеләргә хезмәт итеп, җәмәгатьчелек алдында торсыннар дип,
сезне Исраил Алласы, Исраил җәмәгатьчелегеннән аерып алып, Үзе-
нә якынлаштырды – бу сезгә азмы әллә? [10] Ул сине, синең белән
бергә барлык туганнарыңны, Леви угылларын Үзенә якынлаштырды,

шуның өстенә сез тагы руханилыкны да дәгъвалыйсыз. [11] Шул рә-
вешле, син һәм синең тарафдарларың Раббыга каршы чыгасыз. Һа-
рунга нәрсә булган, сез нигә аңа карата ризасызлык белдерәсез?
[12] Аннары Муса Элиаб угыллары Датан белән Абирамны чакы-
рырга кеше җибәрде. Әмма алар әйтте:
– Без бармыйбыз! [13] Синең безне, чүлдә үтерү өчен, сөт һәм бал
аккан җирдән чыгаруың җитмәдеме? Шуның өстенә син безнең
өстән хакимлек итәргә дә телисеңме? [14] Моннан тыш, син безне
сөт һәм бал ага торган җиргә алып килмәдең. Һәм безгә кырлар,
йөзем бакчалары бирмәдең. Син бу кешеләрне алдаларга телисең-
ме? Бармыйбыз без!
[15] Мусаның бик нык ачуы чыкты һәм ул Раббыга әйтте:
– Аларның китергән әйберләренә күзеңне дә төшермә; мин алар-
ның берсеннән дә ишәк алмадым һәм берсенә дә зыян итмәдем.
[16] Һәм Муса Корахка әйтте:
– Иртәгә син, бөтен тарафдарларың һәм Һарун Раббы алдында
булыгыз. [17] Һәрберегез үзенең сумала төтәсләү савытын алып, аның
өстенә хуш исле сумала салсын; һәрберегез үзенең сумала төтәс-
ләү савытын – барлыгы ике йөз илле сумала төтәсләү савытын –
Раббы алдына китерегез. Син һәм Һарун – икегез дә сумала төтәс-
ләү савытларыгызны алып килегез.
[18] Һәм һәрберсе, үзенең сумала төтәсләү савытын алып, алар өс-
тенә хуш исле сумала куйды һәм Изге чатырга керү урынына ки-
леп басты. Муса белән Һарун да шунда тордылар. [19] Һәм Корах
үзенең бөтен тарафдарларын Изге чатырга керү урыны янына,
алар каршына җыйды. Шулвакыт Раббының даны бөтен җәмә-
гатьчелеккә беленде.
[20-21] Раббы Муса белән Һарунга әйтте:
– Бу җәмәгатьчелектән аерылыгыз, һәм Мин аларны күз ачып
йомганчы юк итәчәкмен.
[22] Алар исә йөзләре белән җиргә капландылар һәм ялвардылар:
– И Аллаһы, бөтен адәм рухының Алласы! Бер кеше эшләгән
гөнаһ өчен Син бөтен җәмәгатьчелеккә ачу белдерәсеңме?
[23] Раббы Мусага әйтте:
[24] – Җәмәгатьчелеккә әйт: «Корах, Датан һәм Абирам торак урын-
нарының һәр ягыннан читкә китегез».
[25] Муса торды да Датан белән Абирам янына китте, аның артын-
нан Исраил аксакаллары дә торып киттеләр. [26] Муса җәмәгатьче-
леккә әйтте:
– Бу гөнаһлы кешеләрнең чатырларыннан ерактарак торыгыз
һәм, аларның гөнаһлары аркасында һәлак булмас өчен, аларның
бернәрсәсенә дә кагылмагыз.
[27] Һәм алар Корах, Датан, Абирам торак урыннарының һәр ягын-
нан читкә киттеләр. Ә Датан белән Абирам, чатырларыннан чыгып,

хатыннары, угыллары һәм балалары белән керү урыннары янында тордылар.

28 Муса әйтте:

– Менә шуннан Раббының мине бу эшләрне башкару өчен җибәргән булуын белерсез – мин бит боларны үз акылым белән эшләмим.
29 Әгәр алар барлык кешеләр үлгән кебек табигый үлем белән үлсә һәм аларның язмышы башка кешеләрнең язмышы кебек булса, Раббы мине җибәрмәгән дигән сүз.
30 Раббы гадәттән тыш хәл тудырып, җир үзенең авызын ачса, аларның һәммәсен һәм һәрнәрсәсен йотса, һәм алар тере килеш үлеләр дөньясына китсәләр, белегез: болар Раббыны кире каккан кешеләр.

31 Мусаның шушы сүзләрне әйтеп бетерүе булды, корахлыларның аяк астында җир ярылып та китте.
32 Һәм, авызын ачып, аларны, гаиләләрен, Корахның барлык тарафдарларын һәм бөтен малларын йотты.
33 Алар булган барлык нәрсәләре белән, тере килеш, үлеләр дөньясына киттеләр. Аларны җир каплады, һәм алар җәмәгатьчелек арасыннан юк ителде.
34 Алар тирәсендәге барлык исраиллеләр, тегеләрнең ачы тавышын ишетүгә:

– Безне дә җир йотар! – дип, кычкыра-кычкыра качып киттеләр.

35 Хуш исле сумала китергән теге ике йөз илле кеше дә, Раббыдан ут чыгып, юк булды.

36 Һәм Раббы Мусага әйтте:

37 – Рухани Һарун угылы Элгазарга әйт: сумала төтәсләү савытларын яндырылган калдыклар арасыннан җыеп алсын да яндырылган сумаланы ераккы түксен, чөнки сумала төтәсләү савытлары хәзер изгеләндерелделәр инде.
38 Гөнаһлары аркасында үлемгә дучар ителгәннәрнең сумала төтәсләү савытлары, мәзбәхне каплау өчен, юка пластиналар итеп чүкеп телгәләнсен. Аннары бу савытларны Раббы алдына китерделәр, шуңа күрә алар изге һәм исраиллеләрне кисәтү өчен билге булачаклар.

39 Рухани Элгазар яндырылган кешеләрнең сумала төтәсли торган җиз савытларын җыеп алды. Алар мәзбәхне каплау өчен юка итеп чүкеп телгәләнделәр.
40 Менә бу исраиллеләргә кисәтү: Һарун нәселеннән булмаган, ышанып эш тапшырылмаган бер генә кеше дә Раббы алдында хуш исле сумала төтәсләргә тиеш түгел, югыйсә, ул, Корах һәм аның тарафдарлары кебек, һәлак ителәчәк. Болар Раббының Муса аша рухани Элгазарга әйтелгән боерыгы буенча эшләнелде.

41 Икенче көнне Исраилнең бөтен җәмәгатьчелеге, Муса белән Һарунга каршы сукранып:

– Раббының халкын сез һәлак иттегез, – диде.

42 Җәмәгатьчелек Муса белән Һарун каршына җыелгач, алар Изге чатырга таба юнәлделәр. Менә шулчак чатырны болыт каплады һәм Раббының шөһрәте күренде.
43 Муса белән Һарун Изге чатыр алдына килделәр.
44 Һәм Раббы Мусага әйтте:

45 – Бу җәмәгатьчелектән читләшегез, һәм Мин аларны күз ачып йомганчы һәлак итәм.

Әмма Муса һәм Һарун йөзләре белән җиргә капландылар.

46 Муса Һарунга әйтте:

– Кулыңа сумала төтәсләү савытыңны ал да, мәзбәхтән ут алып, аны яндыр, төтәслә һәм тиз генә җәмәгатьчелек алдына китер. Аларны гөнаһтан арындыру йоласын үтә. Чөнки Раббы аларга ачуланды, һәм үләт башланды.

47 Һарун, Муса әйткәнчә, сумала төтәсләү савытын алып, җыен
арасына йөгерде, ә халык арасында инде үләт башланган иде, һәм
ул, хуш исле сумала төтәсләп, халыкны гөнаһтан арындыру йола-
сын үтәде. 48 Ул үлеләр белән тереләр арасында басып торды, һәм
үләт туктады. 49 Корах фетнәсендә үлгәннәрне исәпләмичә, үләт-
тән үлүчеләрнең саны ундүрт мең җиде йөз кешегә җитте. 50 Үләт
туктаганнан соң, Һарун Изге чатырга керү урыны алдына Муса
янына кайтты.

*Һарун кул таягының чәчәк атуы*

# 17

1 Раббы Мусага әйтте:

2 – Исраиллеләргә әйт һәм алардан кул таякларын ал.
Аларның һәр ата-баба ыругыннан берәр данә, унике ыруг
җитәкчесеннән унике кул таягын ал һәм һәрберсенең исемен үз
таягы өстенә язып куй. 3 Һарун исемен Леви таягы өстенә яз. Һәр
ата-баба ыруг башлыгының исемен язу өчен бер таяк булырга тиеш.
4 Ул таякларны Изге чатырдагы боерыклар сандыгы алдына – Мин
сезгә күренгән урынга куй. 5 Мин кемне сайласам, аның таягы бө-
ре чыгарачак; шуның белән Мин исраиллеләрнең сезгә сукранула-
рын туктатачакмын.

6 Муса исраиллеләргә сөйләде, һәм аларның барлык ыруг җитәк-
челәре таякларын аңа бирделәр; аларның ата-бабалар ыруглары са-
ны буенча һәр җитәкчедән бер таяк – барлыгы унике таяк булды;
бу таяклар арасында Һарун таягы да бар иде. 7 Һәм Муса таякларны
боерыклар куелган чатырга Раббы алдына китереп куйды.

8 Икенче көнне Муса боерыклар куелган чатырга керде. Менә,
Леви ыругы өчен булган Һарун таягы бөре чыгарып чәчәк атты
һәм бадәм чикләвекләре өлгерде! 9 Аннары Муса барлык таякլар-
ны Раббы алдыннан алып, исраиллеләр алдына чыгарды. Һәм алар
моны күрделәр, һәрберсе үзенең кул таягын алды.

10 Раббы Мусага әйтте:

– Буйсынмаучыларга кисәтү билгесе буларак, Һарун таягын боерыклар сандыгы алдына яңадан куй; алар Миңа сукрануларын туктатсыннар, югыйсә, үләчәкләр.

11 Муса шулай эшләде дә; Раббы аңа ничек әмер иткән булса, шулай эшләде.

12 Исраиллеләр Мусага әйттеләр:
– Менә без үләбез, һәлак булабыз, һәммәбез һәлак була! 13 Раббының Изге чатырына якынлашкан һәркем үлә. Безнең һәммәбезгә дә үләргә туры киләчәкме?!

*Руханиларның һәм левиләрнең вазифалары*

**18** 1 Раббы Һарунга әйтте:
– Син һәм синең угылларың, синең белән бергә атаң гаиләсе Изге бүлмәдә хезмәт иткәндә күрсәткән җитешсезлекләре өчен гөнаһ йөртәсез; рухани вазифаларын үтәгәндә күрсәткән җитешсезлекләрегез өчен фәкать син һәм синең белән бергә угылларың җаваплы. 2 Шулай ук туганнарыңны – Леви угылларын, ягъни ата-бабаларың ыругын үзең белән ал; алар сиңа бәйле булсыннар*. Син һәм угылларың боерыклар куелган чатыр алдында хезмәт иткәндә, алар сиңа ярдәм итсеннәр. 3 Алар сиңа һәм Чатырга хезмәт итсеннәр; әмма алар Изге бүлмәнең әйберләренә һәм мәзбәхкә якынлашмасыннар; югыйсә, алар сезнең белән бергә үләчәкләр. 4 Алар сиңа бәйле булсыннар һәм Изге чатырны күзәтсеннәр, Чатырның бөтен эшләрен башкарсыннар, ә рөхсәт бирелмәгән кеше сезгә якын килергә тиеш түгел.
5 – Исраиллеләргә тагын ачу килмәсен өчен, сез Изге бүлмәгә һәм мәзбәхкә күз-колак булырга тиеш. 6 Менә, Мин сезнең туганнарыгыз – левиләрне исраиллеләр арасыннан сайлап алдым һәм бүләк итеп сезгә бирдем. Алар, Изге чатырда хезмәт итү өчен, Раббыга багышландылар. 7 Фәкать син һәм синең белән бергә синең угылларың мәзбәхнең һәр нәрсәсе өчен, пәрдә эчендәге һәр нәрсә өчен, руханилык вазифасын башкарыгыз. Руханилык вазифасын сезгә бүләк итеп тапшырам. Кем дә булса башка кеше якын килсә, үлемгә дучар ителергә тиеш.

*Руханиларга бирелгән өлеш*

8 Аннары Раббы Һарунга әйтте:
– Менә Миңа тәкъдим ителгән бүләкләрне күзәтүне Мин сиңа тапшырам; исраиллеләр тарафыннан Миңа багышланган бөтен нәрсәне, сезнең мәңгелек өлеш итеп, сиңа һәм синең угылларыңа бирәм. 9 Яндырылмый торган иң изге нәрсәләрдән менә болар синеке булачак. Аларның Миңа китергән һәр икмәк бүләге, һәр гөнаһ йолу корбаны һәм һәр гаеп йолу корбаны синеке булачак. Болар сиңа һәм синең угылларыңа бик изге булачак. 10 Аларны сез иң изге урында ашагыз, ир-ат җенесеннән булган теләсә кем аларны ашый ала; алар синең өчен изге булсыннар.

---

* 18:2 *Леви* – яһүдчә «ябышкак», «багланучы» мәгънәсендә.

[11]– Болардан тыш, исраиллеләрнең Миңа китергән теләсә нинди махсус бүләкләре синеке булачак. Аларның барлык бүләкләрен Мин сиңа, синең угылларыңа һәм кызларыңа мәңгелек өлеш итеп бирәм. Синең өеңдә пакь булган һәркем аларны ашарга мөмкин.

[12]– Исраиллеләрнең Раббыга бүләк иткән беренче уңышларыннан иң яхшыларын: зәйтүн маеннан иң яхшысын, шәрабтан һәм бодайдан иң яхшысын Мин сиңа бирәм. [13]Аларның җире җитештергән һәм Раббыга бүләк ителгән беренче җимешләренең барысы да синеке булачак. Синең өеңдә пакь булган һәркем аларны ашый ала.

[14]– Исраил җирендә Раббыга багышланган һәрнәрсә синеке булачак. [15]Раббыга тәкъдим ителгән, беренче булып туган һәр җан иясе, кешеме ул, хайванмы, синеке булачак; әмма кешеләр арасында беренче булып туган бала өчен йолым түләнергә тиеш, һәм шакшы хайваннарның беренче булып туганнары өчен дә йолым түләнергә тиеш. [16]Ә алар өчен йолым: бер айлыктан башлап, үзең билгеләгән бәя буенча, һәрберсе өчен биш шәкыл көмеш алачаксың. Рәсми бәя буенча, бер шәкыл егерме гера була. [17]Әмма сыер, сарык, кәҗәләрнең беренче булып туганнары өчен йолым алынмый, чөнки алар изге, аларның канын мәзбәх өстенә сип; Раббының күңеленә хуш килгән тәмле ис буларак, аларның маен утта яндырып тәкъдим ит. [18]Аларның ите, махсус бүләкнең селкетелгән күкрәк һәм арткы уң боты кебек, синеке булачак. [19]Исраиллеләрнең Раббыга дип тәкъдим иткән барлык изге бүләкләрен мәңгелек өлеш итеп сиңа, синең угылларыңа һәм синең кызларыңа бирәм. Менә бу – синең һәм синең белән бергә нәселең өчен Раббы алдында тоз килешүе*.

[20]Раббы Һарунга әйтте:

– Исраил җирендә синең мирасың һәм исраиллеләр арасында синең өлешең булмаячак; Мин – синең өлешең һәм исраиллеләр арасында синең мирасың.

*Левиләргә бирелгән өлеш*

[21]– Менә, Мин, үтәгән хезмәтләре, Изге чатырда башкарган эшләре өчен мирас итеп, Исраилдә һәр гошерне* левиләргә бирәм. [22]Бүгеннән башлап исраиллеләр, киләчәктә гөнаһлы булмасыннар һәм үлмәсеннәр өчен, Изге чатырга якын килмәскә тиешләр. [23]Ә Изге чатыр хезмәтен левиләр башкарсын һәм аларның гөнаһларын үз өсләренә алсын. Менә бу буыннан-буынга күчеп килә торган мәңгелек кагыйдә булачак. Левиләр исә исраиллеләр арасында мирас ала алмаячак. [24]Чөнки исраиллеләр Раббыга бүләк итеп биргән гошерне Мин мирас итеп левиләргә бирәм, шуның өчен аларга: «Исраиллеләр арасында сезгә мирас булмаячак» – дидем.

---

* **18:19** *Тоз килешүе* – мәңгелек какшамас килешү мәгънәсендә.

* **18:21** *Гошер* – керемнең уннан бер өлеше, Аллаһыга багышлана торган җыем.

[25] Раббы Мусага әйтте:
[26] — Левиләргә аңлат һәм әйт: «Мин сезгә мирас итеп биргән гошерне исраиллеләрдән алган вакытта, шуның уннан бер өлешен бүләк итеп Раббыга тәкъдим итегез. [27] Бу, ындыр табагыннан яңа сугылган бодай һәм яңа агып чыккан шәраб белән тәкъдим иткән бүләк кебек, сезнеке исәпләнәчәк. [28] Шулай итеп, сез дә исраиллеләрдән алачак гошерләрегезнең барчасыннан Раббыга бүләк тәкъдим итәчәксез; һәм шуннан Раббының бүләк тәкъдимен рухани Һарунга бирәчәксез. [29] Сезгә бирелгән бүләкләрнең һәммәсеннән изге һәм иң яхшы өлешне Раббыга тәкъдим итегез».
[30] — Һәм левиләргә әйт: «Шуннан иң яхшы өлешне Раббыга тәкъдим иткән вакытта ул, ындыр табагыннан яңа сугылган бодай һәм яңа агып чыккан шәраб кебек, сезнең уңышларыгыз булып исәпләнәчәк. [31] Сез һәм гаиләләрегез моны һәр урында ашый ала, чөнки бу — Изге чатырда башкарган хезмәтегез өчен әҗер. [32] Иң яхшы өлешне китергән өчен, сез гөнаһлы булмаячаксыз. Исраиллеләр китергән изге бүләкләрне нәҗесләмәгез, югыйсә, үләчәксез».

*Шакшылыкны пакьләү суының әзерләнүе*

**19** [1] Раббы Муса белән Һарунга әйтте:
[2] — Раббының исраиллеләргә әмер иткән кануннарының бер кагыйдәсе менә мондый: исраиллеләр сиңа кимчелексез һәм моңарчы камыт кимәгән җирән бозау китерергә тиешләр. [3] Бозауны рухани Элгазарга бирегез. Ул тукталу урыныннан чыгарылсын һәм рухани күз алдында суелсын. [4] Рухани Элгазар бармагы белән аның канын алсын да Изге чатырның алгы ягына җиде мәртәбә сипсен. [5] Руханиның күз алдында бозау яндырылсын; шулай ук аның тиресе һәм ите, каны, эчендәге шакшылары белән бергә, яндырылсын. [6] Рухани эрбет агачы, һүссөп* үсемлеге һәм җете кызыл йон җеп алсын да аларны яндырылган бозау өстенә ыргытсын. [7] Шуннан соң рухани үзенең киемнәрен һәм тәнен су белән юсын, аннары тукталу урынына керсен; әмма ул кичкә кадәр шакшы булачак. [8] Бозауны яндырган кеше дә үзенең киемнәрен һәм тәнен су белән юарга тиеш; ул да кичкә кадәр шакшы булачак.
[9] — Бер пакь кеше яндырылган бозауның көлен җыеп алсын да аны тукталу урыны тышында чиста бер урында сакласын. Ул Исраил җәмәгатьчелегенә шакшылыкны пакьләү суы әзерләү өчен саклансын; бу — гөнаһтан чистарту өчен. [10] Яндырылган бозауның көлен җыйган кеше дә үз киемнәрен юарга тиеш, ул да кичкә кадәр шакшы булачак. Бу исраиллеләр һәм алар арасында читтән килеп яшәгән кешеләр өчен дә мәңгелек кагыйдә булачак.

---

* [19:6] *Һүссөп* — пакьләнү өчен кулланыла торган үсемлек.

11 – Үлгән кеше мәетенә кагылган теләсә кем җиде көн буе шак-
шы булачак. 12 Ул кеше өченче һәм җиденче көндә шул шакшы-
лыкны пакьләү суы белән үзен чистартырга тиеш; шуннан соң ул
чистарыначак. Әгәр өченче һәм җиденче көндә үзен чистартмаса,
ул чистарынмаячак. 13 Үлгән кеше мәетенә кагылган һәм үзен пакь-
ләмәгән һәркем Раббының Изге чатырын шакшылатыр, андый
кеше Исраилдән юкка чыгарылырга тиеш, чөнки аның өстенә шак-
шылыкны пакьләү суы сибелмәгән, шунлыктан ул – шакшы, аның
өстендә әле һаман да шакшылык бар.
14 – Кем дә булса берәү чатырда үлә икән, канун шундый: бу ча-
тыр эчендә булганнар да, чатырга кергәннәр дә җиде көн шакшы
булачак. 15 Ул чатырда өсте ачык һәм капкач белән ябылмаган те-
ләсә нинди савыт-саба шакшы булачак.
16 – Кырда кылыч белән үтерелгән яки үзе үлгән кешегә, кеше
сөягенә яки кабергә кагылган теләсә кем җиде көн шакшы бу-
лачак.
17 – Шакшы булган кеше өчен яндырылган гөнаһ йолу корбаны-
ның көлен алып, аны савытка салырга һәм өстенә саф су коярга
кирәк. 18 Шуннан соң пакь булган берәр кеше һүссөп алып, аны
әлеге көлле суга манчысын да чатыр өстенә, андагы барлык са-
вытларга, кешеләргә һәм кеше сөягенә яки үтерелгән яисә үлгән
кеше мәетенә, кабергә кагылган кеше өстенә сипсен. 19 Шул пакь
кеше өченче һәм җиденче көннәрдә шакшы кеше өстенә әлеге су-
ны сипсен. Җиденче көндә пакьләнгән кеше су белән үз киемнә-
рен һәм тәнен юарга тиеш, кич белән ул пакь булачак.
20 – Әгәр кем дә булса берәү, шакшы булып та, үзен пакьләмәсә,
ул кеше үз халкы арасыннан юк ителергә тиеш; чөнки ул Раббының
Изге бүлмәсен шакшылатыр; аның өстенә шакшылыкны пакьләү
суы сибелмәгән, шунлыктан ул – шакшы. 21 Менә бу – исраилле-
ләргә мәңгелек кагыйдә. Шакшылыкны пакьләү суын сипкән кеше
дә үз киемнәрен юарга тиеш. Шакшылыкны пакьләү суына кагыл-
ган теләсә кем кичкә кадәр шакшы булачак. 22 Шакшы кеше ка-
гылган һәрнәрсә шакшы булачак; шундый нәрсәгә кагылган кеше
дә кичкә кадәр шакшы булачак.

*Мириамның үлеме*

**20** 1 Беренче айда исраиллеләр, бөтен җәмәгатьчелек, Сыйн
чүленә килделәр, халык Кадышта туктады. Шунда Ми-
риам үлде, һәм аны Кадышта җирләделәр.

*Кыядан су бәреп чыгу*

2 Биредә җәмәгатьчелеккә эчәр су булмады, һәм алар Муса белән
Һарунга каршы чыгар өчен җыелдылар. 3 Халык, Мусаны гаепләп,
аңа әйтте:

– Их, туганнарыбыз Раббы алдында үлгән вакытта без дә үлгән
булсак! 4 Нигә сез Раббының халкын бу чүлгә алып килдегез, без
үзебез һәм терлекләребез үлсен дипме? 5 Нигә сез безне Мисыр-
дан алып чыктыгыз һәм бу начар урынга алып килдегез? Монда
иген дә игеп булмый, монда инҗир дә, йөзем дә, анар да, хәтта
эчәргә су да юк!
6 Муса белән Һарун, җәмәгатьчелек яныннан китеп, Изге чатыр-
га керү урыны янына килделәр дә йөзләре белән җиргә капланды-
лар, менә шул чакта аларга Раббының шөһрәте күренде. 7 Раббы
Мусага әйтте:
8 – Кулыңа таягыңны ал да, агаң Һарун белән бергә, җәмәгать-
челекне җыегыз. Аларның күз алдында кыяга әмер итегез, шун-
да кыя үзеннән су чыгарыр. Шулай итеп син кыядан алар өчен
су алырсың һәм җәмәгатьчелеккә, аларның терлекләренә су эче-
рерсең.
9 Муса, Раббы әмер иткәнчә, Аның алдыннан таякны алды.
10 Шуннан соң Муса белән Һарун җәмәгатьчелекне кыя алдына
җыйдылар, һәм Муса аларга әйтте:
– Әй сез, фетнәче кешеләр, тыңлагыз, бу кыядан сезгә суны әл-
лә без чыгарырга тиешме?
11 Мусаның, кулын күтәреп, таягы белән ике тапкыр кыяга сугуы
булды, аннан күп су бәреп тә чыкты. Җәмәгатьчелек һәм аларның
терлекләре су эчте.
12 Шуннан соң Раббы Муса белән Һарунга әйтте:
– Исраиллеләрнең күз алдында Миңа иман китермәвегез һәм
Минем изгелегемне танымавыгыз өчен, сез бу халыкны Мин вәгъ-
дә иткән җиргә алып кермәячәксез.
13 Болар Мериба* сулары иде, анда исраиллеләр Раббыны гаеп-
ләделәр, һәм Раббы аларга Үзенең изге булуын күрсәтте.

*Исраиллеләрнең Эдом җире аркылы үтә алмаулары*

14 Муса Кадыштан* Эдом патшасына илчеләр җибәрде. Алар
әйттеләр:
– Туганың Исраил әйтүенчә, безнең башка төшкән авырлык-
ларны син беләсең. 15 Аталарыбыз Мисырга күчеп урнашкач, без
озак вакытлар анда яшәдек, әмма мисырлылар безнең белән һәм
безнең аталарыбыз белән тупас мөгамәлә кылдылар. 16 Һәм без Раб-
быга мөрәҗәгать иттек, Ул безнең зарыбызны ишетте һәм, фәреш-
тә җибәреп, безне Мисырдан чыгарды. Менә хәзер без Кадышта,
синең мәмләкәтеңнең чигендәге шәһәрдә. 17 Син безгә үз җирең

---

* 20:13 *Мериба* – яһүдчә «гаепләү» мәгънәсендә.
* 20:14 *Кадыш* – яһүдчә «изге урын» мәгънәсендә, 20:12-13нче аятьне карагыз.

аша үтеп китәргә рөхсәт ит әле! Без синең кырларың һәм йөзем бакчаларың аша үтмәбез һәм коеларыңнан су эчмәбез. Без бары тик патша юлы буйлап кына үтәрбез, синең илең чикләрен үтеп чыкканга кадәр уңга да, сулга да борылмыйча, читкә тайпылмыйча барырбыз.
18 Әмма Эдом әйтте:
– Минем җирем аша үтмә, югыйсә, мин кылыч белән сезгә каршы чыгачакмын.
19 Исраиллеләр аңа әйттеләр:
– Без олы юл буйлап кына үтәчәкбез, үзебез һәм терлекләребез суыңны эчәбез икән, аның өчен түләрбез. Без синең җиреңаша атлап үтеп китәргә генә сорыйбыз, моның бит бернәрсәсе дә юк.
20 Ә Эдом әйтте:
– Минем җирем аша үтмәссез.
Һәм ул күп санлы халык һәм көчле гаскәр белән исраиллеләргә
каршы чыкты. 21 Шулай итеп, Эдом исраиллеләргә үзенең җире аша
үтәргә рөхсәт итмәде, һәм алар аны читләтеп үттеләр.

*Һарунның үлеме*

22 Исраиллеләр Кадыштан юлга чыктылар һәм бөтен җәмәгать-
челек Һор тавына килеп җитте. 23 Раббы Эдом җире чигендә Һор
тавында Муса белән Һарунга әйтте:
24 – Һарун үзенең үлгән ата-бабалары белән кушылачак, чөнки сез Мериба сулары янында Минем күрсәтмәмә каршы килдегез, шуңа күрә Һарун Мин исраиллеләргә бирергә вәгъдә иткән җиргә
кермәячәк. 25 Һарунны һәм аның угылы Элгазарны ал да Һор та-
вына алып мен. 26 Һарунның киемнәрен салдырып, угылы Элга-
зарга кидер, чөнки Һарун үзенең ата-бабалары белән кушылачак. Ул анда үләчәк.
27 Муса Раббы кушканча эшләде. Алар барча җәмәгатьчелек күз
алдында Һор тавына менделәр. 28 Муса, Һарунның киемнәрен сал-
дырып, угылы Элгазарга кидерде. Һарун шунда тау башында үлде.
Ә Муса белән Элгазар тау башыннан кире төштеләр. 29 Һарунның
үлгәнен белгәннән соң, бөтен җәмәгатьчелек, Исраил гаиләләре утыз көн буе аны кызганып елады.

*Арадның юк ителүе*

**21** 1 Көньякта, Нәгебтә яшәүче Кәнган патшасы Арад, исраиллеләрнең Атарим юлы буенча килүен ишеткәч, аларга каршы сугыш ачты һәм берничәсен әсир итеп алды.
2 Шулчак исраиллеләр Раббыга нәзер итеп әйттеләр:
– Бу халыкны безнең кулга бирсәң, аларның шәһәрләрен тәмам юк итәчәкбез.

[3] Раббы, исраиллеләрнең тавышын ишетеп, кәнганиләрне аларның
кулына бирде, һәм исраиллеләр тегеләрне, шәһәрләре белән бергә,
тәмам юк иттеләр. Шуңа күрә бу урынны Хорма* дип атадылар.

*Бакырдан ясалган елан*

[4] Алар, Һор тавыннан Эдом җирен әйләнеп үтү өчен, Камышлы
диңгез юлы белән киттеләр. Юлда халыкның күңеле төшенкелеккә
бирелә башлады. [5] Халык, Аллаһы белән Мусадан ризасызлыкла-
рын белдереп, болай дип сорады:

– Ни өчен безне Мисырдан алып чыктыгыз, без чүлдә һәлак булсын дипме? Чөнки монда икмәк тә, су да юк, һәм бу яраксыз ризыктан инде күңелебез бизде.

[6] Шулчак Раббы халык арасына агулы еланнар җибәрде, алар ха-
лыкны чактылар, һәм исраиллеләрнең күбесе үлде. [7] Халык Муса
янына килеп әйтте:

– Раббыга һәм сиңа каршы сөйләвебез белән без гөнаһ эшләдек; Раббыдан ялварып сора, ул еланнарны безнең яннан алсын.

Һәм Муса халык өчен гыйбадәт кылып ялварды.

[8] Раббы Мусага әйтте:

– Бер елан яса да аны биек колга очына беркет, һәм елан чаккан һәркем, аңа карап, тереләчәк.

[9] Шуннан соң Муса, бакырдан елан ясап, аны биек колга очына беркетте һәм елан чаккан һәркем, аңа карап, исән калды.

*Моабка сәфәр*

[10] Исраиллеләр юлга чыктылар һәм Оботта чатырларын корып
тукталдылар. [11] Аннары Оботтан китеп, чүлдә, Моаб каршында,
кояш чыгышы тарафындагы Ие-Әбаримдә чатырларын кордылар.
[12] Ул урыннан китеп, Зеред үзәнлегендә чатырларын корып тукта-
дылар. [13] Ул урыннан китеп, чүлдәге Арнон елгасының икенче ягын-
да чатырларын кордылар. Арнон елгасы, Моабның чигеннән агып,
Моаб белән аморилар арасында чик хасил итте. [14-15] Шуңа күрә
Раббының Сугышлар Китабында бу хакта болай диелгән: «Суфа-
дагы Ваһеб шәһәре, Арнон елгасының үзәнлекләре белән сөзәк-
лекләре Ар шәһәренә, Моаб чиге буенча җәелгән».
[16] Аннан алар Беергә* киттеләр. Раббының Мусага: «Халыкны
җый, аларга су бирәчәкмен», – дигән коесы менә шушы иде.
[17] Шулчак исраиллеләр менә мондый җыр башлады:

– Әй, кое, су белән тулы бул.
Без сине җыр белән тәбрик итәбез.

---

* **21:3** *Хорма* – яһүдчә «тулысынча һәлак булу» мәгънәсендә; 14:45нче аятьтә шулай.

* **21:16** *Беер* – яһүдчә «кое» мәгънәсендә.

18 Син – морзалар казыган,
үзләренең хакимлек таяклары һәм юл таяклары белән
халык морзалары казыган кое.

Аннары исраиллеләр чүлдән Маттанага киттеләр. [19-20] Маттана-
дан Нахалиелгә, Нахалиелдән Бамотка, Бамоттан чүлгә таба караган
Песгә тавы итәгендәге, Моаб җирендәге үзәнлеккә килделәр.

*Исраиллеләрнең Сихонны һәм Огны җиңүләре*

[21] Исраиллеләр аморилэр патшасы Сихонга илчеләр җибәреп
әйттеләр:
[22] – Безгә үзеңнең җирең аша үтәргә рөхсәт ит әле. Без синең
кырларыңа һәм йөзем бакчаларыңа кермәбез, синең коеларыңнан
су да эчмәбез, синең чикләреңне үтеп киткәнгә кадәр, юлдан тай-
пылмыйча патша юлыннан гына барырбыз.
[23] Әмма Сихон исраиллеләргә үз җире аша үтәргә рөхсәт бирмәде.
Сихон үзенең бөтен халкын җыйды, чүлдә исраиллеләргә каршы чы-
гып, Яһаска кадәр килде һәм исраиллеләр белән сугышты. [24] Исраил-
леләр Сихонны кылыч белән җиңделәр һәм Арноннан алып Йавукка
кадәр, Аммон чигенә кадәр, аның җирләрен яулап алдылар. Әмма
шуннан ары бара алмадылар, чөнки аммонлыларның чиге нык иде.
[25] Исраиллеләр аморилэрнең барлык шәһәрләрен – шул исәптән
Хишбун һәм аның әйләнә-тирәсендәге авылларын – басып алдылар
һәм шуларда яшәделәр. [26] Хишбун аморилэр патшасы Сихонның шә-
һәре булган. Сихон, Моабның элекке патшасына каршы сугышып,
Арнон елгасына кадәр аның бөтен җирен тартып алган булган.
[27] Менә шуңа күрә дә шагыйрьләр болай диләр:
– Хишбунга килегез, һәм ул яңадан төзелсен,
Сихонның шәһәре яңадан нигезләнсен.
28 Чөнки ут Хишбун шәһәреннән,
ялкын Сихон шәһәреннән чыкты;
һәм Моабтагы Ар шәһәре
Арнон биеклекләрен биләүчеләрне ялмап алды.
29 Әй Моаб, кайгы сиңа!
Сез, Кемошка* табынучы халык, һәлак булдыгыз!
Кемош угыллары качып киттеләр,
ә кызлары исә Амор патшасы Сихонга әсирлеккә төште.
30 Без аларны уклар белән тар-мар иттек.
Хишбун Дибонга кадәр һәлак ителде.
Без аларны Медебага, Нофахка кадәр юк иттек.

[31] Исраиллеләр исә аморилэр җирендә яшәп калды. [32] Муса Язер
шәһәрен тикшерү өчен шымчылар җибәрде. Шуннан соң алар

---

* 21:29 *Кемош* – Моаб илаһының исеме.

Язерне һәм аның әйләнә-тирәсендәге авылларны яулап алдылар, анда яшәүче амориләрне куып җибәрделәр.
33 Аннары исраиллеләр борылып, юл буенча Башанга таба киттеләр. Башан патшасы Ог үзе һәм аның бөтен халкы, исраиллеләргә каршы чыгып, Эдрегыйда алар белән сугышты.
34 Раббы Мусага әйтте:

– Огтан курыкма, чөнки Мин аны, аның барлык халкын һәм жирен синең кулга бирәчәкмен. Хишбунда яшәгән амориләр патшасы Сихон белән ничек эшләгән булсаң, аның белән дә шулай эшлә.
35 Шулай итеп, исраиллеләр Огны, аның угылларын, аның бөтен халкын, берсен дә калдырмыйча, кырып бетерделәр һәм жирен яулап алдылар.

*Бәлакның Билгамны чакыруы*

**22**
1 Исраиллеләр, аннан кузгалып, юлга чыктылар һәм Моаб тигезлегендә, Үрдүннең аръягындагы Әрихә каршында туктап, чатырларын кордылар.
2 Сиппор угылы Бәлак исраиллеләрнең амориләр белән нәрсә
эшләгәнен күрде. 3 Моаблылар бу халыктан бик курыктылар, чөнки исраиллеләр бик күп иде. Моаблылар исраиллеләр алдында куркуга төштеләр.
4 Моаблылар Мидьян аксакалларына әйттеләр:

– Бу халык, үгез кырдагы үләнне ашап бетергән кебек, әйләнә-тирәбездәге бар нәрсәне ашап бетерәчәк.

Сиппор угылы Бәлак исә бу вакытта Моаб патшасы иде. 5 Бәлак
Фөрат елгасы буенда үзенең туган жире Петорда яшәүче Бигур угылы Билгамны чакырды. Аңа: «Менә Мисырдан бер халык чыгып, жир йөзен каплап алды һәм ул халык хәзер минем жирем каршында
яши. 6 Хәзер кил дә минем өчен бу халыкка ләгънәт укы, чөнки ул миннән көчлерәк. Син ләгънәтләсәң, бәлкем, мин аны жиңә һәм бу жирдән куып чыгара алырмын. Мин беләм, син кемгә фатиха бирсәң, ул мөбарәк була, һәм кемне ләгънәтләсәң, ул каргалган була», – дигән сүзләрен җиткерү өчен, илчеләр җибәрде.
7 Моаб аксакаллары белән Мидьян аксакаллары, колларына фал ачу өчен түләм алып, Билгам янына килделәр һәм аңа Бәлак сүзләрен сөйләп бирделәр. 8 Билгам аларга әйтте:

– Бу төнне монда үткәрегез, Раббы миңа ничек дип әйтсә, сезгә шулай җавап кайтарырмын.

Һәм Моаб морзалары Билгам янында калдылар. 9 Аллаһы, Билгам янына килеп:

– Синең яндагы бу кешеләр кемнәр алар? – дип сорады.
10 Билгам Аллаһыга әйтте:

– Минем янга аларны Моаб патшасы Сиппор угылы Бәлак җибәргән һәм менә шуларны әйтергә кушкан: 11 «Менә, Мисырдан

бер халык чыкты да җир йөзен каплады. Хәзер кил дә минем өчен
бу халыкка ләгънәт укы. Бәлкем, мин аңа каршы сугыша алырмын
һәм аны куып чыгара алырмын».
12 Аллаһы Билгамга әйтте:
– Алар белән барма һәм бу халыкка ләгънәт укыма, чөнки ул
фатихаланган халык.
13 Билгам иртән торгач, аларга:
– Барыгыз, үз җирегезгә кайтыгыз, чөнки Раббы миңа сезнең
белән барырга рөхсәт итми, – диде.
14 Моаб морзалары, Бәлак янына кайтып, аңа әйттеләр:
– Билгам безнең белән килергә риза булмады.
15 Бәлак исә болардан да күбрәк санда һәм дәрәҗәлерәк морза-
лар җибәрде. 16 Алар, Билгам янына килеп, аңа:
– Сиппор угылы Бәлак: «Минем янга килүең тоткарланмасын.
17 Мин сиңа зур хөрмәт күрсәтермен һәм ни кушсаң, шуны эш-
ләрмен. Килче, зинһар, минем өчен бу халыкка ләгънәт укы», дип
әйтә, – диделәр.
18 Әмма Билгам аларга болай дип җавап бирде:
– Бәлак миңа хәтта сарае тулы көмешен һәм алтынын бирергә
булса да, кечкенә эшме ул, зур эшме, Раббы Алламның күрсәтмә-
сен кире кагып, һичнәрсә эшли алмыйм. 19 Шулай да, сез бу төнне
монда калыгыз, Раббы миңа тагын нәрсә әйтүен белермен.
20 Төнлә белән Аллаһы Билгам янына килеп, аңа әйтте:
– Бу кешеләр сине чакырырга килгәннәр икән, тор да алар бе-
лән бар, тик Мин кушканнарны гына үтә.

*Билгамның ана ишәге*

21 Иртә белән Билгам торды да, үзенең ана ишәген иярләп, Моаб
морзалары белән китеп барды. 22 Әмма Билгамның китеп барганы
өчен Аллаһының ачуы чыкты, һәм Раббының фәрештәсе, Билгам-
ны киреләндерү өчен, аның юлына аркылы басты. Билгам, үзе
белән ике хезмәтчесен ияртеп, ишәгенә атланып барды. 23 Ишәк,
кулына кылыч тотып юлда торучы Раббы фәрештәсен күрүгә, юл-
дан борылып кырга керде, ә Билгам исә, ишәген юлга кире кертү
өчен, аны кыйнады.
24 Аннан Раббы фәрештәсе ике йөзем бакчасы арасындагы тар
юлга төште, ә тар юлның ике ягында да дивар иде. 25 Ишәк исә,
Раббы фәрештәсен күреп, диварга сыенды һәм Билгамның аягын
диварга кысты; ул тагын ишәген кыйнады.
26 Аннары Раббы фәрештәсе алдан барды һәм уңга да, сулга да
китәргә юл булмаган тар урынга торып басты. 27 Ишәк, Раббы фә-
рештәсен күреп, Билгам астында җиргә ятты. Моңа Билгамның
ачуы килде, һәм ул ишәген таяк белән кыйнады. 28 Шулвакыт Раб-
бы ишәкне телле итте, һәм ишәк Билгамга:

– Нәрсә эшләдем соң мин сиңа? Инде өченче мәртәбә кыйныйсың мине, – диде.

[29] Билгам исә ишәккә:

– Чөнки син ачуымны чыгарасың! Кулымда кылыч булган булса, мин сине хәзер үк үтергән булыр идем, – диде.

[30] Ишәк исә Билгамга әйтте:

– Бөтен гомерең буе өстенә атланып йөргән ишәгең мин түгелме соң? Моңарчы синең алда болай кыландыммы соң?

Билгам җавап кайтарды:

– Юк.

*Фәрештәнең Билгамны шелтәләве*

[31] Шулчак Раббы Билгамның күзләрен ачты, һәм ул кулына кылыч тотып юлда торучы Раббы фәрештәсен күрде. Билгам иелеп, йөзе белән җиргә капланды.

[32] Раббы фәрештәсе аңа әйтте:

– Ни өчен син ишәгеңне инде өч тапкыр кыйнадың? Мин сине киреләндерү өчен юлга чыктым, чөнки минем алдымдагы юлың
дөрес юл түгел. [33] Ишәк, мине күреп, менә инде өч мәртәбә миннән читкә борылды. Әгәр дә ул миннән читкә борылмаган булса, мин сине үтергән, ә ишәкне исән калдырган булыр идем.

[34] Һәм Билгам Раббы фәрештәсенә әйтте:

– Мин гөнаһ эшләдем, чөнки юлымда миңа каршы якта торуыңны белмәдем. Бу сиңа ошамагач, кире китим, алайса.

[35] Раббы фәрештәсе Билгамга әйтте:

– Бу кешеләр белән бергә бар, әмма мин сиңа нәрсә әйтсәм, аларга шуны гына сөйлә.

Шуннан Билгам Бәлак морзалары белән бергә китте.

*Бәлакның Билгамны каршыларга чыгуы*

[36] Бәлак, Билгамның килү хәбәрен ишеткәч, аны каршы алу өчен Арнон чигенең кырыендагы моаблылар шәһәренә юнәлде.
[37] Бәлак Билгамга әйтте:

– Сине чакыру өчен кешеләр җибәргән идем түгелме? Нигә миңа килмәдең? Әллә мин сиңа хөрмәт күрсәтерлек хәлдә түгелме?

[38] Билгам исә Бәлакка әйтте:

– Менә, мин килдем. Әмма мин нәрсә дә булса әйтә аламмы? Аллаһы миңа нәрсә кушса, шуны гына сөйләячәкмен.

[39] Билгам Бәлак белән китеп, Кырьят-Хусот шәһәренә барып
җитте. [40] Бәлак, үгез һәм сарыклар корбан итеп, Билгам һәм аның
белән килгән морзаларга бирде. [41] Икенче көнне иртә белән Бәлак
Билгамны ияртеп, Бамот-Багал биеклегенә алып менде. Шуннан торып Билгам Исраил халкының бер өлешен күрде.

*Билгамның беренче гыйбрәтле сүзләре*

**23** [1] Билгам Бәлакка әйтте:
– Син монда миңа җиде мәзбәх төзет һәм минем өчен
җиде үгез бозау белән җиде сарык тәкәсе әзерлә.
[2] Бәлак Билгам әйткәнчә эшләде, һәм Бәлак белән Билгам һәр мәзбәх өстенә бер үгез бозау белән бер сарык тәкәсе тәкъдим иттеләр.
[3] Билгам Бәлакка әйтте:
– Син үзеңнең яндырылган тәкъдимең янында торып тор, ә мин китим, бәлки, Раббы мине каршыларга чыгар. Ул миңа нәрсә әйтсә, шуны сиңа белдерермен.
Шуннан ул бер кысыр калку урынга менеп китте.
[4] Анда Аллаһы Билгам белән очрашты, һәм Билгам Аңа әйтте:
– Мин җиде мәзбәх эшләдем һәм һәркайсына бер үгез бозау белән бер сарык тәкәсе тәкъдим иттем.
[5] Раббы Билгамның теленә сүзләр салды һәм әйтте:
– Бәлак янына кире бар һәм аңа Мин әйткәннәрне җиткер.
[6] Шулай итеп, Билгам Бәлак янына кире килде. Менә Бәлак үзе
һәм Моабның барлык морзалары аның яндырылган тәкъдиме янына
бастылар. [7] Билгам, үзенең гыйбрәтле сүзләрен башлап, болай диде:
– Көнчыгыш тауларыннан чыккан Моаб патшасы Бәлак
мине Арамнан алып килде.
«Кил, минем өчен Ягъкубка ләгънәт укы.
Кил, Исраилгә бәддога укы», – дип мине чакырды.
[8] Аллаһы Үзе ләгънәт итмәгәнне мин ничек ләгънәт укыйм?
Аңа Раббы бәддога кылмаганны мин ничек бәддога
кылыйм ди?
[9] Мин бу халыкны кыялар түбәсеннән күрәм;
калкулыклардан аны тамаша кылам.
Менә, халык аерым яши;
ул халыклар арасында исәпләнми.
[10] Ягъкубның тузан бөртекләрен кем саный алыр?
Яисә исраиллеләрнең дүрттән бер өлешенең санын кем
исәпли алыр?
Җаным workel гаделләр үлеме белән үлсен
һәм минем ахырым гаделләрнеке кебек булсын!

[11] Бәлак Билгамга әйтте:
– Син миңа нәрсә эшләдең? Мин сине дошманнарымны ләгънәт итү өчен чакырдым, ә син аларны мөбарәк итәсең!
[12] Ул җавап биреп әйтте:
– Миңа Раббы нәрсә сөйләсә, мин шуны төгәл итеп әйтергә тиеш түгелме?

*Билгамның икенче гыйбрәтле сүзләре*

[13] Бәлак аңа әйтте:
– Минем белән башка урынга бар, шуннан аларны күрерсең, барысын да түгел, әмма бер өлешен генә. Шуннан торып, минем өчен аларга ләгънәт укы.
[14] Шуннан соң Бәлак аны Софим яланына, Песгә тау башына алып менде һәм анда җиде мәзбәх төзетте, һәр мәзбәх өстенә бер үгез бозау белән бер сарык тәкәсе китертте.
[15] Билгам Бәлакка әйтте:
– Син монда үзеңнең яндырылган тәкъдимең янында торып тор, ә мин анда Аллаһыны каршы алыйм.
[16] Раббы Билгам белән очрашты һәм аның теленә сүзләрен салды һәм әйтте:
– Бәлак янына кире бар һәм аңа Мин әйткәннәрне җиткер.
[17] Һәм Билгам Бәлак янына кире кайтты. Менә Бәлак үзе һәм Моабның барлык морзалары аның яндырылган тәкъдиме янына бастылар.
Бәлак аңардан:
– Раббы сиңа нәрсә сөйләде? – дип сорады.
[18] Билгам, үзенең гыйбрәтле сүзләрен башлап, болай диде:
– Әй, Бәлак, тор да тыңла,
әй, Сиппор угылы, мин әйткәннәргә колак сал.
19 Аллаһы бит Ул кеше заты түгел,
Ул ялган сөйләми;
Ул адәм угылы да түгел,
Үзенең фикерен үзгәртмәс.
Ул сөйләр дә эшен эшләмәсме?
Ул сүз бирер дә аны үтәмәсме?
20 Менә, мин фатиха бирү өчен боерык кабул иттем.
Ул фатиха кылды һәм мин моны һич тә үзгәртә алмыйм.
21 Ягъкубта бәла күренмәс,
Исраилдә бәхетсезлек сизелмәс.
Аларның Раббы Алласы алар белән,
һәм алар арасында патшага шат кычкыру була.
22 Аллаһы аларны Мисырдан алып чыкты,
алар кыргый үгез мөгезләре кебек.
23 Ягъкубка каршы нинди дә сихерчелек файдасыз,
Исраилгә каршы күрәзәлек итү дә файдасыз.
Хәзер Ягъкуб белән Исраил хакында кешеләр әйтерләр:
– Аллаһы нәрсәләр эшли!
24 Менә халык ана арыслан кебек тора,
үтерелгән корбанын ашап бетергәнче
һәм аның канын эчеп бетергәнче
ятмаган ата арыслан кебек күтәрелә.

[25] Бәлак Билгамга әйтте:
– Алайса аларны ләгънәтләмә дә, фатиханы да бирмә.
[26] Җавап кайтарып, Билгам Бәлакка әйтте:
– Раббы миңа нәрсә кушса, мин шулай эшләячәкмен дип сиңа әйтмәдемме әллә?

*Билгамның өченче гыйбрәтле сүзләре*

[27] Бәлак Билгамга әйтте:
– Әйдә, мин сине башка урынга алып барыйм, бәлки, Аллаһы мәгъкуль күрер, шул урыннан минем өчен аларны ләгънәт итәрсең.
[28] Шуннан соң Бәлак Билгамны чүлгә таба караган Пигур тавының башына алып менеп китте.
[29] Билгам Бәлакка әйтте:
– Монда миңа җиде мәзбәх төзет һәм минем өчен җиде үгез бозау һәм җиде сарык тәкәсе китерт.
[30] Бәлак Билгам кушканча эшләде һәм һәр мәзбәх өстенә бер үгез бозау һәм бер сарык тәкәсе тәкъдим итте.

## 24

[1] Билгам Исраилне мөбарәк кылуның Раббыга мәгъкуль
булуын күрде. Элекке кебек күрәзәлек итү өчен китмәде,
әмма хәзер йөзен чүлгә таба борды. [2] Билгам күз төше-
реп алды һәм Исраилнең үз ыруглары буенча урнашуын күрде. Бил-
гам өстенә Аллаһы Рухы инде; [3] һәм Билгам, үзенең гыйбрәтле сүз-
ләрен башлап, болай диде:

– Бигур угылы Билгам сөйли моны,
ачык карашлы кеше сөйли,
[4] Аллаһының сүзләрен ишетүче,
Кодрәт Иясеннән күренешне күрүче,
егылып төшкән,
ә күзләре ачык булган кеше сөйли:
[5] «Әй, Ягъкуб, синең чатырларың,
әй, Исраил, синең торакларың нинди гүзәл!
[6] Алар үзәннәр кебек җәеләләр,
елга буендагы бакчалар кебек,
Раббы утырткан йөзьяшәр үләннәр кебек,
су буендагы эрбет агачлары кебек үсәләр.
[7] Аның чиләкләреннән су агачак,
аның орлыгы мул итеп су сибелеп үсәчәк,
аның патшасы Агаг патшадан бөегрәк булачак,
һәм аның патшалыгы күтәреләчәк.
[8] Аллаһы аны Мисырдан алып чыкты,
ул кыргый үгез мөгезләре кебек,
үзенә дошман булган халыкларны ашап бетерә,
аларның сөякләрен ваклый

һәм үзенең уклары белән дошманнарын тар-мар итә.
9 Ул иелде, ана вә ата арыслан кебек ята,
аны торгызырга кем соң җөрьәт итсен?
Сине мөбарәк итүче мөбарәк булсын,
сине ләгънәт итүче ләгънәтләнсен!»

10 Бәлакның Билгамга ачуы чыкты, Бәлак кулларын җәеп җибәрде һәм Билгамга әйтте:
– Мин сине минем дошаннарымны ләгънәт итү өчен чакырдым,
ә син менә өченче тапкыр инде аларны мөбарәк итәсең. 11 Хәзер үз
урыныңа йөгер! Мин сиңа зур хөрмәт күрсәтергә теләдем, ә менә Раббы сине ул хөрмәттән мәхрүм итте.
12 Билгам Бәлакка әйтте:
– Мин синең миңа җибәргән илчеләреңә: 13 «Бәлак үзенең сарае
тулы алтын-көмешен миңа бирсә дә, үз теләгем белән яхшылык яки яманлык эшләү өчен Раббы сүзеннән чыга алмыйм. Раббы миңа нәрсә әйтсә, шуны гына сөйләячәкмен», – дип белдермә-
деммени? 14 Менә хәзер мин үз халкым янына барам. Бу халыкның
киләчәктә синең халкыңа нәрсә эшләячәген сиңа белдерәм.

*Билгамның дүртенче гыйбрәтле сүзләре*

15 Билгам, үзенең гыйбрәтле сүзләрен башлап, болай диде:
– Бигур угылы Билгам сөйли моны,
ачык карашлы кеше сөйли,
16 Аллаһының сүзләрен ишетүче,
Аллаһы Тәгаләдән белем алучы,
Кодрәт Иясеннән күренешне күрүче,
егылып төшкән,
ә күзләре ачык булган кеше сөйли:
17 «Мин аны күрәм, әмма шушы вакытта түгел;
аңа карыйм, ләкин якын түгел әле ул.
Ягъкубтан йолдыз чыгачак;
ә Исраилдән хакимлек таягы күтәреләчәк.
Ул Моаб җирен кырып салачак
һәм Шет угылларын тар-мар итәчәк.
18 Эдом басып алыначак,
Сәгыйрны аның дошманнары басып алачак,
ә Исраил үзенең көчен күрсәтәчәк.
19 Ягъкуб токымыннан булган берәү хакимлек итәчәк
һәм шәһәрдә калганнарны юк итәчәк».

*Билгамның соңгы гыйбрәтле сүзләре*

20 Шуннан соң Билгам Амалыкны күрде һәм, гыйбрәтле сүзләрен башлап, болай диде:

– Амалык баш халык иде,
әмма ахырда ул һәлак булачак.

21 Аннан ары ул кынлыларны күрде һәм, үзенең гыйбрәтле сүзләрен башлап, болай диде:
– Синең торагың нык,
синең ояң кыя өстенә корылды.
22 Ашшур сине әсирлеккә алып киткәнгә кадәр,
Кабил бөлдереләчәк.

23 Билгам, үзенең гыйбрәтле сүзләрен башлап, болай диде:
– И Аллаһы, моны эшләгән вакытта кем
генә исән калыр икән!
24 Киттиләрдән диңгез көймәләре киләчәк
һәм алар Ашшурны буйсындырачак,
шулай ук Эберны да буйсындырачаклар;
әмма соңгы чиктә алар да һәлак булачак!

25 Аннары Билгам торды да кире үзе яшәгән урынга китеп барды,
Бәлак та үз юлы белән китте.

*Исраиллеләрнең Багал-Пигурга табынуы*

**25** 1 Шиттимдә яшәгән вакытта, исраиллеләр Моаб кызлары белән зина кыла башладылар. 2 Ул кызлар аларны үз
илаһларына корбаннарын багышлаган җыелышка барырга чакырдылар; халык ул корбаннарны ашады һәм аларның илаһларына табынды. 3 Шулай итеп, исраиллеләр Багал-Пигурга табынып,
үзләрен аңа бәйләделәр, шунлыктан Раббының аларга ачуы чыкты.
4 Раббы Мусага әйтте:
– Халыкларның барча башлыкларын җыеп ал да аларны Раббы алдында кояш чыкканда асып үтер, шуннан соң Раббының ачуы исраиллеләрдән китәр.
5 Муса Исраил хакимнәренә әйтте:
– һәрберегез Багал-Пигурга табынып, үзегезнең аңа бәйле кешеләрегезне үтерегез.
6 Муса белән Исраилнең бөтен җәмәгатьчелеге Изге чатырга керү урыны янында матәм тоттылар. Менә, исраиллеләрдән берәү, аларның күз алдында, үз кардәшләре янына бер мидьянлы хатынны алып
килде. 7 Рухани Һарун угылы Элгазарның угылы Пинхәс, моны
күргәч, җәмәгатьчелек арасыннан чыгып, кулына сөңгесен алды.
8 Ул, исраилле ир артыннан йокы бүлмәсенә кереп, шул исраилле ир белән мидьянлы хатынны чәнчеп үтерде. Шуннан соң исраиллеләрне харап итүче үләт туктады. 9 Үләттән һәлак булучылар саны
егерме дүрт мең кешегә җиткән иде.

10 Раббы Мусага әйтте:
11 – Рухани Һарун угылы Элгазарның угылы Пинхәс исраилле-
ләргә каршы кабарган ачуымны басты. Чөнки ул, Минем кебек, ис-
раиллеләр арасында башка илаһларга түзеп тормады. Шунлыктан
Мин, башка илаһларга түзеп тормасам да, исраиллеләрне тар-мар
итмәдем. 12 Шуңа күрә игълан ит: «Мин аңа Үземнең тынычлык ки-
лешүемне бирәм. 13 Һәм бу аңа һәм аның нәселләренә мәңгелек
руханилык килешүе булачак, чөнки ул үзенең Алласы өчен башка
илаһларга түзеп тормады һәм исраиллеләрнең гөнаһын йолып алды».
14 Мидьянлы хатын белән бергә үтерелгән исраилленең исеме
Зимри иде. Ул Салу угылы, Шимун ыругындагы бер гаиләнең баш-
лыгы. 15 Ә үтерелгән мидьянлы хатынның исеме Көзби, ул – мидь-
янлылар ыругыннан бер гаиләнең башлыгы Сурның кызы.
16 Раббы Мусага әйтте:
17 – Мидьянлылар белән дошманлаш һәм аларны тар-мар ит.
18 Чөнки алар үзләренең мәкерлекләре белән Пигур вакыйгасында
һәм үләт көнендә үтерелгән аларның кыз кардәшләре – Мидьян
башлыгының кызы Көзби белән күңелегезне аздырып, сезнең бе-
лән дошманлаштылар.

*Исраиллеләрнең санын икенче тапкыр исәпкә алу*

**26** 1 Менә шул үләттән соң, Раббы Мусага һәм Һарун угы-
лы рухани Элгазарга әйтте:
2 – Бөтен Исраил җәмәгатьчелегенең егерме яшьтән алып
аннан өлкәнрәк булган, сугышка яраклыларының һәммәсен гаи-
ләләре буенча исәпкә алыгыз.
3 Муса белән рухани Элгазар Үрдүн елгасы ярында, Әрихә кар-
шындагы Моаб үзәнлегендә, исраиллеләргә әйттеләр:
4 – Раббының Мусага әмер итүенчә, егерме яшьтән алып аннан
өлкәнрәк булганнарның барысын да исәпкә алыгыз.
Болар Мисыр җиреннән чыккан исраиллеләр:
5 Исраилнең беренче угылы – Рубин. Рубинның угыллары: Ха-
нохтан – ханохлылар кабиләсе, Паллудан – паллулылар кабиләсе;
6 Хесроннан – хесронлылар кабиләсе, Кәрмидән – кәрмиләләр ка-
биләсе. 7 Бу – рубинлылар кабиләләре. Алардан исәпкә алынган-
нарның саны кырык өч мең җиде йөз утыз кеше булды. 8 Паллуның
угылы Элиаб. 9 Элиабның угыллары: Немуил, Датан һәм Абирам.
Датан һәм Абирам – халык арасыннан сайланган түрәләр, алар
Корах тарафдарлары белән бергә Раббыга каршы фетнә күтәргән-
нәр һәм Муса белән Һарунга каршы ризасызлык белдергәннәр.
10 Шулчак җир үзенең авызын ачты да Корах белән бергә аларны
йотты; ут чыгып, ике йөз илле кешене яндырган вакытта, Корах та-
рафдарлары да үлде. Ә алар, кисәтү өчен, гыйбрәт буларак калды-
рылды. 11 Әмма Корахның угыллары исән калдылар.

[12] Кабиләләре буенча Шимун угыллары: Немуилдән – немуилле-
ләр кабиләсе, Яминнән – яминлеләр кабиләсе, Яхиннан – яхин-
лылар кабиләсе. [13] Зерахтан – зерахлылар кабиләсе, Шаулдан –
шауллылар кабиләсе. [14] Шимун кабиләләрендә егерме ике мең ике
йөз кеше булды.

[15] Кабиләләре буенча Гәд угыллары: Сефоннан – сефонлылар ка-
биләсе, Хәггидән – хәггиләләр кабиләсе, Шунидан – шуниләләр
кабиләсе. [16] Featured Ознидән – озниләләр кабиләсе, Эридән – эриләләр ка-
биләсе. [17] Арудидан – арудилылар кабиләсе, Арелидан – арели-
лылар кабиләсе. [18] Гәд угылларыннан исәпкә алынган кабиләләр
шулар булды: алар кырык мең биш йөз кеше исәпләнде.

[19] Эр һәм Онан – Йәһүдә угыллары, әмма алар Кәнган җирендә
үлеп калдылар. [20] Кабиләләре буенча Йәһүдә угыллары менә болар:
Шеладан – шеланилар кабиләсе, Перестән – переслеләр кабиләсе,
Зерахтан – зерахлылар кабиләсе. [21] Перес угыллары: Хесроннан –
хесронлылар кабиләсе, Хамулдан – хамуллылар кабиләсе. [22] Йәһү-
дә угылларыннан исәпкә алынган кабиләләр шулар булды: алар
җитмеш алты мең биш йөз кеше исәпләнде.

[23] Кабиләләре буенча Исәсхәр угыллары: Толадан – толалылар
кабиләсе, Пуаһтан – пуниләр кабиләсе, [24] Йашубтан – йашублылар
кабиләсе, Шимруннан – шимрунлылар кабиләсе. [25] Исәсхәр угыл-
ларыннан исәпкә алынган кабиләләр шулар булды: алар алтмыш
дүрт мең өч йөз кеше исәпләнде.

[26] Кабиләләре буенча Зәбулун угыллары: Середтән – середлеләр
кабиләсе, Элоннан – элонлылар кабиләсе, Яхлиелдән – яхлиелле-
ләр кабиләсе. [27] Зәбулун угылларыннан исәпкә алынган кабиләләр
шулар булды: алар алтмыш мең биш йөз кеше исәпләнде.

[28] Кабиләләре буенча Йосыф угыллары – Менашше һәм Эфраим.
[29] Менашше угыллары: Макирдан – макирлылар кабиләсе, Макир
Гилыгадның атасы булган; Гилыгадтан – гилыгадлылар кабиләсе.
[30] Менә Гилыгад угыллары: Игызырдан – игызырлылар кабиләсе,
Хелыктан – хелыклылар кабиләсе, [31] Асриелдән – асриелләләр ка-
биләсе, Шехемнән – шехемлеләр кабиләсе, [32] Шемидәдән – ше-
мидәлеләр кабиләсе, Хефердән – хеферлеләр кабиләсе. [33] Хефер
угылы Селуфхадның угыллары булмады, бары тик кызлары гына
бар иде. Селафхад кызларының исемнәре: Махла, Ноа, Хөглә, Мил-
кә һәм Тирса. [34] Менашше угылларыннан исәпкә алынган кабилә-
ләр шулар булды: алар илле ике мең җиде йөз кеше исәпләнде.

[35] Кабиләләре буенча Эфраим угыллары болар булды: Шутелах-
тан – шутелахлылар кабиләсе, Бәхердән – бәхерлеләр кабиләсе,
Таханнан – таханилар кабиләсе. [36] Менә Шутелах угыллары болар:
Эраннан – эранлылар кабиләсе. [37] Эфраим угылларыннан исәпкә
алынган кабиләләр шулар булды: алар утыз ике мең биш йөз кеше
исәпләнде. Болар Йосыф угылларының кабиләләре иде.

38 Кабиләләре буенча Беньямин угыллары болар булды: Беладан –
белалылар кабиләсе, Ашбелдан – ашбеллылар кабиләсе, Ахирам-
нан – ахирамлылар кабиләсе; 39 Шефуфамнан – шефуфамлылар
кабиләсе, Хуфамнан – хуфамлылар кабиләсе. 40 Беланың угылла-
ры – Ард һәм Нагам: Ардтан – ардлылар кабиләсе, Нагаманнан –
нагаманлылар кабиләсе. 41 Беньямин угылларыннан исәпкә алын-
ган кабиләләр шулар булды: алар кырык биш мең алты йөз кеше
исәпләнде.

42 Кабиләләре буенча Дан угыллары болар булды: Шухамнан –
шухамлылар кабиләсе. Дан угылларыннан исәпкә алынган каби-
ләләр шулар булды: 43 алар алтмыш дүрт мең дүрт йөз кеше исәп-
ләнде. Алар барысы шухамлылар кабиләләре иде.

44 Кабиләләре буенча Ашир угыллары болар булды: Имнадан –
имналылар кабиләсе, Ишвидән – ишвиеләр кабиләсе, Берига-
дан – беригалылар кабиләсе, 45 Берига угылларыннан: Хебердән –
хеберлеләр кабиләсе, Малкиелдән – малкиеллеләр кабиләсе. 46 Ашир
кызының исеме – Серах. 47 Ашир угылларыннан исәпкә алынган ка-
биләләр шулар булды: алар илле өч мең дүрт йөз кеше исәпләнде.

48 Кабиләләре буенча Нәфтали угыллары болар булды: Яхсиел-
дән – яхсиеллеләр кабиләсе, Гүнидән – гүнилеләр кабиләсе, 49 Йе-
сердән – исриләр кабиләсе, Шиллемнән – шиллемлеләр кабиләсе.
50 Нәфтали угылларыннан исәпкә алынган кабиләләр шулар бул-
ды: алар кырык биш мең дүрт йөз кеше исәпләнде.

51 Менә исраиллеләрдән исәпкә алынганнарның саны: алты йөз
бер мең җиде йөз утыз кеше.

52 Раббы Мусага әйтте:

53 – Исәпкә алынган исемнәр санына карап, аларга мирас итеп
җир бирелергә тиеш. 54 Зур ыругка җир мирасын күбрәк итеп, ә
кечкенәгә азрак итеп бир; җир мирасы һәр ыругка исәпкә алын-
ганнарның санына карап бирелергә тиеш. 55 Җир шобага салып бү-
ленергә тиеш. Алар ата-бабаларының ыруг исемнәре буенча мирас
итеп җир алырга тиешләр. 56 Җир мираслары кеше саны аз булган
һәм кеше саны күп булган ыругларга шобага салып бүленергә тиеш.

57 Кабиләләре буенча левиләрдән исәпкә алынганнар болар: Гер-
шоннан – гершонлылар кабиләсе, Коһаттан – коһатлылар кабиләсе,
Мераридан – мерарилылар кабиләсе. 58 Болар да Леви кабиләләре:
либниләр кабиләсе, хебрунлылар кабиләсе, махлилылар кабиләсе,
мушилылар кабиләсе, корахлылар кабиләсе.

Коһат – Амрамның атасы. 59 Амрам хатынының исеме – Йөхә-
бәд. Ул Мисырда туган Леви кызы һәм ул хатын Амрамга Һарунны,
Мусаны һәм аларның кыз туганнары Мириамны тудырган. 60 Һарун-
ның угыллары: Надаб, Абиһу, Элгазар һәм Итамар. 61 Әмма Надаб
белән Абиһу Раббы алдында рөхсәт ителмәгән ут тәкъдим иткән ва-
кытта һәлак булдылар.

62 Һәм бер айдан алып аннан өлкән яшьтәге Леви ирләренең са-
ны егерме өч мең кеше булды. Алар исраиллеләр белән бергә исәп-
кә алынмадылар, чөнки исраиллеләр арасында левиләргә мирас
итеп җир бирелмәде.
63 Муса белән рухани Элгазар тарафыннан исәпкә алынганнар
менә шулар булды. Алар исраиллеләрне Үрдүн елгасы ярында, Әри-
хә каршындагы Моаб үзәнлегендә исәпкә алдылар. 64 Әмма Муса
белән рухани Һарун тарафыннан Синай чүлендә исәпкә алынган
исраиллеләрдән бер генә кеше дә әлеге исәпкә алынучылар ара-
сында булмады. 65 Чөнки алар хакында Раббы: алар һәммәсе дә чүл-
дә үләчәк, диде. Алар арасыннан бер кеше дә калмады, бары тик
Ифунни угылы Кәлеб белән Нун угылы Йешуа гына исән калды.

### *Угылы булмаган гаилә өчен мирас кагыйдәләре*

**27** 1-2 Йосыф угылы Менашше кабиләләреннән Менашше
угылы Макир, Макир угылы Гилыгад, Гилыгад угылы
Хефер, Хефер угылы Селуфхад кызларының исемнәре:
Махла, Ноа, Хөглә, Милкә һәм Тирса. Алар Изге чатырга керү
урыны төбенә Муса белән рухани Элгазар алдына, җитәкчеләр һәм
барча җәмәгатьчелек алдына килеп бастылар да әйттеләр:
3 – Безнең атабыз чүлдә үлде һәм ул Корах тарафдарларының
Раббыга каршы оештырылган фетнәсендә катнашмады, әмма ул үз
гөнаһы өчен үлде, ә аның угыллары булмады. 4 Атабызның угылы
булмаганы өчен, аның исеме үзенең кабиләсеннән сызып ташла-
нырга тиешме? Атабызның туганнары арасында безгә дә биләмә
бирегез.
5 Муса аларның дәгъвасын Раббыга җиткерде. 6 Раббы Мусага
әйтте:
7 – Селуфхад кызлары дөресен сөйлиләр. Аталарының туганнары
арасында аларга мирас итеп биләмә бир һәм аталарының мирасын
аларга тапшыр. 8 Һәм исраиллеләргә сөйләп аңлат: «Әгәр берәү үл-
сә һәм аның угылы булмаса, мирасы аның кызына тапшырылырга
тиеш. 9 Әгәр аның кызы да булмаса, ул чагында аның мирасын ту-
ганнарына тапшырыгыз. 10 Әгәр туганнары да булмаса, аның мира-
сын атасының туганнарына бирегез. 11 Әгәр атасының туганнары
булмаса, аның мирасын кабиләсендәге иң якын туганына бирегез,
һәм ул аның биләмәсе булачак. Менә бу – Раббының Мусага әмер
итүенчә, исраиллеләргә бирелгән канунның кагыйдәсе булачак».

### *Йешуаның җитәкчелекне мирас итеп алуы*

12 Аннары Раббы Мусага әйтте:
– Менә шушы Әбарим тавына мен дә Мин исраиллеләргә бирә-
чәк җиргә кара. 13 Аны караганнан соң, туганың Һарун кебек, син
дә үлгән үз ата-бабаларың белән кушылырсың. 14 Чөнки сез Сыйн

чүлендә, җәмәгатьчелек Мине гаепләгән вакытта, Мин әйткәннәрне тыңламадыгыз; сулар янында, аларның күз алдында Минем изгелегемне танымадыгыз.

(Болар Сыйн чүлендәге Мериба-Кадыш сулары иде.)

15 Муса Раббыга әйтте:

16 – Раббы, барлык мәхлук рухларның Алласы, бу җәмәгатьчелекнең башлыгы итеп башка кешене билгеләсәң иде. 17 Ул алар алдында чыксын, алар алдында керсен. Һәм ул аларны әйдәп барсын, аларны алып кайтсын. Шулай итеп, Раббының халкы көтүчесез сарыклар кебек калмасын иде.

18 Раббы Мусага әйтте:

– Үзендә Рух булган кешене – Нун угылы Йешуаны янына ал да кулыңны аның өстенә куй. 19 Аны рухани Элгазар һәм бөтен җәмәгатьчелек алдына бастырып куй һәм алар күз алдында җитәкчелекне аңа йөклә. 20 Исраилнең бөтен җәмәгатьчелеге аны тыңласын өчен, үз дәрәҗәңнең бер өлешен аңа бир. 21 Ул рухани Элгазарга мөрәҗәгать итәчәк. Элгазар Раббы алдында изге жирәбәләр* белән Раббы ихтыярын Йешуа өчен хәл итәчәк. Йешуа үзе һәм аның белән бергә Исраилнең бөтен җәмәгатьчелеге Элгазарның сүзе белән чыгачак һәм аның сүзе белән керәчәк.

22 Муса Раббы әмер иткәнчә эшләде һәм Йешуаны рухани Элгазар һәм бөтен җәмәгатьчелек алдына бастырып куйды. 23 Раббы әмер иткәнчә, Муса үзенең кулларын Йешуа өстенә куйды һәм аңа җитәкчелекне йөкләде.

*Көндәлек тәкъдимнәр*

**28** 1 Раббы Мусага әйтте:

2 – Исраиллеләргә әмер ит һәм әйт: «Миңа яндыру бүләге буларак, ризык бүләкләрен билгеләнгән вакытында китерегез; аның тәмле исе Минем күңелемә хуш килер». 3 Һәм аларга әйт: «Сез Раббыга яндыру бүләге итеп бирергә тиеш булган корбаннар менә болар: көндәлек тулаем яндыру корбаны буларак, һәркөн китерелергә тиешле кимчелексез бер яшьлек ике тәкә бәрән.
4 Бәрәннәрнең берсен иртән, икенчесен кичен китер; 5 һәм, икмәк бүләге буларак һиннең дүрттән бер өлеше кадәр зәйтүн мае белән аралаштырылган, епаның уннан бер өлеше кадәр иң яхшы бодай оны белән бергә тәкъдим ит. 6 Менә бу – Синай тавында башланган көндәлек тулаем яндыру корбаны, аның тәмле исе Раббының күңеленә хуш килер. 7 Һәр бәрән өчен һиннең дүрттән бер өлеше кадәр шәраб бүләге китер. Раббыга шәраб бүләген Изге бүлмәдә тәкъдим ит. 8 Икенче бәрәнне кичен китер, аның икмәк һәм шәраб

* 27:21 *Изге жирәбәләр* – бу сүз яһүдчә «урим» дигән тәгъбирне аңлата. Аллаһының ихтыярын белү өчен, рухани алардан файдаланган.

бүләкләре иртә белән тәкъдим ителгән икмәк һәм шәраб бүләкләре кебек булачак. Әлеге яндыру бүләгенең тәмле исе Раббының күңеленә хуш килер».

*Шимбә көн тәкъдимнәре*

[9] «Ә шимбә көнне кимчелексез бер яшьлек ике бәрән һәм, аның икмәк бүләге итеп, зәйтүн мае белән аралаштырылган, епаның уннан ике өлеше кадәр иң яхшы бодай оны һәм аның шәраб бүләген бергә тәкъдим итегез. [10] Бу – көндәлек тулаем яндыру корбаны һәм, аның икмәк бүләгеннән тыш, һәр шимбә өчен тулаем яндыру корбаны була».

*Айлык тәкъдимнәр*

[11] «Яңа ай башында, Раббыга тулаем яндыру корбаны итеп, ике үгез бозау һәм бер сарык тәкәсе, кимчелексез бер яшьлек җиде тәкә бәрән китерегез. [12] Һәм һәр үгез бозау өчен икмәк бүләге итеп зәйтүн мае белән аралаштырылган, епаның уннан өч өлеше кадәр иң яхшы бодай оны һәм һәр сарык тәкәсе өчен икмәк бүләге итеп зәйтүн мае белән аралаштырылган, епаның уннан ике өлеше кадәр иң яхшы бодай оны китерегез. [13] Һәр тәкә бәрән өчен икмәк бүләге итеп зәйтүн мае белән аралаштырылган, епаның уннан бере кадәр иң яхшы бодай оны тәкъдим итегез. Менә бу – тулаем яндыру корбаны буларак, Раббыга тәкъдим ителә торган яндыру бүләге; аның тәмле исе Раббының күңеленә хуш килер. [14] Һәм аларның шәраб бүләкләре һәр үгез бозау өчен ярты һин, бер сарык тәкәсе өчен һиннең өчтән бере кадәр һәм һәр тәкә бәрән өчен һиннең дүрттән бере кадәр булырга тиеш. Бу – елның барлык айларында яңа ай башы өчен тулаем яндыру корбаны була. [15] Көндәлек тулаем яндыру корбаны һәм аның шәраб бүләгеннән тыш, өстәмә, Раббыга гөнаһ йолу корбаны итеп бер кәҗә тәкәсе тәкъдим итегез».

*Коткарылу бәйрәме тәкъдимнәре*

[16] «Беренче айда, айның ундүртенче көнендә – Коткарылу бәйрәме. [17] Шул ук айның унбишенче көнендә бәйрәм башлана: җиде көн төче икмәк ашарга тиешсез. [18] Беренче көнне изге җыелыш үткәрегез; ул көнне бернинди дә эш эшләмәгез. [19] Раббыга ут белән тулаем яндыру корбаны: ике үгез бозау, бер сарык тәкәсе һәм бер яшьлек җиде тәкә бәрән китерегез. Болар барысы да кимчелексез булырга тиеш. [20] Һәм аларның икмәк бүләге буларак, һәр үгез бозау өчен епаның уннан өч өлеше кадәр һәм бер сарык тәкәсе өчен епаның уннан ике өлеше кадәр, [21] җиде бәрәннең һәрберсенә епаның уннан бер өлеше кадәр зәйтүн мае белән аралаштырылган иң яхшы бодай оны китерегез. [22] Һәм сезне гөнаһтан арындыру өчен, гөнаһ йолу корбаны итеп бер кәҗә тәкәсе тәкъдим итегез. [23] Боларны, иртән китерелгән

көндәлек тулаем яндыру корбаныннан тыш, өстәмә тәкъдим итегез.
[24] Шул рәвешле, яндыру бүләге буларак, җиде көннең һәр көнендә ризык бүләген тәкъдим итегез; аның тәмле исе Раббының күңеленә хуш килер. Аны, көндәлек тулаем яндыру корбаны һәм аның шәраб бүләгеннән тыш, өстәмә тәкъдим итегез. [25] Җиденче көнне изге җыелыш үткәрегез; ул көнне бернинди дә эш эшләмәгез».

*Уңыш бәйрәме тәкъдимнәре*

[26] «Уңыш бәйрәменең, ягъни Атналар бәйрәменең беренче көнендә, Раббыга яңа бөртек бүләге китергән вакытта, изге җыелыш үткәрегез. Бу көнне бернинди дә эш эшләмәгез. [27] Һәм Раббыга, тулаем яндыру корбаны буларак, ике үгез бозау, бер сарык тәкәсе һәм бер яшьлек җиде тәкә бәрән тәкъдим итегез; аның тәмле исе Раббының күңеленә хуш килер. [28-29] Алар белән бергә, икмәк бүләге итеп, һәр үгез бозау өчен епаның уннан өч өлеше кадәр, сарык тәкәсе өчен епаның уннан ике өлеше кадәр һәм җиде бәрәннең һәрберсе өчен епаның уннан бер өлеше кадәр зәйтүн мае белән аралаштырылган иң яхшы бодай оны китерегез. [30] Һәм сезне гөнаһтан арындыру өчен, бер кәҗә тәкәсе тәкъдим итегез. [31] Көндәлек тулаем яндыру корбаны һәм аның икмәк бүләгеннән тыш, өстәмә, боларны шәраб бүләкләре белән бергә тәкъдим итегез. Бу корбаннар кимчелексез булырга тиеш».

*Быргы бәйрәме тәкъдимнәре*

**29** [1] «Җиденче айның беренче көнендә изге җыелыш үткәрегез; ул көнне бернинди дә эш эшләмәгез; ул көн сездә быргы кычкырту көне булсын. [2] Корбанның тәмле исе Раббының күңеленә хуш килсен өчен, тулаем яндыру корбаны итеп бер үгез бозау, бер сарык тәкәсе һәм бер яшьлек җиде бәрән тәкъдим итегез. Болар кимчелексез булырга тиеш. [3] Һәм алар белән бергә, икмәк бүләге итеп, бер үгез бозау өчен епаның уннан өч өлеше кадәр, бер сарык тәкәсе өчен епаның уннан ике өлеше кадәр, [4] җиде бәрәннең һәрберсе өчен епаның уннан бер өлеше кадәр зәйтүн мае белән аралаштырылган иң яхшы бодай оны китерегез. [5] Сезне гөнаһтан арындыру өчен гөнаһ йолу корбаны итеп бер кәҗә тәкәсе тәкъдим итегез. [6] Боларны, канун буенча, айлык белән көндәлек тулаем яндыру корбаннары һәм аларның икмәк белән шәраб бүләкләреннән тыш, өстәмә тәкъдим итегез. Алар – Раббыга китерелгән яндыру бүләкләре, аларның тәмле исе Раббының күңеленә хуш килер».

*Гөнаһ йолу көне тәкъдимнәре*

[7] «Җиденче айның унынчы көнендә изге җыелыш үткәрегез; ул көнне ураза тотыгыз һәм бернинди дә эш эшләмәгез. [8] Корбанның тәмле исе Раббының күңеленә хуш килсен өчен, тулаем яндыру

корбаны итеп, бер үгез бозау, бер сарык тәкәсе һәм бер яшьлек
җиде бәрән тәкъдим итегез. Болар барысы да кимчелексез булырга
тиеш. [9-10] Һәм алар белән бергә, икмәк бүләге итеп, бер үгез бозау
өчен епаның уннан өч өлеше кадәр, бер сарык тәкәсе өчен епаның уннан ике өлеше кадәр һәм җиде бәрәннең һәрберсе өчен
епаның уннан бер өлеше кадәр, зәйтүн мае белән аралаштырылган иң яхшы бодай оны китерегез. [11] Һәм гөнаһ йолу корбаны итеп
бер кәҗә тәкәсе корбан итегез. Аны, гөнаһтан арындыру корбаны,
көндәлек тулаем яндыру корбаны һәм аның икмәк белән шәраб
бүләкләреннән тыш, өстәмә тәкъдим итегез».

*Чатырлар бәйрәме тәкъдимнәре*

[12] «Җиденче айның унбишенче көнендә изге җыелыш үткәрегез;
бернинди дә эш эшләмәгез һәм җиде көн буе Раббы хөрмәтенә
бәйрәм итегез. [13] Корбанның тәмле исе Раббының күңеленә хуш
килсен өчен, тулаем яндыру корбаны итеп унөч үгез бозау, ике сарык тәкәсе һәм бер яшьлек ундүрт тәкә бәрәнне яндыру корбаны
буларак тәкъдим итегез. Болар барысы да кимчелексез булырга тиеш. [14-15] Һәм аларның икмәк бүләге итеп, унөч үгез бозауның һәрберсе өчен епаның уннан өч өлеше кадәр, ике сарык тәкәсенең
һәрберсе өчен епаның уннан ике өлеше кадәр һәм ундүрт тәкә бәрәннең һәрберсе өчен епаның уннан бер өлеше кадәр, зәйтүн мае
белән аралаштырылган иң яхшы бодай оны китерегез. [16] Һәм гөнаһ йолу корбаны итеп бер кәҗә тәкәсе китерегез. Аны, көндәлек
тулаем яндыру корбаны һәм аның икмәк белән шәраб бүләкләреннән тыш, өстәмә тәкъдим итегез.

[17] Икенче көнне унике үгез бозау, ике сарык тәкәсе һәм бер
яшьлек ундүрт тәкә бәрән тәкъдим итегез. Болар барысы да кимчелексез булырга тиеш. [18] Һәм, аларның санына карап, канун буенча, үгез бозауларның, сарык тәкәләренең һәм тәкә бәрәннәрнең икмәк белән шәраб бүләкләре [19] һәм гөнаһ йолу корбаны итеп
бер кәҗә тәкәсе китерегез. Аны, көндәлек тулаем яндыру корбаны һәм аның икмәк белән шәраб бүләкләреннән тыш, өстәмә
тәкъдим итегез.

[20] Өченче көнне унбер үгез бозау, ике сарык тәкәсе һәм бер
яшьлек ундүрт тәкә бәрән тәкъдим итегез. Болар барысы да кимчелексез булырга тиеш. [21] Һәм, аларның санына карап, канун буенча, үгез бозауларның, сарык тәкәләренең һәм тәкә бәрәннәрнең икмәк белән шәраб бүләкләре [22] һәм гөнаһ йолу корбаны итеп
бер кәҗә тәкәсе китерегез. Аны, көндәлек тулаем яндыру корбаны һәм аның икмәк белән шәраб бүләкләреннән тыш, өстәмә
тәкъдим итегез.

[23] Дүртенче көнне ун үгез бозау, ике сарык тәкәсе һәм бер яшьлек
ундүрт тәкә бәрән тәкъдим итегез. Болар барысы да кимчелексез

булырга тиеш. 24 Һәм, аларның санына карап, канун буенча, үгез
бозауларның, сарык тәкәләренең һәм тәкә бәрәннәрнең икмәк
белән шәраб бүләкләре 25 һәм гөнаһ йолу корбаны итеп бер кәҗә
тәкәсе китерегез. Аны, көндәлек тулаем яндыру корбаны һәм
аның икмәк белән шәраб бүләкләреннән тыш, өстәмә тәкъдим
итегез.

26 Бишенче көнне тугыз үгез бозау, ике сарык тәкәсе һәм бер
яшьлек ундүрт тәкә бәрән тәкъдим итегез. Болар барысы да ким-
челексез булырга тиеш. 27 Һәм, аларның санына карап, канун бу-
енча, үгез бозауларның, сарык тәкәләренең һәм тәкә бәрәннәр-
нең икмәк белән шәраб бүләкләре 28 һәм гөнаһ йолу корбаны итеп
бер кәҗә тәкәсе китерегез. Аны, көндәлек тулаем яндыру корба-
ны һәм аның икмәк белән шәраб бүләкләреннән тыш, өстәмә
тәкъдим итегез.

29 Алтынчы көнне сигез үгез бозау, ике сарык тәкәсе һәм бер
яшьлек ундүрт тәкә бәрән тәкъдим итегез. Болар барысы да ким-
челексез булырга тиеш. 30 Һәм, аларның санына карап, канун бу-
енча, үгез бозауларның, сарык тәкәләренең һәм тәкә бәрәннәр-
нең икмәк белән шәраб бүләкләре 31 һәм гөнаһ йолу корбаны итеп
бер кәҗә тәкәсе китерегез. Аны, көндәлек тулаем яндыру корба-
ны һәм аның икмәк белән шәраб бүләкләреннән тыш, өстәмә
тәкъдим итегез.

32 Җиденче көнне җиде үгез бозау, ике сарык тәкәсе һәм бер
яшьлек ундүрт тәкә бәрән тәкъдим итегез. Болар барысы да ким-
челексез булырга тиеш. 33 Һәм, аларның санына карап, канун бу-
енча, үгез бозауларның, сарык тәкәләренең һәм тәкә бәрәннәр-
нең икмәк белән шәраб бүләкләре 34 һәм гөнаһ йолу корбаны итеп
бер кәҗә тәкәсе китерегез. Аны, көндәлек тулаем яндыру корба-
ны һәм аның икмәк белән шәраб бүләкләреннән тыш, өстәмә
тәкъдим итегез.

35 Сигезенче көнне изге җыелыш үткәрегез, бернинди дә эш эш-
ләмәгез. 36 Корбанның тәмле исе Раббының күңеленә хуш килсен
өчен, тулаем яндыру корбаны итеп бер үгез бозау, бер сарык тәкә-
се һәм бер яшьлек җиде тәкә бәрәнне яндыру корбаны буларак тә-
къдим итегез. Болар барысы да кимчелексез булырга тиеш. 37 Һәм,
аларның санына карап, канун буенча, үгез бозауның, сарык тәкә-
сенең һәм тәкә бәрәннәрнең икмәк белән шәраб бүләкләре 38 һәм
гөнаһ йолу корбаны итеп бер кәҗә тәкәсе китерегез. Аны, көндә-
лек тулаем яндыру корбаны һәм аның икмәк белән шәраб бүләк-
ләреннән тыш, өстәмә тәкъдим итегез».

39 «Билгеләнгән бәйрәмнәрегездә Раббыга, нәзерләрегездән һәм
ихтыяри тәкъдимнәрегездән тыш, өстәмә, тулаем яндыру корбан-
нарыгызны, икмәк һәм шәраб бүләкләрегезне һәм татулык кор-
баннарыгызны китерегез».

# 30

[1] Муса Раббы әмер иткәннәрнең һәммәсен исраиллеләр-
гә сөйләп бирде.

*Әйткән нәзерне үтәү хакында*

[2] Муса исраиллеләрнең ыруг башлыкларына әйтте:
– Раббы менә нәрсә әмер итте: [3] «Әгәр кем дә булса бирәү Раб-
быга нәзер әйтсә яки үзен тыйган вәгъдә белән бәйләргә ант итсә,
ул үзенең биргән сүзен бозарга тиеш түгел һәм авызыннан чыккан
һәр сүзен үтәргә тиеш».

*Хатын-кызларның әйткән нәзерне үтәүләре хакында*

[4] «Әгәр бер хатын яшь чагында, атасы өендә торган вакытта,
Раббыга нәзер әйтсә яки үзен тыйган вәгъдә белән бәйләсә, [5] һәм
аның атасы кызының нәзерен яки вәгъдә белән бәйләнгән булуын
ишетсә һәм бу хакта бер сүз дә әйтмәсә, бу хәлдә аның бөтен нә-
зерләре һәм барлык үзен тыйган вәгъдәләре үтәләчәк. [6] Әгәр дә
атасы бу хакта ишетеп, аңа рөхсәт итмәсә, мондый хәлдә кызы-
ның барлык нәзерләре һәм үзен тыйган вәгъдәләре үтәлмәячәк;
Раббы аны кичерәчәк, чөнки моны аның атасы тыя.
[7] Әгәр нәзер биргән яки уйламыйча әйткән, үзен тыйган вәгъдә
белән бәйләгән хатын кияүгә чыкса, [8] һәм бу хакта аның ире ишетсә
һәм ишетеп тә бер сүз дә әйтмәсә, бу хәлдә аның нәзерләре һәм үзен
тыйган вәгъдәләре үтәләчәк. [9] Әгәр ире бу хакта ишетеп, хатынына
рөхсәт итмәсә, ул хатынының нәзерен һәм аның уйламыйча әйткән
үзен тыйган вәгъдәсенең көчен бетерә, һәм Раббы аны кичерәчәк.
[10] Тол яки иреннән аерылган хатынның нәзере һәм аның үзен
тыйган вәгъдәсе үтәләчәк.
[11] Әгәр хатын ире өендә нәзер әйтсә яки үзен тыйган вәгъдә бе-
лән бәйләргә ант итсә, [12] һәм ире бу хакта ишетеп тә бер сүз дә әйт-
мәсә һәм хатынын тыймаса, бу хәлдә хатынның бөтен нәзерләре
һәм аның барлык үзен тыйган вәгъдәләре үтәләчәк. [13] Әгәр ире бу
хакта ишетеп, хатынының нәзерләрен яки вәгъдәләрен кире как-
са, хатынның нәзерләре яки аның авызыннан чыккан вәгъдәләре
үтәлмәячәк; чөнки ире аларның көчен бетерә; һәм Раббы хатынны
кичерәчәк. [14] Үзен тыю өчен әйткән һәр вәгъдәне һәм һәр нәзерне
хатынның ире рәсмиләштерә яки көчен бетерә ала. [15] Әгәр аның
ире хатынының нәзер һәм вәгъдәләре хакында ишеткән көндә
һәм аннан соңгы көннәрдә дә бу хакта бер сүз дә әйтмәсә, димәк,
ул хатынның нәзер, вәгъдәләрен рәсмиләштерә; чөнки бу хакта
ишеткән көндә ул хатынына бер сүз дә әйтми. [16] Әгәр берникадәр
вакыттан соң ир аларның көчен бетерсә, ул чакта бу ир хатыны-
ның гөнаһын үз өстенә алган була».

[17] Ир белән хатын арасындагы, яшь чагында, атасының өендә чакта, кызы белән атасы арасындагы әйткән нәзерне ничек үтәргә икәнлеге хакында Раббының Мусага әмер иткән кагыйдәләре менә шулар.

*Мидьянлыларга каршы сугыш*

**31** [1] Раббы Мусага әйтте:
[2] – Исраиллеләр өчен мидьянлылардан үч ал. Шуннан соң син үлгән ата-бабаларың белән кушылырсың.
[3] Муса халыкка әйтте:
– Мидьянлылардан Раббының үчен алу өчен, арагыздан кешеләрне сугышка коралландырыгыз. [4] Исраиллеләрнең барлык ыругларыннан, һәр ыругтан бер мең кеше алып, сугышка озатып җибәрегез.
[5] Барлык исраиллеләрдән, һәр ыругтан бер мең кеше исәбеннән, коралландырылган унике мең кеше сугышка озатып җибәрү өчен
аерып алынды. [6] Муса һәр ыругтан мең кешене һәм рухани Элгазар угылы Пинхәсне дә сугышка озатып җибәрде. Пинхәс Изге бүлмә савытларын һәм, куркыныч килүен белдерү өчен, быргыны кулына алды.
[7] Алар, Раббы Мусага әмер иткәнчә, мидьянлыларга каршы сугышка киттеләр һәм мидьянлыларның барлык ир-атларын кырып
бетерделәр. [8] Үтерелгән ирләр белән бергә биш Мидьян патшасын: Эви, Рәкым, Сур, Хүр һәм Ребаны да, шулай ук Бигур угылы Билгамны да кылыч белән үтерделәр. [9] Ә Мидьян хатыннарын һәм
аларның балаларын әсир итеп алдылар, аларның барлык терлекләрен, көтүләрен һәм барча мал-мөлкәтләрен ганимәт итеп алдылар.
[10] Һәм мидьянлылар яшәгән барлык шәһәр һәм торак урыннарын
яндырдылар. [11] Кешедән алып терлеккә кадәр – кулларына төшкән
барлык байлыкны һәм ганимәтне үзләренә алдылар. [12] Кулларына
төшкән әсирләрне, байлыкны һәм ганимәтне Үрдүн ярында, Әрихә каршындагы Моаб үзәнлегенә – тукталу урынына, Муса белән рухани Элгазарга һәм Исраил җәмәгатьчелегенә алып кайттылар.
[13] Муса белән рухани Элгазар һәм җәмәгатьчелекнең барлык җитәкчеләре аларны каршы алу өчен тукталу урыныннан чыктылар.
[14-15] Муса сугыштан кайткан гаскәр башлыкларын, ягъни меңбашларны һәм йөзбашларны, ачуланып әйтте:
– Сез барлык хатын-кызларны исән калдырдыгызмы?! [16] Менә,
алар Билгамның киңәше буенча, Пигур вакыйгасында исраиллеләрнең Раббыдан чигенүләренә сәбәп булганнар, шуңа күрә дә
Раббы халкында үләт таралды. [17] Шушы минутта ук барлык ир балаларны һәм ир белән ятып якынлык кылган хатын-кызларны үтерегез. [18] Ә ир белән ятып якынлык кылмаган барлык кызларны
үзегез өчен калдырыгыз.

[19] – Арагызда кеше үтергән һәм үтерелгәннең мәетенә кагылган-
нар җиде көн буе тукталу урынының тышында торырга тиеш. Сез
үзегез вә әсирләрегез өченче һәм җиденче көннәрдә чистарыныр-
га тиеш. [20] Барлык кием-салымнарыгызны, күн һәм тире әйберлә-
регезне, кәҗә мамыгыннан эшләнгән бар нәрсәгезне, шулай ук
барлык агач савытларыгызны чистартыгыз.
[21] Рухани Элгазар сугышта йөреп кайткан сугышчыларга әйтте:
– Раббы Мусага әмер иткән канунның кагыйдәсе менә шундый:
[22-23] Алтын, көмеш, бакыр, тимер, ак һәм кара кургашны һәм утта
янмаган бар нәрсәне чистарту өчен ут аша үткәрегез, шуннан соң
алар шакшылыкны пакьләү суы белән чистартылырга тиеш. Һәм
утта яна торган бар нәрсә шакшылыкны пакьләү суы белән чис-
тартылырга тиеш. [24] Җиденче көндә киемнәрегезне юыгыз, шуннан
соң пакь булырсыз һәм тукталу урынына керерсез.

*Ганимәтне бүлү*

[25] Раббы Мусага әйтте:
[26] – Син һәм рухани Элгазар халыкның гаилә башлыклары кулга
төшергән ганимәтне, әсирләрне һәм терлекләрне исәпкә алыгыз.
[27] Ганимәтне тигез итеп икегә бүл: яртысын сугышта булган хәрби-
ләргә, яртысын барлык җәмәгатьчелеккә бүлеп бир. [28] Сугышта
булган хәрбиләргә бирелгәннең яртысыннан, әсирме ул, эре тер-
лекме, ишәкме, вак терлекме, һәр биш йөздән берсен салым итеп
Раббыга ал; [29] һәм, Раббыга махсус бүләк буларак, рухани Элгазар-
га бир. [30] Исраиллеләргә бирелгәннең яртысыннан, әсирме ул, эре
терлекме, ишәкме, вак терлекме, һәр илледән берсен ал да аларны
Раббының Изге чатырында хезмәт итүче левиләргә бир.
[31] Муса белән рухани Элгазар, Раббы Мусага ничек әмер иткән
булса, шулай эшләделәр.
[32] Сугышта булган хәрбиләр, үзләре өчен алган байлыклардан
тыш, алты йөз җитмеш биш мең вак терлек, [33] җитмеш ике мең эре
терлек, [34] алтмыш бер мең ишәк [35] һәм ир белән ятып якынлык
кылмаган утыз ике мең кызны кулларына төшерделәр.
[36] Сугышта булган хәрбиләрнең яртысында: вак терлекләр саны
өч йөз утыз җиде мең биш йөз баш, [37] шулардан Раббыга салым итеп
алты йөз җитмеш бише бирелде; [38] эре терлекләр саны утыз алты
мең, шулардан Раббыга салым итеп җитмеш икесе бирелде; [39] ишәк-
ләр саны утыз мең биш йөз, шулардан Раббыга салым итеп алтмыш
бере бирелде; [40] кешеләр саны уналты мең булып, шулардан Раббыга
салым итеп утыз икесе бирелде.
[41] Муса, Раббы әмер иткәнчә, Раббыга махсус бүләк итеп бирел-
гән салымны рухани Элгазарга тапшырды.
[42] Муса сугышта булган хәрби кешеләрдән исраиллеләр өчен ае-
рып алынганның яртысыннан: [43] вак терлекләр саны өч йөз утыз

җиде мең биш йөз, [44] эре терлекләр саны утыз алты мең, [45] ишәк-
ләр саны утыз мең биш йөз баш, [46] кешеләр саны уналты мең бул-
ды. [47] Муса, Раббы әмер иткәнчә, исраиллеләр өлешенә тигәннең
яртысыннан кеше һәм терлекләрнең илледән бер өлешен алып,
Изге чатырда хезмәт итүче левиләргә бирде.
[48] Гаскәр башлыклары булган меңбашлары һәм йөзбашлары, Муса
янына килеп, аңа әйттеләр:
[49-50] – Без сезнең хезмәтчеләрегез, безнең кулга тапшырылган
хәрбиләрне санадык, алар арасыннан берәү дә югалмаган. Шуңа
күрә без Раббы алдында үзебезне йолу өчен, Раббыга бүләк итеп,
сугышта алган алтын әйберләрне: кул башына кия торган беләзек-
ләр, йөзекләр, кул беләзекләрне, алкалар һәм муенсалар алып
килдек.
[51] Муса белән рухани Элгазар алардан алтынны, ягъни алтыннан
эшләнгән бөтен әйберләрне алдылар. [52] Меңбашлар һәм йөзбаш-
лардан Раббыга бүләк итеп китерелгән алтын барлыгы уналты мең
җиде йөз илле шәкыл авырлыгында булды. [53] Хәрбиләр исә һәр-
берсе байлыкны үзе өчен талады. [54] Муса белән рухани Элгазар ал-
тынны, меңбашлардан һәм йөзбашлардан алып, Раббы алдына,
исраиллеләр истәлеге итеп, Изге чатырга алып килделәр.

*Рубин, Гәд ыруглары һәм Менашше ыругының яртысына милек*

**32** [1] Рубин һәм Гәд угылларының көтүләре бик күп иде һәм
алар Язер һәм Гилыгад җирләренең көтү йөртү өчен
яраклы урын икәнен күрделәр. [2-3] Гәд һәм Рубин угыл-
лары Муса белән рухани Элгазар һәм җәмәгатьчелек җитәкчеләре
янына килеп сөйләделәр:
– Атарот, Дибон, Язер, Нимра, Хишбун, Элгале, Себам, Нәбу
һәм Бегон, [4] Исраил җәмәгатьчелеге алдында Раббы тар-мар иткән
бу җир – эре терлек өчен яраклы җир, ә синең хезмәтчеләреңнең
эре терлекләре бар.
[5] Һәм алар әйттеләр:
– Без синең күз алдында мәрхәмәт казанганбыз икән, бу җирне
биләмә итеп безгә – хезмәтчеләреңә бир; безне Үрдүннең аръягы-
на чыгарма.
[6] Муса Гәд һәм Рубин угылларына әйтте:
– Кардәшләрегез сугышка барачак, ә сез монда калырсызмы?
[7] Ни өчен сез исраиллеләрнең күңелләрен Раббы аларга биргән
җиргә барудан сүрелдерәсез? [8] Раббы биргән җирне карау өчен, мин
сезнең аталарыгызны Кадыш-Барниадан җибәргән вакытта, алар
да нәкъ менә шулай эшләгән иде. [9] Алар Эшкүл үзәнлегенә кадәр
барып җитеп, ул җирне күрделәр һәм исраиллеләрнең күңелләрен
Раббы аларга биргән җиргә барудан сүрелдерделәр. [10] Шул көнне
Раббының ачуы кабарды һәм Ул ант итеп әйтте: [11] «Мисырдан

чыккан бу кешеләр, егерме яшьтән алып аннан өлкәнрәк булганнары, Ибраһимга, Исхакка һәм Ягъкубка бирермен дип ант иткән жирне һич күрмәячәкләр, чөнки алар Миңа жаннары-тәннәре белән иярмәделәр. 12 Бу исәпкә кыназлы Ифунни угылы Кәлеб белән Нун угылы Йешуа гына керми, чөнки алар Раббыга жаннары-тәннәре белән иярделәр». 13 Раббының Исраилгә ачуы кабарды, һәм Ул Аның алдында яманлык эшләгән бу буынны, тәмам юкка чыкканчы, кырык ел буе чүлдә йөртте.

14 – Менә, сез – гөнаһлылар буыны, аталарыгыз урынын аласыз һәм Раббының Исраилгә каршы ачуын тагын да ныграк кабартасыз. 15 Әгәр сез Аңардан чигенәсез икән, Ул Исраил халкын янә чүлдә калдырачак. Шулай итеп, сез бу халыкны тулысынча харап итәчәксез.

16 Гәд һәм Рубин угыллары, Муса янына килеп, аңа әйттеләр:

– Без монда көтүләребез өчен сарык араннары һәм балаларыбыз өчен шәһәрләр корачакбыз. 17 Үзебез исә бик тиз коралланачакбыз, исраиллеләрне үзләренә булачак жиргә урнаштырганга кадәр, алар алдыннан барачакбыз. Ә балаларыбыз, бу жирдәгеләр һөжүменнән хәвефсез яшәр өчен, ныгытылган шәһәрләрдә калсыннар. 18 Исраиллеләрнең һәрберсе үзенең жир мирасын алып урнашканга кадәр, без үз өйләребезгә кайтмаячакбыз. 19 Без Үрдүннең аръягында алар белән бергә мирас алмаячакбыз, чөнки безнең мирасыбыз Үрдүннең көнчыгыш тарафында булачак.

20 Муса аларга әйтте:

– Әгәр шулай эшлисез һәм, коралланып, Раббы алдында сугышка чыгасыз икән, 21-22 Раббы Үзе алдындагы дошманнарын тар-мар иткәнгә һәм Үрдүннең аръягындагы жир Раббы алдында яулап алынганга кадәр сезнең арагыздан коралланган теләсә кем Үрдүннең аръягына чыга икән, ул кеше, ахырдан, өенә кайта ала; Раббы алдында да, Исраил алдында да гөнаһсыз булырсыз; һәм Раббы алдында бу жир сезнең мөлкәтегез булыр.

23 – Әгәр алай эшләмәсәгез, Раббы алдында гөнаһ эшләгән булачаксыз, һәм өстегезгә киләчәк гөнаһ өчен жәфа чигәчәксез. 24 Балаларыгыз өчен шәһәрләр төзегез, сарыкларыгыз өчен араннар корыгыз һәм авызыгыздан чыккан сүзләрне тормышка ашырыгыз.

25 Гәд угыллары белән Рубин угыллары Мусага әйттеләр:

– Синең хезмәтчеләрең, әфәндебез, син ничек кушсаң, шулай эшләячәкләр. 26 Безнең балаларыбыз, хатыннарыбыз, көтүләребез һәм барча терлекләребез монда – Гилыгад шәһәрләрендә калачак. 27 Ә синең хезмәтчеләрең, сугышчылар кебек коралланып, әфәндебез кушканча, Үрдүн аръягына чыгып, Раббы алдында сугышка барачаклар.

28 Муса алар хакында рухани Элгазарга, Нун угылы Йешуага һәм исраиллеләрнең ыруг башлыкларына әмер бирде. 29 Муса аларга әйтте:

– Әгәр Гәд һәм Рубин угыллары, сугышчылар кебек коралланып, Раббы алдында сезнең белән бергә Үрдүннең аръягына чыгалар һәм сезнең алдыгыздагы җир басып алына икән, ул чагында Гилыгад җирен биләмә итеп аларга бирегез.
[30] Әгәр сезнең белән бергә Үрдүн аръягына чыкмыйлар икән, ул чагында алар сезнең белән бергә Кәнган җирендә биләмә алырга тиеш.

[31] Гәд һәм Рубин угыллары болай дип җавап бирделәр:

– Раббы синең хезмәтчеләреңә ничек боерган булса, без шулай эшләрбез.
[32] Без, коралланып, Раббы алдында Кәнган җиренә барачакбыз, әмма безгә биләмә итеп биреләсе җирләр Үрдүннең бу ягында булсын.

[33] Муса Гәд һәм Рубин угылларына, Йосыф угылы Менашше ыругының яртысына аморилəр патшасы Сихон патшалыгын һәм Башан патшасы Ог патшалыгын шәһәрләре һәм әйләнә-тирәдәге җирләре белән бирде.

[34-36] Гәд угыллары ныгытмалы Дибон, Атарот, Арогыр, Атрот-Шофан, Язер, Йөгбеһа, Бәйт-Нимра, Бәйт-Һаран шәһәрләрен һәм сарык араннары кордылар.
[37-38] Ә Рубин угыллары Хишбун, Элгале һәм Кырьятаим, Нәбу һәм Багал-Мәгун (кайбер исемнәре үзгәртелгән) һәм Сибма шәһәрләрен яңадан төзеделәр; һәм үзләре яңадан төзегән шәһәрләргә яңа исемнәр бирделәр.

[39] Менашшенең угылы Макир угыллары, Гилыгадка китеп, аны басып алдылар һәм анда яшәгән аморилəрне куып чыгардылар.
[40] Муса Гилыгадны Менашше угылы Макирга бирде, һәм ул шунда яшәде.
[41] Менашше нәселеннән булган Яһир аморилəрнең авылларын басып алды һәм аларны Яһир Авыллары дип атады.
[42] Нобах та Кынатны һәм аның тирәсендәге шәһәрләрне басып алды һәм аны үз исеме белән Нобах дип атады.

*Мисырдан Үрдүн елгасына кадәр үткән юл*

## 33

[1] Хәрби төркемнәре белән Муса һәм Һарун җитәкчелегендә Мисыр җиреннән чыккан исраиллеләрнең сәяхәтләре менә мондый.
[2] Муса, Раббы күрсәтмәсе нигезендә, аларның сәяхәтләрен кузгалып китү урыннарының исемнәре буенча язды. Кузгалып китү урыннары буенча аларның сәяхәтләре менә мондый:

[3] Беренче айда, беренче айның унбишенче көнендә, Коткарылу бәйрәменнән соң икенче көндә бөтен Мисырның күз алдында алар тантаналы рәвештә Рәмесестән чыктылар.
[4] Бу вакыт эчендә мисырлылар Раббы тарафыннан үтерелгән бөтен беренче булып туган угылларын күмделәр, һәм Раббы аларның илаһларын хөкем итте.

[5] Исраиллеләр Рәмесестән кузгалып китеп, Суккөттә чатырларын корып урнаштылар.

6 Суккөттән китеп, чүл читендәге Этамда чатырларын корып урнаштылар.
7 Этамнан китеп, Багал-Сефоннан көнчыгышта урнашкан Пи-Һахирутка кире кайттылар һәм Мигдол каршында чатырларын корып урнаштылар.
8 Пи-Һахирут каршысыннан китеп, диңгез кичеп, чүлгә чыктылар һәм, Этам чүле буйлап өч көн барганнан соң, Марада чатырларын корып урнаштылар.
9 Марадан китеп, Элимгә килделәр; Элимдә исә унике су чыганагы һәм җитмеш хөрмә агачы бар иде. Алар шунда чатырларын корып урнаштылар.
10 Элимнән китеп, Камышлы диңгез яры буенда чатырларын корып урнаштылар.
11 Камышлы диңгез яры буеннан китеп, Син чүлендә чатырларын корып урнаштылар.
12 Син чүленнән китеп, Дуфкада чатырларын корып урнаштылар.
13 Дуфкадан китеп, Алушта чатырларын корып урнаштылар.
14 Алуштан китеп, Рефидимдә чатырларын корып урнаштылар; анда халык өчен эчәргә су булмаган.
15 Рефидимнән китеп, Синай чүлендә чатырларын корып урнаштылар.
16 Синай чүленнән китеп, Кыйбрут-Һаттавада чатырларын корып урнаштылар.
17 Кыйбрут-Һаттавадан китеп, Хасеротта чатырларын корып урнаштылар.
18 Хасероттан китеп, Ритмада чатырларын корып урнаштылар.
19 Ритмадан китеп, Риммон-Перестә чатырларын корып урнаштылар.
20 Риммон-Перестән китеп, Либнада чатырларын корып урнаштылар.
21 Либнадан китеп, Риссада чатырларын корып урнаштылар.
22 Риссадан китеп, Кыһилатада чатырларын корып урнаштылар.
23 Кыһилатадан китеп, Шефер тавында чатырларын корып урнаштылар.
24 Шефер тавыннан китеп, Харадада чатырларын корып урнаштылар.
25 Харададан китеп, Макыһелотта чатырларын корып урнаштылар.
26 Макыһелоттан китеп, Тахатта чатырларын корып урнаштылар.
27 Тахаттан китеп, Терахта чатырларын корып урнаштылар.
28 Терахтан китеп, Миткада чатырларын корып урнаштылар.
29 Миткадан китеп, Хашмонада чатырларын корып урнаштылар.
30 Хашмонадан китеп, Мосеротта чатырларын корып урнаштылар.
31 Мосероттан китеп, Бәне-Ягаканда чатырларын корып урнаштылар.

32 Бәне-Ягаканнан китеп, Хор-Һагидгәддә чатырларын корып урнаштылар.

33 Хор-Һагидгәддән китеп, Йотбатада чатырларын корып урнаштылар.

34 Йотбатадан китеп, Абронада чатырларын корып урнаштылар.

35 Абронадан китеп, Эсион-Гебердә чатырларын корып урнаштылар.

36 Эсион-Гебердән китеп, Сыйн чүлендәге Кадышта чатырларын корып урнаштылар.

37 Кадыштан китеп, Эдом җирләре чигендәге Һор тавында чатырларын корып урнаштылар.

38 Раббының күрсәтмәсе буенча, рухани Һарун Һор тавына менгән
һәм исраиллеләрнең Мисыр җиреннән чыгып китүләренең кыры-
гынчы елында, бишенче айда, айның беренче көнендә шунда үлгән.
39 Һарун Һор тавында үлгән вакытта аңа йөз егерме өч яшь булган.

(40 Кәнган җиреннән көньяктагы Нәгебтә яшәгән кәнганлы Арад патша исраиллеләрнең килүен ишеткән.)

41 Алар Һор тавыннан китеп, Салмонада чатырларын корып урнаштылар.

42 Салмонадан китеп, Пунонда чатырларын корып урнаштылар.

43 Пунаннан китеп, Оботта чатырларын корып урнаштылар.

44 Оботтан китеп, Моаб чигендәге Ие-Әбаримда чатырларын корып урнаштылар.

45 Ие-Әбаримнан китеп, Дибон-Гадта чатырларын корып урнаштылар.

46 Дибон-Гадтан китеп, Алмон-Диблатаимда чатырларын корып урнаштылар.

47 Алмон-Диблатаимдан китеп, Нәбу алдындагы Әбарим тауларында чатырларын корып урнаштылар.

48 Әбарим тауларыннан китеп, Үрдүн елгасы ярында, Әрихә каршында, Моаб үзәнлегендә чатырларын корып урнаштылар.

49 Үрдүн яры буенча Бәйт-Ишимоттан Абел-Шиттимга кадәр, Моаб үзәнлегендә чатырларын корып урнаштылар.

50 Үрдүн елгасы ярында Әрихә каршында Моаб үзәнлегендә Раббы Мусага әйтте:

51-52 – Исраиллеләргә әйт: «Үрдүн елгасын кичеп, Кәнган җире-
нә кергәч, ул җирдә яшәүчеләрне бөтенләй куып чыгар. Аларның
коеп ясалган һәм таштан сырлаган барча потларын һәм потларына
табыну урыннарын пыр туздыр. 53 Ул җирне биләп алыгыз һәм ан-
да хуҗа булып урнашыгыз, чөнки Мин ул җирне сезгә милек итеп
бирәм. 54 Ул җирне, шобага салып, кабиләләр арасында бүлегез,
кеше саны күп булган төркемгә күбрәк, аз санлы төркемгә азрак
җир бирегез. Шобага кемгә кайда төшсә, шул җир аныкы булачак.
Ата-бабаларыгызның ыругларына карап үзегезгә мирас алыгыз.

[55] Әгәр ул җирдә яшәүчеләрне кумасагыз, калганнары сезнең күзләрегезгә күгән кебек һәм гәүдәгезнең ян якларына энә кебек кадалачак. Алар сез яшәгән бу җирдә сезнең белән дошманлашачак. [56] Менә шул чакта Мин аларга каршы нәрсә эшләргә ният иткән булсам, шуны сезгә каршы эшләячәкмен».

*Кәнган җире чикләре*

**34** [1] Раббы Мусага әйтте:
[2] – Исраиллеләргә әмер бир һәм әйт: «Кәнган җиренә кергәч, Мин сезгә бирәчәк ул җирнең чикләре менә мондый булачак:

[3] Сезнең көньяк тарафыгыз Сыйн чүленнән башланып, Эдом чиге буенча барачак һәм көньяк чигегез Тоз күленең* көнчыгыш азагыннан башланып дәвам итәчәк. [4] Чигегез, Акраббим үткеленең көньягына таба чыгып, Сыйн чүле аша үтәчәк һәм Кадыш-Барнианың көньягына кадәр барачак; аннан Хасар-Аддарга юнәләчәк һәм Асмонга үтәчәк. [5] Чик Асмоннан Мисыр гөрләвегенә юнәләчәк һәм диңгезгә* кадәр сузылачак.

[6] Ә көнбатыш чигегез Бөек диңгез* белән аның яры булачак. Бу – сезнең көнбатыш чигегез.

[7] Төньяк чигегезне Бөек диңгездән башлап Һор тавына таба билгеләгез. [8] Һор тавыннан чик Хаматка керү урынына таба сузылачак һәм чикнең очлары Седадка барып чыгачак. [9] Шуннан чик Зифронга таба яңадан сузылачак һәм Хасар-Энанга кадәр барып чыгачак. Бу – сезнең төньяк чигегез.

[10] Көнчыгыш чигегезне Хасар-Энаннан Шефамга таба билгеләгез. [11] Шефамнан чик Аинның көнчыгыш ягындагы Риблага таба сузылачак һәм аннан Киннерет диңгезенең* көнчыгыш ярындагы сөзәклекләр буенча дәвам итәчәк. [12] Чик Үрдүн елгасына төшеп сузылачак һәм аның очы Тоз күленә барып чыгачак. Менә бу сезнең һәр тарафка чикләре билгеләнгән җирегез булачак».

[13] Муса, исраиллеләргә әмер итеп, болай диде:

– Тугыз ярым ыругка бирергә дип Раббы әмер иткән һәм сез шобага салып мирас итеп алачак җир менә шушы була. [14] Чөнки Рубин һәм Гәд угылларының ыруглары һәм Менашшеның ярым ыругы, гаиләләренә карап, үз мирасларын алдылар инде. [15] Ике ярым ыруг үзләренә мирас җирен Әрихә каршында, Үрдүннең көнчыгыш ярында алдылар.

---

* 34:3 *Тоз күле* – «Үле диңгез».
* 34:5 *Диңгез* – ягъни «Урта диңгез».
* 34:6 *Бөек диңгез* – ягъни «Урта диңгез».
* 34:11 *Киннерет диңгезе* – «Гәлиләя диңгезе».

*Җир бүлүчеләр*

16 Раббы Мусага әйтте:
17 – Менә сезгә җир бүлеп бирәчәк кешеләрнең исемнәре: рухани Элгазар белән Нун угылы Йешуа. 18 Һәм һәр ыругтан җир бүлү өчен берәр җитәкче алыгыз. 19 Менә аларның исемнәре:
– «Йәһүдә ыругыннан – Ифунни угылы Кәлеб;
20 Шимун ыругыннан – Аммиһуд угылы Шемуил;
21 Беньямин ыругыннан – Кислон угылы Элидад;
22 Дан угыллары ыругыннан – Йогли угылы җитәкче Вукки;
23 Йосыф угылларыннан, Менашше угыллары ыругыннан – Ифод угылы җитәкче Ханниел;
24 Эфраим угыллары ыругыннан – Шифтан угылы җитәкче Кымуил;
25 Зәбулун угыллары ыругыннан – Парнах угылы җитәкче Элисафан;
26 Исәсхәр угыллары ыругыннан – Аззан угылы җитәкче Палтиел;
27 Ашир угыллары ыругыннан – Шеломи угылы җитәкче Ахиһуд;
28 Нәфтали угыллары ыругыннан – Аммиһуд угылы җитәкче Педаһел».
29 Кәнган җирендә исраиллеләргә мирас итеп җир бүлеп бирү өчен Раббы билгеләгән кешеләрнең исемнәре менә шулар.

*Исраиллеләрнең левиләргә шәһәрләр бүлеп бирүе*

35 1 Үрдүн елгасы ярында, Әрихә каршында, Моаб үзәнлегендә Раббы Мусага әйтте:
2 – Исраиллеләргә әмер ит: алар үзләре биләмә итеп алган мирастан яшәү өчен левиләргә шәһәрләр бирсеннәр; һәм ул шәһәрләрнең һәр ягында алар өчен көтүлекләре дә булсын; 3 шәһәрләр яшәү өчен, ә көтүлекләре аларның сыерлары, көтүләре һәм барлык башка терлекләре өчен булачак.
4 – Сез левиләргә бирергә тиешле шәһәр читендәге көтүлекләр шәһәр диварыннан мең терсәк озынлыгында шәһәр тирәсенә сузылырга тиеш. 5 Һәр шәһәр көтүлек уртасында булачак, шәһәр читеннән көнчыгышка таба ике мең терсәк, көньякка ике мең терсәк, көнбатышка ике мең терсәк һәм төньякка ике мең терсәк итеп үлчәгез. Аларның шәһәр тирәсендәге көтүлекләре менә шулай булачак.
6 – Левиләргә сез бирәчәк шәһәрләрдән алтысы сыену шәһәрләре булачак. Кеше үтерүчегә шул шәһәрләргә качарга рөхсәт итәргә мөмкин булачак. Бу алты шәһәрдән тыш, аларга тагын кырык ике шәһәр бирегез. 7 Левиләргә сез бирергә тиешле шәһәрләр саны кырык сигез булачак, аларның әйләнә-тирәсендә көтүлекләр дә булсын. 8 Исраиллеләр биләмәләреннән левиләргә шәһәрләр

биргәндә, күп мөлкәтле ыруглардан — күбрәк, аз мөлкәтле ыруглардан азрак бирегез. Һәр ыруг, алган мирасының күләменә карап, үз шәһәрләреннән левиләргә өлеш бирергә тиеш булачак.

*Сыену шәһәрләре*

9 Раббы Мусага әйтте:
10-11 – Исраиллеләргә игълан ит: «Үрдүн аша үтеп, Кәнган жире-
нә кергәннән соң, үзегез өчен сыену шәһәрләре сайлап алыгыз.
Ялгышлык белән кеше үтерүчегә анда качарга рөхсәт итәргә мөм-
кин булачак. 12 Ул шәһәрләр үч алучыдан саклану өчен сыену
урыннары булачак. Шулай итеп, кеше үтергән адәм җәмәгатьчелек
хөкеменә кадәр үтерелмәскә мөмкин. 13 Сыену өчен сез бирергә
тиешле сыену шәһәрләре алтау булачак. 14 Үрдүннең бу ягында —
өч шәһәр һәм Кәнган җирендә өч шәһәр бирегез; ул шәһәрләр
сыену шәһәрләре булырга тиеш. 15 Ялгышлык белән кеше үтергән
теләсә кем кача алсын өчен, бу алты шәһәр исраиллеләргә һәм
алар арасында читтән килгән кешеләргә һәм вакытлыча яшәүче-
ләргә сыену шәһәрләре булачак.
16 Әгәр берәү тимер корал белән кемгә дә булса сукса һәм теге
кеше үлсә, суккан кеше үтерүче була; кеше үтерүче үлемгә тап-
шырылырга тиеш. 17 Берәү кулындагы үтергеч таш белән кемгә дә
булса суга һәм теге кеше шул сугудан үлә икән, ул кеше үтерүче
була; кеше үтерүче үлемгә тапшырылырга тиеш. 18 Әгәр берәү ку-
лындагы үтергеч агач корал белән кемгә дә булса суга һәм шул су-
гудан теге кеше үлә икән, ул кеше үтерүче була; кеше үтерүче
үлемгә тапшырылырга тиеш. 19 Кан үче алучы кеше үтерүчене үзе
үтерә ала; ул үтерүчене очрата икән, аны үтерә ала. 20-21 Әгәр берәү
кемне булса да нәфрәт белән төртеп җибәрә яки яман ният белән
аңа нәрсә булса да ыргыта, һәм ул кеше шуннан үлә икән, яки
дошманлык аркасында аңа кулы белән суга һәм ул кеше шуннан
үлә икән, сугучы кеше үлемгә тапшырылырга тиеш, чөнки ул ке-
ше үтерүче була. Кан үче алучы кеше үтерүчене очрата икән, аны
үтерә ала.
22 Әгәр берәү дошманлыктан түгел, бәлки ялгышлык белән кем-
не дә булса төртеп җибәрә яки аңа яман ниятсез нәрсә булса да
ыргыта икән, 23 яки аны күрмичә, үтергеч таш төшерә, һәм теге
кеше шуннан үлә икән, әмма үтерүче аның дошманы булмаса һәм
аңа яманлык эшләргә теләмәсә, 24 бу очракта җәмәгатьчелек, үте-
рүче белән кан үче алучы арасындагы эшне тикшереп, түбәндәге
кануннар нигезендә генә хөкем итәргә тиеш. 25 Җәмәгатьчелек
үтерүчене кан үче алучының кулыннан коткарырга һәм аны качып
киткән сыену шәһәренә кире кайтарырга тиеш; һәм ул, изге май
белән майланган баш рухани үлгәнгә кадәр, анда яшәргә тиеш.
26-27 Әгәр кеше үтерүче үзе качкан сыену шәһәреннән чыга һәм кан

үче алучы аны сыену шәһәреннән читтә очратып үтерә икән, кан үче
алучы аны үтерүдә гаепле булмаячак. [28] Чөнки кеше үтерүче, баш
рухани үлгәнгә кадәр, үзе качкан сыену шәһәрендә яшәргә тиеш;
баш рухани үлгәннән соң, аңа үзенең мөлкәте булган җиренә кай-
тырга рөхсәт ителә.
[29] Менә болар – сез яшәгән барлык урыннарда буыннан-буынга
күчеп килә торган канун һәм кагыйдә булачак».

*Катыйльләрнең хөкем ителүе*

[30] «Әгәр берәү кеше үтерә икән, үтерүче кеше шаһитләр сөйлә-
venә карап үтерелергә тиеш; әмма үтерүдә гаепләп үлем җәзасына
хөкем итү өчен бер генә шаһит җитми.
[31] Кеше үтерүдә гаепле булган үтерүченең җаны өчен йолым ал-
магыз, чөнки ул үлемгә тапшырылырга тиеш.
[32] Сыену шәһәренә качкан кешедән, баш рухани үлгәнгә кадәр,
качкын үзенең элекке җирендә яшәсен дип, йолым алмагыз.
[33] Үзегез яшәгән җирне нәҗесләмәгез; чөнки кан җирне нәҗес-
ли, һәм өстенә кан түгелгән җир, бүтән бернәрсә белән дә түгел,
фәкать кан түккәннең каны белән генә чистартыла. [34] Сез яшәгән
һәм Мин яши торган җир нәҗесләнергә тиеш түгел; чөнки Мин –
Раббы, Мин исраиллеләр арасында яшим».

*Мирас алган кызның кияүгә чыгу кагыйдәсе*

**36** [1] Йосыф угылы булган Менашшенең угылы Макирның
малае Гилыгад нәселенә караган кабилә башлыклары
килеп, Муса һәм исраиллеләрнең ыруг башлыклары ал-
дында әйттеләр:
[2] – Раббы безнең әфәндебезгә җирне исраиллеләргә мирас итеп
шобага белән бүлеп бирергә әмер иткән, шулай ук безнең кардә-
шебез Селуфхадның мирасын аның кызларына бирелсен дип тә
Раббы тарафыннан әфәндебезгә әмер бирелгән. [3] Әгәр алар исра-
иллеләрнең башка ыруг угылларына кияүгә чыгалар икән, алар-
ның мирасы, аталарыбыз мирасыннан алынып, алар кушылган
ыругның мирасына өстәләчәк һәм, шулай итеп, шобага белән без-
гә бүлеп бирелгән мирасыбыздан чигереләчәк. [4] Исраиллеләр Ил-
ленче елга кергәндә, ул кызларның мирасы үзләре яши торган
ыругның мирасына өстәләчәк, һәм аларның мирасы безнең атала-
рыбыз мирасыннан чигереләчәк.
[5] Аннары Муса, Раббының күрсәтмәсе буенча, исраиллеләргә
әмер итеп әйтте:
– Йосыф угылларының ыругы дөресен сөйли. [6] Селуфхад кыз-
лары хакында Раббының әмер итеп әйткәне шул: алар үзләренең
күңелләренә ошаган теләсә кемгә кияүгә чыга алалар, тик бу кеше
үз атасының ыругындагы кабиләдән генә булсын. [7] Исраиллеләрнең

мирасы бер ыругтан икенче ыругка күчмәсен, чөнки һәрбер ис-
раилле үзенең аталары ыругының мирасына бәйле булырга тиеш.
[8] Исраиллеләр ыругында мирасчы булган һәр кыз үз атасының
ыругтагы кабиләсеннән булган берәүгә кияүгә чыгарга тиеш, шу-
лай итеп, исраиллеләрнең һәрберсе үз аталарының мирасына ия
булачак. [9] Мирас бер ыругтан икенче ыругка күчмәсен, чөнки ис-
раиллеләрнең һәр ыругы үз мирасына бәйле булырга тиеш.

[10] Раббы Мусага ничек әмер иткән булса, Селуфхад кызлары
нәкъ шулай эшләделәр. [11] Селуфхад кызлары Махла, Тирса, Хөглә,
Милкә һәм Ноа әтиләре ягыннан үз абыйларының угылларына
кияүгә чыктылар. [12] Алар Йосыф угылы Менашше угылларының
ыругларына кияүгә чыктылар һәм аларның мираслары аталары
нәсел-кабиләсендә калды.

[13] Үрдүн елгасы ярында, Әрихә каршында, Моаб үзәнлегендә
Раббының Муса аркылы исраиллеләргә әмер иткән кануннары
һәм әмерләре менә шулар.